# ШУРА

№ 42

2023




2000999960727

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте

ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

# ЭЧТӘЛЕК

Җомга хотбәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . . . . . . . . . . . 9

ВӘГАЗЬЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Мөселман кешесенең киеме . . . . . . . . . . . . . . 14
Аллаһыга охшаган бер генә әйбер дә юк . . . . . . . . 18
Хөсетлек — көчсезлек ул . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Күрше милләт вәкилләре белән тату яшәү . . . . . . 30
Психология — бүгенге көн бәласеме? . . . . . . . . 39
Тапланган йөрәк ни белән куркыныч? . . . . . . . . . 44
Ата-ана хакы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Авырлыклар, авырулар вакытында сабырлык . . . . . . 58
Нәрсә ул тәвәссүл һәм тәбәррук? . . . . . . . . . . . . 62
Рия — кече ширек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Гаилә таркатуда сихер куллану . . . . . . . . . . . . . 75
Вакытның кадере: үткәннәргә хисап, киләчәккә планнар кору . . 81
Аллаһы Тәгаләнең Әр-Раззак исеме . . . . . . . . . . 90

«НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН?» . . . . . . . . . . . . . . 98
Июль – Сентябрь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99

НӘСЫЙХӘТ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Әхлак һәм әхлакый вазифаларыбыз . . . . . . . . . . 118

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021, Казан,
Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Ленар Хамматов

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**МӨХӘРРИР:**
Исламия Хәбибрахманова

**ДИЗАЙНЕР:**
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Ильяс Гарифуллин

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Илшат Хәйретдинов
shutterstock.com сайты кулланылды.

**«ШУРА» дини альманах, № 42**

октябрь–декабрь 2023
рабигыль-әүвәл – җөмәдәл-ахыр 1445

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: izdat@huzur.ru
Сайт: huzur.ru

*Типографиянең адресы:*

*«ОТ Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420030, Казан шәһ., Жуковка ур., 2.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 22.09.2023
Чыгу көне: 06.10.2023

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аятьсүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание
на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللّٰهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللهِ۞ صَلَّى اللهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللهِ!۞ اِتَّقُوا اللهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ:

________________________________۞

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

________________________________________۞

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسلَامُ۞

Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمدُ لِلّٰه حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞ اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاىِٔ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әмин» дип әйтә.

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләẕии һәдәәнә лиһәәẕәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләẕии каалә фии китәәбиһил-кәриими әстәгыйẕү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаẕәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү’миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуẕмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләẕиинәт-тәкау, вәл-ләẕиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйẕү билләһи: __________________________________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ____________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмуллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә кааләллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә иẕәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйẕү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү'миниинә вәл мү'минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәл-ләẓиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ẓәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуṣмәәнә вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү'миниинә вәл мү'минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл

әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мүкыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә’мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәрүүн. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын.[2] Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары,

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

[2] 3 тапкыр әйтелә.

элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

**«Һичшиксез, Аллаһы –** [гөнаһлардан] **курыккан һәм** [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] **игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ____________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: ____________________________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

**«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез** [Аллаһы тарафыннан] **рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында** [хакыйкый һәм кабул ителгән] **дин – Ислам** [дине генә]**».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа ияручеләргә сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

> **«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм** [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] **сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син – догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгеләү.

**Иң соңыннан, «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

**«Һичшиксез, Аллаһы** [һәрнәрсәне аңлатыр өчен, индергән китабында] **гадел булырга, изгелек кылырга һәм** [бигрәк тә] **якын туганнарга** [мохтаҗ булган нәрсәләрен] **бирергә** [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] **әмер итә.** [Зина кебек] **Фәхешлектән,** [көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] **тыелганнан һәм** [кешеләргә] **җәбер-золым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*13нче октябрь вәгазе,*
*рабигыль-әүвәл аеның 28нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Мөселман кешесенең киеме

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмииин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-Кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар итүче, яралтучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләгә барлык хәмед-сәнәләребез, барча мактауларыбыз булса иде. Аның сөекле бәндәсе, пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә барча салават-шәрифләребез булса иде.

Мөселман кешесенең киеме нинди булырга тиеш? Әлбәттә, бу сорауны ишеткәч, һәр милләт үз гореф-гадәтләренә яраклашкан киемнәрне күзаллый. Ләкин шәригатебезнең үз әдәпләре һәм кысалары бар: ир кеше өчен аерым, хатын-кыз өчен аерым. Динебездәге Аллаһы Тәгалә тарафыннан куелган кануннар безнең, ягъни адәмнәрнең, табигатебезгә тәңгәл килә. Шушы киенүгә кагылган кануннар үтәлмәсә, җәмгыятебездәге тәртип тулысынча бозыла. Нәтиҗәдә, зина кылу, гаиләләр таркалу, фәхешлек, тәкәбберлек һәм башка куркыныч афәтләр тарала. Шәригатебездәге таләпләр нинди соң?

Мөселман ир кешесенең киемендә фарыз өлеше — ул кендектән алып тезгә кадәр гаурәтеңне каплау. Киемең шушы өлешне капларга тиеш, ягъни бу оят җирләре, һәм аларны башка кешеләргә күрсәтү — гөнаһ, алар һәрдаим капланган булырга тиеш. Шулай ук мөселман ир кешесенең киеме тәнгә сыланып тормаска, ямьсез рәвештә асылынып, комачаулардык киң дә булырга тиеш түгел, үтәкүренмәле, кыска җиңле, иелгәч биле ачылырлык яисә гаурәте ачылырлык кием, теләсә нәрсә язган яки сурәтләнгән киемне кию дә күркәм саналмый. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай ди:

يَا بَنِي آدَمَ خُذُوا زِينَتَكُمْ عِندَ كُلِّ مَسْجِدٍ وَكُلُوا وَاشْرَبُوا وَلَا تُسْرِفُوا ۚ إِنَّهُ لَا يُحِبُّ الْمُسْرِفِينَ ۞ قُلْ مَنْ حَرَّمَ زِينَةَ اللَّهِ الَّتِي أَخْرَجَ لِعِبَادِهِ وَالطَّيِّبَاتِ مِنَ الرِّزْقِ ۚ قُلْ هِيَ لِلَّذِينَ آمَنُوا فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا خَالِصَةً يَوْمَ الْقِيَامَةِ ۗ كَذَٰلِكَ نُفَصِّلُ الْآيَاتِ لِقَوْمٍ يَعْلَمُونَ

**«Ий, Адәм балалары! Һәр сәҗдә вакытында** [гаурәт урыннарыгызны каплый торган зиннәтле] **киемегезне киегез. Ашагыз, эчегез, әмма** [хәләлне харам итеп, яки харамга катышып, яки туклык чиген узып] **исраф итмәгез. Һичшиксез, Ул** [Раббыгыз] **исрафчы кешеләрне сөйми.** [Расүлем! Ялангач килеш тәваф кылган мөшрикләргә] **Әйт: «Аллаһының колларына өчен** [уртага] **чыгарган зиннәтләрен** [бизәкле киемнәрне, рөхсәт ителгән бизәнгеч әйберләрне] **һәм тәмле ризыкларын кем харам итте** [аларны киюдән тыеласыз]**?»** [Расүлем!] **Әйт: «Кыямәт көнендә исә алар** [ул тәмле ашамлыклар һәм эчемлекләр] **бу дөнья тормышында иман китергән кешеләр өчен** [булачак]. [Коръәннең хаклыгын] **Белгән кавемгә аятьләрне** [дә] **шул рәвешчә** [төгәл] **аңлатабыз».**

«Әл-Әграф / Киртәләр», 7:31–32

Мөселман хатын-кызына килгәндә, алар өчен капларга фарыз булган өлеш — ул, битеннән, беләзеккә кадәр ике кулыннан һәм тубыкка кадәр ике аягыннан кала, бөтен тәне. Киеме үтәкүренмәле, күзгә төшеп торырлык бизәкле вә зиннәтле, сыланып торырлык булырга тиеш түгел. Бу — фарыздыр. Хатын-кыз бар җирен дә диярлек чит күзләрдән кием астына яшерергә тиеш. Ни өчен? Чөнки хатын-кызларның бар тәне дә зиннәттер, читләргә күрсәтү зур гөнаһ булып тора. Әле ул гына да түгел: сакланмыйча киенгән хатын-кызга чит ир караган саен да гөнаһ язылып барадыр. Әгәр хатын-кызларыбыз тиешенчә киенмәсә, җәмгыятебез бик күп бәлаләргә дучар була. Күз

зинасы — зур афәтләрнең берсе. Ә башыңны югалтып, матур булыйм дип, ачык киемнән йөрү — хатын-кыз өчен түбән гамәлләрдән санала.

Гомумән алганда, киемнең ниндиен кияргә? Безнең өчен берәр үрнәк бармы? Әлбәттә, безнең өчен үрнәк булып илчебез, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм торадыр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәрвакыт баш киемендә булырга тырышкан. Сыланып торган кием кимәгән. Өстенә чапанын киеп йөргән. Үзеннән хуш ис кенә килеп торган. Гади киенсә дә, өс-башын пөхтә тоткан. Ни өчен шулай эшләргә тырышканы турында бер хәдисендә ул болай ди: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә матур һәм Ул матурлыкны ярата». Ә икенче бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аллаһы Тәгалә Үзенең рәхмәтен колында күренгәнне яратадыр», — дигән. Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм заманында бик бай кешеләр арттан өстерәлеп барырлык итеп зиннәтле, озын чапаннар кигәннәр. Бу аларның дәрәҗәсен күрсәткән. Шуңа Илчебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Тәкәбберләнеп, артыннан өстерәлеп барырлык итеп озын кием киючеләргә Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә хәтта карамас та». Шуңа Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дәрәҗәңне күрсәтер өчен генә тукыманы сарыф итеп һәм тәкәбберләнеп киенүне тыйгандыр. Әлеге тәкәбберләнү безнең заманда да бар. Кайберәүләр бик кыйммәтле, модага ияреп киенәләр дә, гади, пөхтә генә киенгәннәрдән үзләрен өстен күрәләр. Без дә шушы тәкәбберлеккә бирелүдән куркыйк. Хәдистә болай дип китерелә: «Тыйнак кием — иманнан», — дип. Шуңа күрә киемебезнең матур, пөхтә генә түгел, артык масаюга китерми торган һәм тыйнак та булуы мөһим. Аңлавыбызча, эш киемдә генә түгел, күңелдә дә.

Милләтебезгә килгәндә, безнең гореф-гадәтләребез динебез белән яраклашкан. Әби-бабаларыбызның киенү рәвешен генә искә төшерсәк тә, аларның әдәпләрен, аларның ни дәрәҗәдә Аллаһы Тәгалә кушканча яшәргә тырышуларын күзаллый алабыз. Әлбәттә, милли дип, матурлык өчен генә яулыксыз һәм күлмәксез кызларның башына калфак «элеп» куюлары икенче

бер мәсьәлә. Бу — ялгышлык. Мөселман татар кызларының башларыннан элек-электән яулыкларын беркем дә салдыра алмаган да, салдыра алмаслар да. Ирләре исә һәрвакыт Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм үрнәге белән яшәр, ин шә Аллаһ.

Хөрмәтле җәмәгать, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безгә, шәригатебездәге шушы кануннарны үтәп, Үзенең ризалыгын алып яшәүләребезне насыйп итсен!

* * *

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә дәүләт җитәкчебезнең саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Динар Зыятдинов,*

*ТР МДНнең «Зәкят» хәйрия фонды хезмәткәре*

*20нче октябрь вәгазе,*
*рабигыль-ахыр аеның 5нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Аллаһыга охшаган бер генә әйбер дә юк

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмииин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-Кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, безне, адәм балаларын, узенең иксез-чиксез нигъмәтләре белән нигъмәтләндереп торучы, бердән-бер булган хак хуҗабыз, гыйбадәткә лаеклы хак Илаһыбыз — Аллаһы Раббыбызга хәмед-сәнәләребез, мактау-олуглауларыбыз булсын.

Һәм дә галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән пәйгәмбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның әһлебәйтенә, сәхабә-кирамнарына безнең тарафтан салават-шәрифләребез, сәлам-догаларыбыз булсын.

Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ, мөхтәрәм дин кардәшләрем! Сезгә Аллаһы Раббыбызның сәламе, рәхмәте вә бәрәкәте булсын!

Иң бөек һәм яхшы гыйлем Аллаһы Раббыбыз турында. Иманның асылы — Аллаһыга дөрес итеп иман китерү. Мөселман кешесе Аллаһы Раббысын Аның исемнәре һәм сыйфатлары аша күбрәк белгән саен, Аның бөек Зат булганын аңлый, Аны күбрәк ярата башлый, Аның рәхмәтенә, мәгъфирәтенә күбрәк омтыла, Аның газабыннан курка һәм шуның белән гыйбадәтен, әхлагын яхшырта. Аллаһыны яхшырак белгән саен кушканнарын җиренә җиткереп үти һәм тыйганнарыннан тулысынча тыела. Аллаһы Тәгалә дә ул кешене ярата башлый.

Аллаһы Тәгалә турында гыйлемне каян алып була соң? Аллаһы Тәгалә турында үзебездән чыгарып сөйли алмыйбыз, бу — тыелган гамәл.

Иң элек, әлбәттә, Коръәни Кәримнән һәм Пәйгәмбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләреннән. Ләкин, җәмәгать, бу аятьләрне, хәдисләрне без үзебез генә укып аңлау түгел, ә танылган галимнәребезнең аңлатмаларына, тәфсирләренә мөрәҗәгать итү дөрес булыр.

Коръәндә мәгънәсе ачык булган мөхкәм аятьләр һәм мәгънәләре ачык булмаган, төрлечә аңлау ихтималы булган мүтәшабиһ, ягъни мәгънәләрен төрлечә аңлау ихтималы булган аятьләр бар. Шунлыктан, тиешенчә гыйлеме булмаган кеше аларны ялгыш аңларга мөмкин.

Аллаһы Раббыбыз болай дип әйтә:

هُوَ الَّذِي أَنزَلَ عَلَيْكَ الْكِتَابَ مِنْهُ آيَاتٌ مُّحْكَمَاتٌ هُنَّ أُمُّ الْكِتَابِ وَأُخَرُ مُتَشَابِهَاتٌ ۖ فَأَمَّا الَّذِينَ فِي قُلُوبِهِمْ زَيْغٌ فَيَتَّبِعُونَ مَا تَشَابَهَ مِنْهُ ابْتِغَاءَ الْفِتْنَةِ وَابْتِغَاءَ تَأْوِيلِهِ ۗ وَمَا يَعْلَمُ تَأْوِيلَهُ إِلَّا اللَّهُ ۗ وَالرَّاسِخُونَ فِي الْعِلْمِ يَقُولُونَ آمَنَّا بِهِ كُلٌّ مِّنْ عِندِ رَبِّنَا ۗ وَمَا يَذَّكَّرُ إِلَّا أُولُو الْأَلْبَابِ

«**Ул — сиңа** [тиңсез бер] **Китапны** [Коръәнне] **иңдерүче. Аның бер өлеше** [мәгънәләре ачык һәм төрлечә аңлау ихтималы булмаган] **мөхкәм аятьләр ки, алар — Китапның нигезе; янә** [төрлечә тәфсир кылыну мөмкинлеге булган] **башка — мүтәшабиһ аятьләр. Күңелләрендә** [хактан ялганга] **тайпылу булганнар фетнә** [чыгару] **теләге һәм мәгънә бирергә тырышулары белән аның** [Коръәннең] **мүтәшабиһ булган аятьләренә ияргәләр** [һәм үзләренчә бердәнбер чын хаклыкка дәгъва итәләр]. **Хәлбуки, аның мәгънәсен Аллаһыдан башка беркем дә белмәс. Гыйлемдә югары дәрәҗәгә ирешкәннәр исә: «Без аларга иман китердек,** [мөхкәм һәм мүтәшабиһ аятьләрнең] **бөтенесе** [дә сүзләрендә бернинди капма-каршылык булмаган]

**Раббыбыздан** [иңдерелгән]**», – дип әйтерләр. Акыл ияләреннән башкалар** [Коръәни Кәримдәге үгетләрне] **искә алмас».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:7

Аллаһы Раббыбыз беркемгә дә, бернәрсәгә дә охшаш түгел һәм АНы беркемгә дә охшатырга ярамаганын һәр мөселман кешесе белергә тиеш. Бу хакта Коръәндә Аллаһы Раббыбыз болай ди:

لَيْسَ كَمِثْلِهِ شَيْءٌ ۖ وَهُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ

**«Аңа** [Аллаһы Тәгаләгә] **охшаш бернәрсә дә юк** [Аның хатыны яки баласы бар дип уйлап та булмый]**. Ул —** [һәрнәрсәне] **Ишетүче,** [һәрнәрсәне] **Күрүче».**

«Әш-Шура / Киңәш», 42:11

Бу аять динебезнең бөек кагыйдәләреннән булып тора. Шуңа күрә Аллаһы Тәгаләнең аятьләрендә һәм Пәйгәмбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләрендә, «йәд» дип килгән очракта, кулны күз алдыбызга китерү һәм шуңа охшаш мәгънәдә аңларга ярамый. Гарәп телендә бу «йәд» дигән сүз кул дип тәрҗемә ителсә дә, без бу сүзне Аллаһы Раббыбызга карата һәм икенче аятьләрендә аңа охшаш булганнарны, гарәп телендәге туры мәгънәсендә алдарак әйткән аятьтәге кагыйдәгә таянып куллана алмыйбыз. «Кул» дип әйтсәк, без Аллаһны кешегә охшаткан булабыз , бу әйбер тыелган, чөнки Аллаһы Раббыбыз бернәрсәгә дә охшамаган.

Аллаһы Раббыбыз турында килгән мүтәшабиһ аятьләрдә Аны Аның мәхлукларына охшатмыйча, танылган галимнәрнең аңлатмасына мөрәҗәгать итү дөрес булыр, чөнки алар безгә мүтәшабиһ аятьләрне аңлаталар, күрсәтәләр.

Аллаһы Раббыбыз алган гыйлемнәр белән гамәл кылып, Аның рәхмәтенә һәм ризалыгына ирешергә насыйп итсен.

* * *

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә дәүләт җитәкчебезнең саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Ильяс хәзрәт Сабиров,*
*Казан шәһәренең «Өмет» мәчете имам-хатыйбы*

*27нче октябрь вәгазе,*
*рабигыль-ахыр аеның 12нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Хөсетлек — көчсезлек ул

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмииин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-Кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Галәмнәрне юктан бар кылып, безләрне халык иткән, тәрбияләгән Аллаһыга барча хәмед-сәнәләребез, олуглау-мактауларыбыз булсын. Һәм дә Мөхәммәд бине Габдулла — Аллаһының хак илчесе, тугры пәйгәмбәре, шәриф булган колы — Аллаһы аңа, аның гаиләсенә һәм аның сәхабәләренә Үзенең салават-шәрифәләрен бирсә иде. Ислам динебез тән һәм рухи яктан пакьлеккә өнди, әмма рухи чисталык тән чисталыгына караганда әһәмиятлерәк. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَوْمَ لَا يَنفَعُ مَالٌ وَلَا بَنُونَ ۞ إِلَّا مَنْ أَتَى اللَّهَ بِقَلْبٍ سَلِيمٍ ۞

**«Ул көндә малы вә баласы һичкемгә файда бирмәс. Мәгәр кеше мөшриклек вә монафикълык керләреннән күңеле пакь хәлдә чын мөселман булып килсә, аңа файда булыр».**

«Әш-Шүгәра / Шагыйрьләр», 26:88–89

Аллаһы Тәгалә Китабында калебкә күп тапкыр игътибар итә. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә үзенең хәдисендә болай дип әйткән:

«Дөреслектә Кыямәт көнендә Аллаһы сезнең тәннәрегезгә һәм сурәтләрегезгә карамас, ләкин сезнең калебләрегезгә карар»[1].

---

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Шулай ук Аллаһы рухи авырулардан кисәтә, чөнки аларның шәхескә һәм җәмгыятькә зарары тиядер, андый очракларда истигазә сүрәләрен укырга куша.

قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ الْفَلَقِ ۞ مِنْ شَرِّ مَا خَلَقَ ۞ وَمِنْ شَرِّ غَاسِقٍ إِذَا وَقَبَ ۞ وَمِنْ شَرِّ النَّفَّاثَاتِ فِي الْعُقَدِ ۞ وَمِنْ شَرِّ حَاسِدٍ إِذَا حَسَدَ ۞

«[Расүлем!] **Әйт: «Таңның Раббысына сыенамын. Ул яраткан** [кешеләр һәм җеннәрдән булган бөтен начар] **нәрсәләрнең зарарыннан.** [Караңгылыгы һәрнәрсә өстенә төшеп,] **Каплаган вакта куе караңгылык зарарыннан.** [Җепләргә ясаган] **Төеннәргә** [төкерә-төкерә] **өргән** [сихерче] **җаннарның зарарыннан да. Янә көнләшүченең көнләшкән чагындагы зарарыннан да».**

«Фәләкъ», 113

Кешеләр арасында бик күп рухи авырулар таралган: яманлык, көнләшү, ялган, бер-берсенә нәфрәт һәм башкалар. Үзебезгә теләгәннәрен кардәшләребезгә теләмәсәк, шул калеб авыруларыннан котылып булмас.

Шулар арасындагы иң куркыныч авыруларның берсе — ул көнчелек. Бу сыйфат аркасында кеше үзенә һәм башкаларга зыян китерә. Белгәнебезчә, дөньяда беренче гөнаһ шул сыйфат аркасында эшләнде. Адәм галәйһиссәламнең улы Кабил көнләшеп, үзенең бертуган кардәшен Һабилне үтерде. Бу сыйфат башка гөнаһларга юл ача һәм иң әүвәл якыннардан, дуслардан, күршеләрдән башланып китә. Янындагы көнләшүче беркайчан да якынының аннан өстен булуын яратмас. Туганының, кардәшенең, күршесенең малы, көче, гыйлеме, дәрәҗәсе, эше аннан яхшырак булуын сөймәс, бигрәк тә бер юнәлештә эшләүче сәүдәгәрләр. Гади эшчеләр арасында да көнләшү бар. Шуңа күрә искә төшерелгән төркемнәр арасындагы мөнәсәбәт начар булса, гаҗәп түгелдер, ул бары шул көнчелек нәтиҗәсе.

## Көнчелекнең сәбәпләре

Дөреслектә, көнчелек хисе тәкъдир һәм Аллаһының исемнәрен, сыйфатларын начар аңлаудан килеп чыга.

Тәкъва кеше башка кешеләргә карата көнчелек, күрә алмау хисе сакламый, чөнки һәрбер нәрсә Аллаһының Әл-Галим (һәр нәрсәне Белүче) һәм Әл-Хәким (Хикмәт иясе) дигән сыйфатлары белән бәйле.

Беренче сәбәп — көнләшкән кешегә ачу тоту, берәр бәла-каза килсә, шатлану, берәр яхшылык килсә, кайгыру. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

أَمْ يَحْسُدُونَ النَّاسَ عَلَى مَا آتَاهُمُ اللَّهُ مِنْ فَضْلِهِ فَقَدْ آتَيْنَا آلَ إِبْرَاهِيمَ الْكِتَابَ وَالْحِكْمَةَ وَآتَيْنَاهُمْ مُلْكًا عَظِيمًا

**«Йә ул** [яһүдләр] **кешеләргә хөсетлек кылалармы? Ул кешеләргә Аллаһы Үз фазыйләтеннән нигъмәтләр яки дәрәҗә биргәне өчен. Дөреслектә Ибраһим балаларына китап бирдек, Ислам диненең хөкемнәрен өйрәттек һәм зур байлык бирдек».**

«Нисә / Хатыннар», 4:54

Икенче сәбәп — тәкәбберлек һәм горурлык. Башкаларда яхшырак әйбер күреп, үзе аны булдыра алмаса, шуны яратмау. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَقَالُوا لَوْلَا نُزِّلَ هَذَا الْقُرْآنُ عَلَى رَجُلٍ مِنَ الْقَرْيَتَيْنِ عَظِيمٍ

**«Алар янә әйттеләр: „Ни булыр иде, әгәр бу Коръән Мәккә яки Таиф шәһәрендәге бер олуг дәрәҗәле бай иргә иңдерелгән булса“, — дип. Күрәсез, алар бай кешене гакыллы туры кешедән артык күргәннәр».**

«Зүхъруф / Зиннәтләнү», 43:31

Шулай ук Аллаһы Тәгалә түбәндәге аятьтә болай дип әйтә:

أَهَٰؤُلَاءِ مَنَّ اللَّهُ عَلَيْهِم مِّن بَيْنِنَا

**«Йә шул кешеләрне безнең арадан Аллаһы бүләкләдеме»**

«Әнгәм / Терлек», 6:53

Өченче сәбәп — идарәчелекне һәм алда булуны ярату: берәр нәрсәдә ул гына алда, беренче булуын теләү.

Дүртенче сәбәп — Аллаһының тәкъдиренә ачу тоту. Аллаһы башкаларга биргән нигъмәтләргә, үзендә ул күп булса да, көнләшеп карау.

Бишенче сәбәп — астыртын һәм саран булуы. Башкаларда бу нигъмәтләр булмасын дип теләү, башкаларда яхшырак әйбер күреп, кемнеңдер баерак, бәхетлерәк яшәвенә көнләшеп карау. Берәүләрнең ниндидер дөньяви нигъмәтләргә ия булуы ул кешедә: «Нигә анда бар, ә миндә юк», яисә: «Анықы бетеп, миндә барлыкка килсен иде», — дигән фикер тудыруы.

Кешеләрдә еш очрый торган әлеге сыйфат турында галимнәр: «Бу — куркыныч чир», — дип әйтәләр. Бик сирәк кеше генә бу чирдән котыла ала, чөнки адәм баласы табигате белән өстен булырга яратучы. Ул Аллаһы Тәгалә тарафыннан шулай яратылган. Күпләр бу авыру белән көрәшеп, аны җиңә ала, ә кемдер көрәшми дә, теләми дә.

Әнәс бине Мәликтән риваять ителә: «Көннәрдән бер көнне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, сәхабәләренә мөрәҗәгать итеп: «Хәзер шул ишектән сезнең яныгызга җәннәт белән шатландырылган бер кеше керер», — диде.

Әнәс бине Мәлик дәвам итә: «Дөрестән дә, яныбызга әнсарлардан бер кеше керде, һәм шул хәл өч көн дәвамында кабатланды. Шуннан соң мин, аңа ияреп, өч көн аның белән булдым, әмма безнең гамәлләрдән аерылып торган бер артык гыйбадәтен күрмәдем. Өч көн узгач, үзенә булган хәлләрне сөйләп бирдем, ул мине чакырып, болай дип әйтте:

أَنِّي لَا أَجِدُ فِي نَفْسِي عَلَى أَحَدٍ مِنَ الْمُسْلِمِينَ غِشًّا، وَلَا أَحْسَدُهُ عَلَى مَا أَعْطَاهُ اللَّهُ إِيَّاه

«Миндә башка мөселманнарга карата бернинди ачу һәм Аллаһы биргән нәрсәләргә көнчелегем юк».

Шуңа күрә, мөхтәрәм мөселманнар, көнчелек — ул кешенең көчсезлегеннән килгән сыйфат. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә безгә аннан котыла торган юлларны күрсәтеп калдырды:

1. Истигазә сүрәсен уку («Фәләкъ» сүрәсе).

2. Тәкъва булып калу. Тәкъва кеше башка кешеләргә карата көнчелек, күрә алмау хисе сакламый һәм аларның кайгы-хәсрәтләренә дә шатланмый.

3. Яратмаган кешеләргә сабыр итү, алар белән әрләшмәү, алар өстеннән зарланмау һәм аларга зыян китерә торган сүзләр әйтмәү.

4. Аллаһыга тәвәккәл итү. Бу сыйфат иң көчлесе булып тора, чөнки Аллаһыга тәвәккәл итү — Аллаһы язганы белән разый булып калу, начары да, яхшысы да Аннан дип тану. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

مَا أَصَابَ مِن مُّصِيبَةٍ إِلَّا بِإِذْنِ اللَّهِ وَمَن يُؤْمِن بِاللَّهِ يَهْدِ قَلْبَهُ وَاللَّهُ بِكُلِّ شَيْءٍ عَلِيمٌ

**«Кайгы, бәла-каза Аллаһының теләге белән генә иреште. Берәү итагать иткән хәлдә Аллаһыга иман китерсә, Аллаһы ул кешенең күңелен хаклыкка күндерер. Аллаһы һәрнәрсәне Белүче».**

«Тәгабүн / Алдану», 64:11

5. Күңелгә начар фикер кертмәү, аның турында уйламау.

6. Гөнаһлы фикер килгәндә тиз арада тәүбә итү. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَمَا أَصَابَكُمْ مِنْ مُصِيبَةٍ فَبِمَا كَسَبَتْ أَيْدِيكُمْ وَيَعْفُو عَنْ كَثِيرٍ

**«Ий, мөэминнәр, сезгә ирешкән бәла-казалар вә кайгылар үзегез кәсеп иткән гөнаһларыгыз сәбәпледер, шулай булса да Аллаһы гөнаһларыгызның күбрәген гафу итәдер».**

«Шура / Киңәш», 42: 30

7. Хәлдән килгәнчә садака бирү һәм изгелек кылу. Дөреслектә, аның тәэсире бик гаҗәеп, һәм ул бәла-казалардан һәм көнчелектән саклый.

8. Көнчелекле, яман, рәнҗетүче кешеләргә яхшылык күрсәтү. Әлбәттә, бу иң авыры. Начарлык күбрәк күрсәткән саен, күбрәк яхшылыклы булу. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَلَا تَسْتَوِي الْحَسَنَةُ وَلَا السَّيِّئَةُ ادْفَعْ بِالَّتِي هِيَ أَحْسَنُ فَإِذَا الَّذِي بَيْنَكَ وَبَيْنَهُ عَدَاوَةٌ كَأَنَّهُ وَلِيٌّ حَمِيمٌ ۞ وَمَا يُلَقَّاهَا إِلَّا الَّذِينَ صَبَرُوا وَمَا يُلَقَّاهَا إِلَّا ذُو حَظٍّ عَظِيمٍ ۞ وَإِمَّا يَنْزَغَنَّكَ مِنَ الشَّيْطَانِ نَزْغٌ فَاسْتَعِذْ بِاللَّهِ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ

**«Яхшылык белән явызлык бертигез булмаслар, чөнки яхшылыкка файда һәм савап бар, явызлыкка зарар һәм газап бар. Әгәр сиңа берәү явызлык кылса, син аңа җавап итеп яхшылык кыл, ул кеше сиңа явызлыкны дошманлык илә кыладыр, әмма син сабыр ит һәм дә аның явызлыгына каршы һәрвакыт изгелек ит, соңра ул синдә явызлыкның юклыгын белеп, явызлык итүеннән туктар һәм тәүбә итеп, синнән гафу сорар, аннары бер-берегезгә якын дус булырсыз. Ләкин бу эшне һәр кеше эшли алмас, мәгәр көчле иманлы, чын сабыр мөэминнәр генә эшли алырлар, вә явызлыкка каршы изгелек итү һәрбер кешегә бирелмәс, мәгәр олуг бәхетле кешегә генә бирелер. Әгәр явызлык итүчегә изгелек итәргә шайтан сиңа ирек бирмәсә, шайтанның шәреннән Аллаһыга сыгын,**

**Ул сине шайтан вәсвәсәсеннән саклар, аннары явызлыкка каршы изгелек итә алырсың. Аллаһы Ишетүче вә Белүчедер».**

«Фүссиләт / Аңлатылды», 41:34-36

9. Көнчелеккә китерә торган нигъмәтләрне яшерү. Аллаһы Ягъкуб галәйһиссәлам турында болай дип әйтте:

وَقَالَ يَا بَنِيَّ لَا تَدْخُلُوا مِنْ بَابٍ وَاحِدٍ وَادْخُلُوا مِنْ أَبْوَابٍ مُتَفَرِّقَةٍ وَمَا أُغْنِي عَنْكُمْ مِنَ اللَّهِ مِنْ شَيْءٍ إِنِ الْحُكْمُ إِلَّا لِلَّهِ عَلَيْهِ تَوَكَّلْتُ وَعَلَيْهِ فَلْيَتَوَكَّلِ الْمُتَوَكِّلُونَ

**«**[Аларның] **аталары әйтте: «Ий, угылларым, Мисырга җиткәч барыгыз да бер капкадан кермәгез, төрлегез төрле капкалардан керегез!** [Бөтенегезне бергә күреп, сезгә күз тидермәсеннәр] **Аллаһыдан килгән бәла-каза хакында берни белергә дә, сезгә ярдәм итәргә дә хәлемнән килмидер, һәр эш өстеннән хөкем йөртүче Аллаһыга хастыр, шуңа баш июдән башка чара юк, мин Аллаһыга тәвәккәл иттем һәм тәвәккәл итүчеләр Аллаһыга гына тәвәккәл итсеннәр!»**

«Йосыф», 12:67

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дип әйтә:

«Үзегезнең эшләрегездә уңышлы булыр өчен, яшерү белән ярдәм сорагыз, дөреслектә, нигъмәт ияләренә көнчелек тиядер».

* * *

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә дәүләт җитәкчебезнең саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Илмир хәзрәт Хәсәнов,*

*Буа районы имам-мөхтәсибе, Буа мәдрәсәсе мөдире*

*3нче ноябрь вәгазе,*

*рабигыль-ахыр аеның 19 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Күрше милләт вәкилләре белән тату яшәү

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмииин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-Кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Галәмнәрне юктан бар итеп, безгә җан биреп, безне төрле халыклар вә милләтләр буларак халык кылып һәм шушы җирдә безгә тыныч-тату яшәргә боерып, һәрберебезгә Үзенең киң рәхмәтләрен-ризыкларын тәкъдир кылган Аллаһы Тәгаләгә дан-мактауларыбыз булса иде. Шулай ук галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән, бөтен милләт вә халыкларга рәхмәт булып, хакыйкатьне, нурны алып килгән Расүл Әкрам Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифәләребез булса иде.

Хөрмәтле җәмәгать, әссәламү галәйкум вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтуһ!

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм соңгы хаҗы вакытында сөйләгән вәгазендә:

«Гарәп булган кешенең гарәп булмаудан һәм гарәп булмаган кешенең гарәп кешесе өстеннән, ак тәнле кешенең кара тәнледән, кара тәнленең ак тәнледән бернинди өстенлеге юк. Аллаһы Тәгалә каршысында хакыйкый өстенлек — ул тәкъвалык, ягъни тәкъва кеше генә Аллаһы Тәгалә каршысында бөек, олы дәрәҗәгә ия», – дип әйтә.

Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәламне халык кылгач, аның нәселе бөтен җир шарына таралып, шул җир шарында яши башлый. Төрлебез төрле: кемдер кара чәчле, кемдер сары; кемдер кара тәнле, кемдер кызыл — һәммәбез

дә кешеләр. Милләтләр, дәүләтләр төрле булса да, күбебезне Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән нәрсә дә булса берләштерә. Әмма иң мөһиме — без бөтенебез дә адәм балалары. Ягъни Аллаһы Тәгалә һәммәбезне халыклар, адәм балалары итеп халык кылган. Һәм Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм шушы дөньяга бөтен халыкларга рәхмәт буларак Ислам дине белән килде. Һәрберебез бу дөньяда кемнеңдер газиз баласы, Аллаһы Тәгаләнең газиз бер коллары, ягъни бәндәләре.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُم مِّن ذَكَرٍ وَأُنثَى وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوبًا وَقَبَائِلَ لِتَعَارَفُوا إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ

**«Ий, кешеләр! Һичшиксез, Без сезне** [Адәм исемле] **бер ирдән һәм** [Хава исемле] **бер хатыннан ярапттык.** [Һәммәгезнең дә ата-анасы бер булганга күрә, нәсел-чыгыш белән мактануның ни мәгънәсе бар?] **Без сезне** [бер-берегезгә уйламый-нитми теләсә ни сөйләр өчен түгел] **танышуыгыз өчен кавемнәр һәм кабиләләр иттек. Аллаһ хозурында иң кадерлегез —** [иң асыл нәселдән булганнарыгыз түгел, Аллаһы Тәгаләнең харамнарыннанан сакланган] **бик тә тәкъвалык иясе булганыгыз. Һичшиксез, Аллаһ —** [һәрнәрсәне] **Белүче,** [һәрнәрсәдән] **Хәбәрдар».**

«Әл-Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:13

Әмма адәм баласының төп максаты нәрсә дигәндә, Аллаһы Тәгалә «Әл-Мүльк» сүрәсенең 2нче аятендә әйтә:

الَّذِي خَلَقَ الْمَوْتَ وَالْحَيَاةَ لِيَبْلُوَكُمْ أَيُّكُمْ أَحْسَنُ عَمَلًا وَهُوَ الْعَزِيزُ الْغَفُورُ

**«Ул, сезнең кайсыгыз гамәлләренә күрә күркәмрәк булуын сынар өчен, үлемне һәм тереклекне яратты** [сезнең кылачакларыгыз хакында әзәли гыйлемен уртага чыгарачак, соңыннан Үзенең гыйлеменә

күрә түгел, кылганнарыгызга күрә әҗерләрегезне бирәчәк]**. Ул — Бөек** [Җиңелмәс]**,** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче».**

«Әл-Мүльк / Хөкемдарлык», 67:2

Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә безнең нәрсә кылганыбызны һәм нәрсә кылачагыбызны белә, ләкин, безнең нинди кеше икәнебезне һәм нәрсә эшләгәнебезне Кыямәт көнендә гамәлләребезгә карата әҗерен бирер өчен, безнең гамәлләребезне бу дөньяда ук бүтән халык-ларга, бүтән кешеләргә күрсәтә. Кешелек тарихында, кызганычка, бик күп сугышлар, канкоешлар, бик күп начар вакыйгалар булып узган. Һәм адәм баласының эчке дөньясын күрә торып, без әле мондый кызганыч хәлләр киләчәктә дә булырга мөмкин, дип әйтә алабыз.

Ни өчен адәм балалары төрле канкоешлар, төрле бозык юлларга кереп китә? Күпчелек очракта, бу — адәм баласының наданлыгы. Икенче бөтендөнья сугышын гына алыйк. Моның төп сәбәбе нәрсәдә? Җавабы: бер халыкның үзен икенче халыклардан өстен куюы. Әмма бу бик гөнаһлы гамәл, чөнки, әйтелгәнчә, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: «Гарәп булган кешенең гарәп булмаганыннан өстенлеге юк». Гарәп булса да, гарәп булмаса да, кара тәнле булса да, ак тәнле булса да, адәм баласының иң мөһим күрсәткече — иманлы булуы.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм заманында бер сәхабә икенче сәхабәгә «кара хатынның углы», дип әйтә. Кара тәнле булган Билал радыяллаһу ганһегә: «Син кара хатынның углы», — дип әйткәч, Билал радыйаллаһу гәнһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына барып, шушы сүзләрне җиткерә. Шуннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шушы сүзләрне әйткән сәхабәгә: «Синдә әле җәһиллек калган, ягъни син әле камиллеккә, гыйлемгә, мәгърифәткә ирешмәгәнсең, чөнки син Аллаһы Тәгаләнең шушы мәхлугын кимсетәсең», — дип әйтә.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә «Әт-Тин» сүрәсендә болай дип әйтә:

لَقَدْ خَلَقْنَا الْإِنسَانَ فِي أَحْسَنِ تَقْوِيمٍ

**«Без кешене иң күркәм сурәттә яралттык».**

«Әт-Тин», 95:4

Ягъни һәрбер адәм баласына Аллаһы Тәгалә матурлык, күңел дөньясын, тышкы кыяфәтен, аяк-кулны, сиземләүне, шатлану, көенү, эчке дөньяны бирде. Шуңа күрә кешенең бүтән бер затны рәнҗетергә, кимсетергә хакы юк. Аллаһы Тәгалә Ислам динен шушы җиргә милләтләр, халыклар, кешеләр, гомумән, бер-берсе белән яхшы мөнәсәбәттә яшәсеннәр өчен җибәрде. Шуңа күрә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әле синдә җәһиллекнең, наданлыкның караңгылыгы калган ди. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәрвакытта да халыклар арасында, ягъни Аллаһының мәхлуклары арасында татулык булдыруны зур бер максат итеп куя торган булган. Әгәр дә тарихка күз салсак, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинә шәһәренә күчеп килүгә, андагы халыклар белән килешү төзи: үзара яхшы мөнәсәбәт-мөгамәлә, бер-береңне яклау, бер-береңне саклау — шул солыхның иң төп принциплары була. Һәм шушы килешү галимнәр тарафыннан бүгенге көндә «Мәдинә конституциясе» дип йөртелә башлый, чөнки бу дөньядагы иң камил, иң яхшы килешү була. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Нинди генә милләт, нинди генә диндә булуына карамастан, бер кеше бер кешене рәнҗетми, кимсетми», чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һиҗрәт кылган вакытта Мәдинә шәһәрендә яһүдиләр дә, насаралар да, гарәпләр дә, гарәп булмаучылар да, Бәни Исраил кавеме дә, төрле илләрдән килгән кол дәрәҗәсендә булучылар да, кол булмаучылар да яши. Шуларның һәрберсенең мәнфәгатен кайгыртып, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм килешү төзи. Әлбәттә, шушы килешүне бозган өчен мөселманнарга килешүне бозган халыкны чыгарып җибәрергә туры килә. Бу бик гадел була, чөнки солыхта бер-берсе белән тату яшәргә килешенгән була. Шулай ук дошман килсә, бергә шушы җирлекне яклыйбыз

дип сөйләшәләр, ләкин шушы солыхны Бәни Исраил кавеме боза. Шуннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһы Тәгаләнең әмере белән шушы халыкка Мәдинә шәһәреннән чыгып китәргә куша.

Һәрбер халык үзенең милләте, мәдәнияте һәм дине белән яши. Мөселман кешесенә шушы халыкларны рәнҗетү, кимсетү, гомумән, аларның диннәрен, мәдәниятләрен кимсетү тыела. Аллаһы Тәгалә хәтта Мәккәдә булган мөшрикләрнең потларын да сүкмәскә куша, чөнки алар җавап итеп Аллаһы Тәгаләне сүгәрләр ди. Ягъни диннәр, бигрәк тә Ислам дине, җир йөзенә тынычлык алып килү өчен иңдерелә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәтта, үзенең өй каршысына чүп атып йөргән яһүди авырып киткәч, аның хәлен белергә керә. Ягъни Ислам дине булган җирдә, мөселманнар яшәгән урында, әгәр алар тәкъва, иманлы, гыйлемле, мәгърифәтле булсалар, бүтән халыкларны хөрмәт итәләр, алар белән яхшы мөнәсәбәттә яшиләр. Мисалга XX гасырны алыйк, милләтчелек, ягъни бер милләтнең икенче милләт өстеннән үзен өстен куюы аркасында бик күп кешеләр корыла, миллионлаган халыкның каны коела, гомере өзелә. Һәм бу безгә зур бер дәрес — бер-берсе белән яхшы мөнәсәбәттә яшәп, бер-беребезгә карата хөрмәт күрсәтергә тиеш.

Безнең җирлектә, ягъни Татарстанда да бик күп төрле милләтләр яши. Элек-электән шушы җирлегебездә төрле кешеләр килеп яшәп, эшләп көн күрәләр. Һәм без мөселман буларак бу кешеләргә дә хөрмәт, яхшы мөнәсәбәт белән карыйбыз. Аларга яхшы мөнәсәбәт белән, тәрбияле, әхлаклы, әдәпле мөнәсәбәт күрсәтәбез. Әгәр дә мөселман кешесе бүтән кешегә, аның милләтенә, диненә һәм бүтән бер кимчелек белән, йә булмаса аның дөньяга булган карашы өчен аның белән орышса, сугышса, бу мөселманның, димәк, тәкъвалыгының дәрәҗәсе бик зәгыйфь, тәкъвалыгының көче-кодрәте әле түбән дәрәҗәдә икәнен күрсәтә.

Ислам диненең төп бер принцибы булып үзара һәм бүтән халыклар белән яхшы мөнәсәбәт корып яшәү тора. Әгәр Ислам тарихына күз салсак,

Ислам дине таралуы вакытына игътибарыбызны юнәлтсәк, Ислам диненең күп җирләргә килүе вакытына, мөселманнар, бүтән илләргә Ислам дине килгәч, бер генә чиркәүне дә җимермиләр, ишмиләр, ватмыйлар һәм бүтән халыклар белән шунда ук килешү төзиләр. Әгәр мөселманнар яши торган Ислам җирлегенә карасак, анда без бик күп чиркәүләр, бүтән дин әһелләренең, бүтән дин вәкилләренең гыйбадәтханәләрен, бүтән телләрдә сөйләшкән, бүтән мәдәнияттә яшәүчеләрне күрә алабыз. Шулай ук безнең җирлектә дә бик күп халыклар, төрле мәдәният, төрле мирас белән яшиләр.

Татар халкында бу элек-электән таралган шундый зур бер гореф һәм динебезнең нигезе: кем генә керсә дә, кем генә килсә дә, яхшы мөгамәлә, якты йөз күрсәтү. Әгәр дә элек нинди дә булса юлчы бер авыл үтсә, нинди дә булса йортка килсә, аны һәрвакыт сыйлап, яхшы мөнәсәбәт күрсәтеп чыгарганнар. Шушы гадәт безнең нигезгә салынып, безнең тәрбиягә сеңеп, бүгенге көнгә кадәр күпләребезнең шушы тормышларында урын алып тора.

Атабыз Адәм галәйһиссәламне Аллаһы Тәгалә балчыктан яралта һәм аның нинди мәхлук булуын Коръәни Кәримдә ассызыклап үтә, чөнки мөселман кешесе белә, хәтта Адәм галәйһиссәламгә фәрештәләр дә баш игән. Аның гыйлеме зур булган, хәтта Аллаһы Тәгалә аның тәүбәсен дә кабул кылган. Һәм без менә шушы олы затның, акыл иясенең балалары. Шул сәбәпле без үзебезнең акылыбызны, иманыбызны һәрвакытта дөреслэп, һәрвакытта үсешкә илтергә тиеш. Мөселман кешесе аларга һәрвакыт ярдәм итәргә тиеш. Тирә-юньдәгеләрнең милләтенә, диненә, карашларына карамастан, хәтта бу кеше бернәрсәгә ышанмаса да, инанмаса да, ул аларга ярдәм итәргә тиеш, чөнки бүгенге көндә без бик күп хәдисләр, аятьләр сөйли алабыз, галимнәрнең тормышыннан булган вакыйгаларны китерә алабыз, әмма дә ләкин ярдәмебез, гамәлебездә шушы Аллаһы Тәгалә биргән хикмәт булмаса, бу кешеләр, әлбәттә, Ислам диненә килмиләр. Әгәр дә без аятьләрнең һәм хәдисләрнең динебезнең матурлыгы хакында сөйләп, үзебезнең гамәлләребездә шушы чагылмаса, бу

кешеләр Ислам диненә, әлбәттә, килмәячәкләр. Алар безнең сүзләребезне, гамәлләребезне икейөзлелеккә саныячаклар. Шуңа күрә, әгәр дә без үзебезнең динебезнең матурлыгын күрсәтергә һәм Аллаһы каршысына баскач: «Йә Раббым! Мин Синең динеңне иң матур яктан күрсәтергә тырыштым!» – дип әйтәсебез килә икән, без һәрвакытта, әлбәттә, Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән, бөтен эшләребезне, гамәлләребезне изге кылырга тиешбез. Кешеләргә карата яхшы мөнәсәбәттә, ягъни бүтән милләт вә дин вәкилләренә дә яхшы мөгамәләдә булырга кирәк. Тарихка күз салсак, мондый вакыйгалар, мондый хәлләр бик күп, чөнки Бөек Ватан сугышы вакытында да, бүтән вакыйгаларда да мөселманнар үзләренең җирләренә, дәүләтләренә һәрвакыт ярдәм иткәннәр. Шулай ук мөселманнарга да бүтән милләт вәкилләре ярдәм итеп яшәгән. Шушындый хәл-вакыйгаларны без һәрвакыт булдырып, без Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешеп яшәргә тиеш.

Без һәммәбез дә Аллаһы каршысына билгеле бер рәвештә киләчәкбез. Кыямәт көнендә Расүлебез  салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: «Бөтен кешеләр бер халәттә килерләр», — ди. Монда инде кешенең милләте, дине булмас, ә кешенең хакыйкатьтә яшәгәнме-юкмы — шул мөһим булачак. Димәк, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте илә бәрәкәтебез, җәмәгать, бер-беребезгә карата яхшы мөнәсәбәттә булуыбызда. Аллаһы Тәгаләгә якын булып яшәргә тырышабыз икән, Аллаһы Тәгалә рәхмәтенә ирешәчәкбез. Нинди генә кеше булса да, нинди генә милләттән булса да, нинди генә дин вәкиле булса да, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтүенчә, мөселман кешесенең кулыннан, теленнән, уй-фикерләреннән бүтәннәр куркыныч көтмиләр. Ягъни аның эшләгән гамәлләре, Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән, зур бер ышанычлы, әманәтле гамәлләрдер, чөнки Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм «Әмин», мөселман кешесе дә шул сыйфатка омтылырга тиеш. Шушы сыйфат, шушы зур бер хикмәткә омтылып, Аллаһы Тәгалә рәхмәтенә омтылырга тиеш. Әгәр дә без үзара тату яшәмибез икән, шушы безгә бирелгән тормы-

шыбыз, җирлегебезне дөрес итеп кулланымыйбыз икән, ахыр чиктә, Аллаһы каршысына баскач, без моның өчен җавап тотачакбыз.

Кемдер имам, кемдер гади мөселман, кемдер укытучы, кемдер машина йөртүче — һәрберебез көн саен изгелек кыла алабыз. Һәм һәрберебез көн саен төрле кешеләр, төрле холыктагы һәм рухи дәрәҗәдәге кешеләр белән очрашабыз. Һәм һәр адәм баласы да Аллаһы Тәгалә өчен кадерледер. Бу дөньяда без һәммәбез дә Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән яшәп, аның рәхмәте, ризалыгы белән, ризыгын ашап яшибез, һәм Ахирәткә баргач, кемнең күңелендә иман булды, кем хакыйкый диндә булды, шушы кешенең генә Аллаһ алдында бер дәрәҗәсе калачак. Әгәр дә Аллаһы рәхмәте белән зур бер хикмәт иясе булырга теләсәк, Аллаһыга якын бәндә булырга теләсәк, без һәрвакытта да үзебезнең тормышыбызны тирә-юнебездәге кешеләргә яхшы мөнәсәбәт-мөгамәлә корып, тормышыбызны калганнарга изгелек кылырга юнәлтергә тиешбез.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә үзенең үрнәгендә күрсәтте: нинди генә кеше булса да, нинди генә милләт яисә дин вәкиле булса да, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте вә ризалыгы белән аңа яхшы мөнәсәбәт, яхшы мөгамәлә күрсәтә иде. Ул Китап әһелләренә карата яхшы мөнәсәбәт корырга боера иде, ятим, мескен һәм фәкыйрьләргә ярдәм итәргә боера иде.

Бүгенге көндә дә мөселманнар шушы эшне дәвам итәләр. Нинди генә кеше, нинди генә халык булса да, нинди генә бәла-каза килсә дә, мөселман кешесе һәрвакытта калганнарга ярдәм кулы сузырга тырыша, алар белән яхшы мөнәсәбәт корып, яхшы сүзләр сөйләшеп, Аллаһының рәхмәтенә ирешергә тырыша.

***

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә дәүләт җитәкчебезнең саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Алмаз Галимҗанов,*
*Саба районы имам-мөхтәсибенең*
*яшьләр белән эшләү буенча ярдәмчесе,*
*Сатыш авылы мәчете имам-хатыйбы*

*10нчы ноябрь вәгазе,*

*рабигыль-ахыр аеның 26нчы көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Психология — бүгенге көн бәласеме?

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барлык галәмнәрне юктан бар кылучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед-сәнәләребез, мактауларыбыз, шөкерләребез булса иде. Пәйгамбәрләрнең соңгысына, пәйгамбәрләрнең таҗы булган, күркәм әхлак үрнәге булган, безгә бәхет-сәгадәт, шатлык-сөенеч юлын өйрәтеп калдырган, «Минем юлым белән барсагыз, һич адашмассыз, саташмассыз, үкенмәссез», — дип әйтеп калдырган пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм рух-шәрифенә салават-сәламнәребезне ирештерсәң иде. Сезгә дә, газиз дин кардәшләрем, шушы нурлы җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең йортына килеп, Аңа изгелекләр, гамәл-гыйбадәтләр белән якынаю юлын булдырырга теләгән, ниятләгән һәм: «Шушы изгелек белән йөрәкләребезне нурландырыйк әле», — дип җыелышканнарга Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте булсын. Аллаһы Тәгалә бик күп гыйлемнәр бирде, кешеләрне гыйлем белән башка мәхлуклардан аермалы итте һәм шул ук мизгелдә Аллаһы Тәгалә кайбер гыйлемнәрне бирмәде. Ул гыйлемнәрнең берсе турында Коръәндә болай дип әйтелә:

وَيَسْأَلُونَكَ عَنِ الرُّوحِ ۖ قُلِ الرُّوحُ مِنْ أَمْرِ رَبِّي وَمَا أُوتِيتُم مِّنَ الْعِلْمِ إِلَّا قَلِيلًا

**«Алар синнән рух хакында сорыйлар. Әйт: «Рух — Раббымның** [«Бар бул!» дигән] **әмереннән** [яралтылган нәрсәләрдән]**. Сезгә исә гыйлемнән аз бер өлеш кенә бирелде».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:85

Аллаһы Раббыбыз безгә кайбер гыйлемнәрне чикләде. Кайбер гыйлемнәр алар акыл белән түгел, ә күңел, җан, рух белән кабул ителергә тиеш. Бүгенге көндә бик күп кешеләр шаккатырлык дәрәҗәдә төркем-төркем психологиягә мөрәҗәгать итә башладылар. Кая карама, бөтенесенең психолог буласы килә, берәр проблема булса, капчык-капчык акча, маллар сарыф итеп, алар тизрәк психологка чаба, тормышта килеп туган проблемалардан чыгу юлы, сорауларга җавап эзлиләр. Әмма Коръәндә, хәдисләрдә безнең динебездә ул сорауларыбызга бушлай җавап бар. Без аларны куллана гына белмибез яки, кызганыч, үзебезнең динебезне белеп бетермибез.

Психология — ул җан халәтен өйрәнә торган фән, дип аңлатыла. Әлбәттә, без алдагы аятьтә әйттек, Аллаһы Тәгалә җан турында бик әз мәгълүмат бирде, хәтта юк диярлек дәрәҗәдә. Менә шушы психология белән бик күп уйланып, фикерләп, бүгенге көндә психологиядә бераз үзгәреш тә күренде: кешеләр күбрәк чит илләрдән килгән, диннән ерак булган халәтне өстен куя. Әмма психологияне төбеннән, борынгыдан карасак, хәтта безнең мөселман галимнәребез Әл-Газали, Әл-Бәлхи, Әл-Кинди, зур-зур галимнәребез, алар шушы психология фәне төзелгәндә үк иң беренче алар үз өлешләрен керттеләр. Билгеле галимебез Ибне Сина үзенең китапларында психосоматика турында яза. Ягъни кеше рухи яктан кирәкмәгән уй-фикерләргә бирешеп, үз-үзенә зыян китерә ала. Психосоматика — тән белән җанның тыгыз бәйләнешен аңлата. Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Безнең тәндә шундый әгъза бар, сау-сәламәт, чиста, пакь хәлендә булса, тәнебез дә шулай ук сау-сәламәт, куәтле, нык хәлдә булыр. Әгәр дә ул әгъза зәгыйфь, авырту, сырхау икән, бөтен тәнебез дә шулай ук авырту булыр», — дип килә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дәвам итеп: «Чыннан да, бу — калеб», — ди. Күп кенә галимнәр йөрәкне йөрәк дип кенә түгел, ә җан дип тә әйтәләр. Җаны, рухы сау-сәламәт булса, ул вакытта аның тәне дә сәламәт булыр, әгәр дә кеше үзенең җанын кайгыртмаса, намазда, гыйбадәттә булмаса, Аллаһы Тәгалә

белән тәгәл мөгамәләдә булмаса, ул вакытта иртәме-соңмы аның тәненә дә төрле чирләр килә башлый.

Кул белән тотып алырлык хәлдә булмаса да, алар бар. Бүгенге көндә бик күп таралган чирләрнең берсе — ул депрессия. Кешенең тамагы тук, яшәргә йорты бар, эшләргә эше бар, гаиләсе, машинасы, туганнары бар. Җир йөзендә ничәмә кеше: «Эх, булсын иде!» — дип хыялланып яткан тормышның, бу дөньяның ләззәтләре һәм рәхәтлекләре бар, сөенеп яшә! Ләкин кеше депрессиягә бирелә. Төп сәбәпләрнең берсе — нәкъ тә шушы калебнең авыру, сырхау хәлендә булуы. Мәсәлән, бүгенге көндә: «Менә шундый рәсемле күлмәк алыр идем», — дип кешеләр 3–4 сәгатьләр буе вакытын шуңа сарыф итә. Ләкин көненең 10–15 минут вакытын догада, зикердә, Коръән уку белән үткәрсә, ул ярты сәгать аңа бер гасыр кебек тоела башлый. Хәтта бер танышым: «Хәзрәт, миңа бер камаз ком бушатырга әйтсәләр, чабып барам, әгәр дә шул ук мизгелдә ике сәгать догада, зикердә утыр дисәләр, ул шулкадәр авыр булып тоела, хәтта бер камаз ком да минем өчен, минем нәфесемә җиңелрәк кебек тоела», — дип әйтә. Ул дөресен әйтә, чөнки, чыннан да, кешенең кияргә киеме, ашарга ризыгы, яшәргә йорты бар, ләкин җан сырхау хәлендә ул киемнең дә, машинаның да ләззәте, шатлыгы, сөенече югала башлый. Кешенең рухы, җаны сырхау хәлендә. Шул вакытта кешеләр психологларга мөрәҗәгать итә башлый. Шөкер, бүгенге көндә динне яхшы белгән хәзрәтләр арасында да психологияне өйрәнеп, кешеләргә дини яктан да, фән ягыннан да ярдәм итә алган кешеләр бар. Аллаһы Тәгалә алардан һәм һәрбарчабыздан да разый булсын. Әгәр дә психолог диннән ерак булса, ул очракта алар, киресенчә, кешенең җанын дәвалау урынына, адаштырырга да мөмкин. Мәсәлән, гаиләне татулаштыру, ныгыту урынына, киресенчә, аларның бер-берсенә каршы чыгуына сәбәпче дә булырга мөмкиннәр. Психологлар шуның белән аерылып торалар. Мөселман кешесенә шундый табиб янына барасы була икән, чын белгеч, үз эшенең профессионалына мөрәҗәгать итәргә тиеш.

Көннәрдән бер көнне Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләдән болай дип сораган:

— Йә, Раббым, авырулар, сырхаулар кайдан килгән?

Аллаһы Тәгалә әйткән:

— Авырулар, сынаулар Миннән — ди.

Ибраһим галәйһиссәлам соравын дәвам итеп:

— Йә, Раббым, шушы авыруларга шифа кайдан килә? Кайдан аласы?

Аллаһы Тәгалә:

— Миннән, авыруларга шифа Мин бирәм, — дип җавап биргән.

Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә тагын бер сорау бирә:

— Авыруы да, шифасы да Синнән булгач, нәрсәгә соң безгә табиблар?

Аллаһы Тәгалә әйтә:

— Мин авыруга карата шифасын табиблар, белгечләр, галимнәр кулына салырмын һәм алар аша шифасын эзләгән кешеләргә бирермен, — ди.

Ягъни без белгеч сайлаган очракта, чын хакыйкый галим булган, үз фәнен, юнәлешен белгән, тәҗрибәле килеш Аллаһы Тәгалә юлында булган, Раббыбыз белән элемтәсе нык булган психологны сайларга тиешбез. Ул үзенең фәнен белүе белән һәм Аллаһы Тәгалә юлында булуы белән кешегә ярдәм иткәндә дә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә, нурына ирешергә тырышучы, сөю хисләрен уятучы булса иде. Шушы сыйфатка ия була торган булсалар иде. Тарихка карасак, VIII гасырда хәтта тарихи китапларда Багдадта психиатрия клиникалары ачылуы турында әйтелә. Безнең галимнәребез Әл-Кинди, Әл-Бәлхи шушы юнәлешкә үзләренең бик зур өлешләрен кертә торган булганнар.

Хөрмәтле җәмәгать, үземнең бер танышымның да халәтен сезгә сөйләп үтәсем килә. Ул материаль яктан бик бай кеше, шушы депрессия башлангач, ул бик танылган, телевидениеда кешеләр арасында чыгыш ясый торган психолог янына бара. Барып, хәйран гына акча сарыф итә. Мин дә, аның белән күрешеп, сөйләшеп, аңа догалар бирдем: шулар сәбәпле ул тынычланды.

Берникадәр вакыт узганнан соң теге психолог янына баруның файдасы турында сорадым. «Нинди киңәшләрен үтәдең соң?» — дип сорагач, ул: «Бер киңәшен дә үтәмәдем, аны үтәсәң, әшсез, хатынсыз ялгызың гына каласың һәм, аны тыңласаң, үзең генә бәхетле булырсың. Үзеңне генә карарга кирәк, үзеңнең фикереңне әйтергә, үзеңнең теләгеңне генә үтәргә тиешсең. Минминлеккә генә өйрәтте ул мине. Аның кушканнарын үтәсәм, хатынсыз, баласыз, дусларсыз калырмын дип аңладым да, вакытында үземне тыйдым, дин юнәлешендә, Аллаһы юлында үземә, калебемә, җаныма тынычлык, шифа таптым», — дип әйтеп куя.

Хөрмәтле җәмәгать, зур галимнәр әйтүенчә: «Аллаһы Тәгалә үз урынында, ягъни безнең өчен иң беренче урында, күңел түрендә, калебебездә, күңелебездә, уй-фикеребездә булса, калганнары үз урыннарына баса. Әгәр дә күңелебездә, телебездә, уй-фикерләребездә Аллаһы Тәгалә булмаса, Аның ризалыгына омтылу булмаса, ул вакытта калганнары да үз урынында була алмас, таралып китәр. Чын хакыйкый бәхет — ул Аллаһы Тәгалә белән тыгыз элемтәдә булу.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә барчабызга да күңел тынычлыгы насыйп итсен, калебләребез сау-сәламәт булсын. Аллаһы Раббыбыз нурлары белән балкып торган күңелләребез, йөрәкләребез булса иде.

* * *

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә дәүләт җитәкчебезнең саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Солтан хәзрәт Морадимов,*

*Казан шәһәренең «Рамазан» мәчете имам-хатыйбы*

*17нче ноябрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 3нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Тапланган йөрәк ни белән куркыныч?

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмииин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-Кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Аллаһы Раббыбызга күңел түрләребездән чыккан, ихластан булган зикер, тәсбих, догаларыбызны, олуглауларыбызны, шөкерләребезне җиткерәбез. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, шулай ук күңел түрләребездән чыккан салават һәм сәламнәребезне әйтәбез. Һәрбарчабызга да Аллаһының сәламе, бәрәкәте, рәхмәте булсын. Ошбу җомга көнебез мөбарәк булсын. Җомга көннең фазыйләтләренә, дәрәҗәләренә Аллаһы Раббыбыз вәгъдә иткән, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән әҗер-савапларга, фазыйләтләргә ирешергә насыйп булсын.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, мәхәллә халкы! Ошбу җомга көнебездә, җомга вәгазебез йөрәкнең чисталыгы — йөрәк турында; җаныбызның чисталыгы — җан турында булыр. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең олуг бер нигъмәтләренең берсе — безгә, кешеләргә, тормыш итү, яшәү нигъмәтен бирде. Без яшәгән вакытта җаныбыз һәм тәнебез белән яшибез, гомер кичерәбез. Тәнебезнең бер өлеше авыртып китсә, шифалап, кадерләп яшибез; тамагыбыз ачса, ризык сораганын сизеп, аны ризыкландырабыз; тәнебез туңса, җылытырга икәнне беләбез; эссе икән, юкаракны киябез. Аллаһы Тәгалә биргән әманәтебезне — шушы тәнебезне саклыйбыз, кадерлибез,

хөрмәтлибез. Әйе, болар барысы да — безнең бурычыбыз, динебезнең олуг бер кагыйдәседер. Ләкин мөселман кешесе болар белән генә чикләнми, безнең «җан» дигән төшенчәбез дә бар. Без аның үлчәмен, авырлыгын белмәсәк тә, җаныбызның барлыгын барчабыз да беләбез. Калебне дә ниндидер бер эчке әгъза яки ит кисәге итеп кабул итү түгел, адәм баласының шушы йөрәген, калебен дә Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә биргән икән, без дә аны чиста һәм төзек хәлдә сакларга тиеш булабыз. Безнең тәнебез, киемебез пычранган кебек, кешенең йөрәге дә, калебе дә пычрана.

Хөрмәтле җәмәгать, моннан чыгып, шуны әйтергә кирәк: тәннәребез турында кайгырткан кебек, җаннарыбыз, йөрәкләребезне дә кайгыртырга тиешбез. Җаннарыбызның нинди хәлдә булулары турында кайгырту, аның нинди хәлдә булуы бездән соралыр. Аллаһы Раббыбыз шушы җанны безгә төзек, матур, чиста хәлдә тапшырды. Ягъни адәм баласы дөньялыкка килгәч, шушы сабый балага нинди күркәм сурәттә, аңа шушы җанны урнаштырып, аны камил рәвештә яратты. Әмма кайдадыр тәрбия җитмәү, кайдадыр Аллаһы Тәгаләне танымау сәбәпле, иң беренчедән, шушы тәннәребезгә, иң мөһиме, җаннарыбызга зыян кылырга, аны пычратырга, авыруга сабыштырырга мөмкинбез. Бу очракта, мөселман бәндәсенә шушы җаннарны юктан бар кылган, аларга нәрсә яхшы, нәрсә начар икәнен белгән Аллаһы Раббыбызның сүзен, Аның әйткәнен тыңлап, шушы тәннәребезне чиста һәм матур хәлдә саклау тиешле була. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә безгә моның турында ачыктан-ачык хәбәр итә:

يَوْمَ لَا يَنفَعُ مَالٌ وَلَا بَنُونَ ۞ إِلَّا مَنْ أَتَى اللَّهَ بِقَلْبٍ سَلِيمٍ

«[Хәерле юлда сарыф ителсә дә] **Бер малның да,** [шәфәгать итә алырлык дәрәҗәдә булган] **улларның да** [беркемгә] **файда бирмәгән көнне. Мәгәр** [көферлек һәм монафикъannлык кебек хасталыклардан тәмам котылып] **керсез күңел белән Аллаһыга килүче булмаса гына».**

«Әш-Шүгәра / Шагыйрьләр», 26:88–89

Ягъни Аллаһы Тәгалә әлеге аятьтә кешегә изге гамәлләреннән һәм чиста йөрәгеннән кала берни дә булышмаячагын әйтә. Бары тик чиста калеб кенә ярдәмгә килер. Аллаһы Тәгаләнен Хаклыгын хак итеп таныган, Аның сүзләреннән тайпылмаган, Аның барлыгын, берлеген белеп яшәгән калеб иң зур файда китерер. Шушы калебең ни дәрәҗәдә чиста, төзек, авырулардан пакь булса, шул дәрәҗәдә файда китерер. Йөрәкне чиста хәлдә саклап яшәү — ул мөселман кешесенең олуг бер бурычыдыр.

Шулай ук, хөрмәтле җәмәгать, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә:

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ عَنْ رَسُولِ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ : إِنَّ العَبْدَ إِذَا أَخْطَأَ خَطِيئَةً نُكِتَتْ فِي قَلْبِهِ نُكْتَةٌ سَوْدَاءُ ، فَإِذَا هُوَ نَزَعَ وَاسْتَغْفَرَ وَتَابَ سُقِلَ قَلْبُهُ ، وَإِنْ عَادَ زِيدَ فِيهَا حَتَّى تَعْلُوَ قَلْبَهُ ، وَهُوَ الرَّانُ الَّذِي ذَكَرَ اللَّهُ ( كَلاَّ بَلْ رَانَ عَلَى قُلُوبِهِمْ مَا كَانُوا يَكْسِبُونَ ) .

«Әгәр адәм баласы гөнаһ кылса, йөрәгендә кара тап барлыкка килә, әгәр гөнаһын калдырып, тәүбә кылса, Аллаһы Тәгалә шушы тапны чистартыр. Ләкин адәм баласы шушы гөнаһны кабатлап, гөнаһлары күбәйгәннән-күбәя икән, аның калебен кара тап каплап алыр», — ди.

كَلَّا ۖ بَلْ ۜ رَانَ عَلَىٰ قُلُوبِهِم مَّا كَانُوا يَكْسِبُونَ

> **«Юк!** [Бу бозык бәндәнең сүзе һич дөрес түгел!] **Кылган** [начар] **нәрсәләре** [һәм рәттән эшләгән гөнаһлары] **аларның йөрәкләрен** [мәгънәви бер] **тутык белән каплаган».**
>
> «Әл-Мутаффифин / Киметеп үлчәүчеләр», 83:14

Беренчедән, адәм баласының көндәлек кылган гамәлләре аңа авырлык китерергә, аның йөрәгендә кара таплар калдырырга һәм аны авыруга дучар итәргә мөмкин икән.

Икенчедән, шул аңлашыла: кеше гөнаһ кылган саен, шул пычрак арта һәм, гади әйберне чистарткан яки пычрак килеш калдырган кебек, йөрәкне дә пычрак хәлдә калдырсак, ул пычрак юа алмаслык дәрәҗәгә җитәргә мөмкин. Шуңа күрә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: «Әгәр дә кеше гөнаһта дәвамлы икән, гөнаһтан кире кайтмыйча, тәүбәгә килмичә, наданлыкта, имансызлыкта, Аллаһы Тәгаләне танымыйча яшәсә, аның шушы тап артканнан-артып, калебе капланыр», — дип әйтә.

Өченчедән, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә йөрәкне юктан бар кылды һәм нәрсә аны чиста хәлдә тотарга ярдәм итәчәген дә аңлатты. Шуны аңларга кирәк. Ул да булса — кылган гөнаһыңны калдырып, тәүбә-истигъфарда булсаң, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә калебеңне чистарта икән.

Тагын бер хәдисендә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Әгәр дә адәм баласы гөнаһ кылганнан соң тәүбә итсә, ул гөнаһ кылмаган дәрәҗәдә булыр». Ягъни Аллаһы Тәгалә каршында үз хатасын аңлап, чын күңелдән тәүбәгә килсә, Аллаһы Тәгалә кабул итсә, аның калебе яңадан чистара.

Дүртенчедән, шушы хәдистән аңларга тиешле әйбер — ул калебнең катылануы, аның каплануы: адәм баласының калебе яхшылыкны ишетми, күрми, аңламый башлый. Безнең халкыбызда: «Бу бәндәнең йөрәге катты», — дигән сүз бар. Димәк, ул кеше яхшы сүзне ишетми, изге гамәлләрне күрми башлый. Бу иң куркынычыдыр. Аллаһы Тәгалә безне шушы халәттән сакласа иде. Адәм баласы шушы дөньялыкта, тормыш иткән рәвешендә, калебенең торышына, аны кайгыртмаса, тора бара ул капланып, Аллаһы Тәгалә сүзен ишетми, йөрәгенә үткәрә алмый башларга мөмкин. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәндә дә бу турыда болай дип әйтә:

وَلَقَدْ ذَرَأْنَا لِجَهَنَّمَ كَثِيرًا مِّنَ الْجِنِّ وَالْإِنسِ ۖ لَهُمْ قُلُوبٌ لَّا يَفْقَهُونَ بِهَا
وَلَهُمْ أَعْيُنٌ لَّا يُبْصِرُونَ بِهَا وَلَهُمْ آذَانٌ لَّا يَسْمَعُونَ بِهَا ۚ أُولَٰئِكَ كَالْأَنْعَامِ
بَلْ هُمْ أَضَلُّ ۚ أُولَٰئِكَ هُمُ الْغَافِلُونَ

**«Без җеннәрдән һәм кешеләрдән күбесен** [көферлектә калуны сайлаганнарын белгәнебезгә күрә, аларны] **җәһәннәм өчен яралттык. Аларның йөрәкләре бар,** [әмма] **алар** [шул йөрәкләре] **белән** [хакыйкатьне] **аңламаслар. Аларның күзләре бар,** [ләкин] **алар белән күрмәсләр. Аларның колаклары бар,** [тик] **алар белән ишетмәсләр. Алар** [төшенү җитмәү, гыйбрәт алмау һәм фикерләп тыңламау ягыннан] **хайваннар кебек. Хәтта алар ныграк адашкан. Алар —** [Аллаһыны онытткан] **гафил кешеләр».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:179

Хөрмәтле җәмәгать, безнең калебләребезне нәрсә чистарта соң? Чыннан да, тәннәребезне, калебләребезне, җаннарыбызны юктан бар кылган Аллаһы Раббыбыз әйткән әйберләр, Аның кушканнары, Аның әйткән сүзләре безнең калебләребезгә шифа, дәва һәм чисталык бирәдер. Динебезне, Раббыбыз кушканнарны үтәп яшәү йөрәкләребезне төзек һәм дөрес хәлдә тотуга ярдәм итә икән. Гомумән әйткәндә, без Аллаһы Тәгалә биргән шушы йөрәк-калебебезне төзек хәлдә саклыйсыбыз килсә, юктан бар кылып, тәннәребезгә җаннарыбызны урнаштырган Аллаһы Раббыбызның сүзләрен тыңлау, Аның кушканнарын үтәү, Ул кушканча яшәү кирәк дип әйтер идек. Ләкин: «Нәрсәләр эшләргә була соң?» — дип әйткәндә, беренчесе, Аллаһы Тәгалә каршында шушы калебләребезне, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисендә әйтелгәнчә, тәүбә-истигъфар, зикердә, Аллаһы Тәгаләне олуглау, шөкер итү кирәк буладыр. Адәм баласы белеп яки белмичә, кайдадыр аңлап җиткермичә, онытылып, ялкауланып, ялгышлыкта булырга мөмкин. Барча адәм баласы да ялгышырга мөмкин, ләкин, ахыр чиктә, Пәйгамбәребез

саллəллаһу галəйһи вə сəлләм әйткәнчә: «Адәм баласы хаталанучан, ә иң хәерлегез, хатасын аңлап, тәүбәгә килеп, кичерү сораучыгыз», — диде. Шуңа күрә, без, иң беренче, Аллаһы Раббыбыз каршында ялгыш, хаталы гамәлләребез өчен гафу сорап, калебләребезне чистарту кирәк буладыр. Калебләребезне саф хәлгә китергәннән соң, без шушы чиста «савытларыбызны» саф, чиста әйбер белән генә тутыру кирәк була. Ягъни, изге гамәл, Аллаһы Тәгалә сүзләре — Коръәни Кәрим, нинди генә вакыт булмасын: авыр вакытыбызда да, җиңеллек булганда да Аллаһы Тәгаләне зикер итү белән үткәрсәк, Раббыбызга шөкер итсәк, шушы калебләребез чиста, саф әйбер белән тулыр. Чыннан да, күз алдыбызга китерик: чиста савытка чиста әйберләрне салган кебек, йөрәкне дә чиста әйберләр белән тутырсак, калебебез дә төзек, чиста булыр. Калеб җан белән бәйле булса да, аның тәнебезгә дә тәэсире бар. Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

الَّذِينَ آمَنُوا وَتَطْمَئِنُّ قُلُوبُهُم بِذِكْرِ اللَّهِ ۗ أَلَا بِذِكْرِ اللَّهِ تَطْمَئِنُّ الْقُلُوبُ

**«Алар — иман китергән һәм күңелләре Аллаһыны зикер итү белән** [бөтен буталчыклардан, шик-шөбһәләрдән котылып] **тынычланган кешеләр. Күңелләр Аллаһыны зикер итү белән тынычланмыймы?»**

«Әр-Рагъд / Күк Күкрәү», 13:28

Чыннан да, күп вакытта төрле-төрле юллар белән күңел тынычлыгы эзлибез. Мәсәлән, без матди әйберләрне күргәч, сатып алгач, ашагач-эчкәч, дөнья нигъмәтләрен күргәч, тынычланган кебек булабыз, ә асылда, тынычлану — Аллаһы Тәгаләне һәрдаим истә тоту, зикер итүдер.

Без калебләребезне чистартып, Аллаһы Тәгаләне зикер итеп, Аның каршында тәүбә итеп, сафлык һәм чисталык белән тутырып, аны тотып тора торган, калебебезне дә, җаныбызны да тәрбияләп тора торган гамәлләребезгә керешсәк иде. Шул гамәлләребездә дәвамлы булсак, җаннарыбыз да, тәннәребез дә пакь булыр.

Гамәл дигәндә, шушы Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәргә тырыш, намазларыңны торгыз, уразаларыңны тот, хәерле гамәл кылуда дәвамлылык ит һәм, чыннан да, әлеге гамәлләрең калебеңә ярдәм итәр. Бу Аллаһы Тәгаләне зикер итәргә, Аны гел күңелдә йөртергә ярдәм итәдер. Шуңа күрә дә Аллаһы Тәгалә каршында чиста күңел, чиста калеб белән булыр өчен тәүбә-истигъфарда булыйк. Иртән торганда, кич ятканда шушы тәүбәләребезне кылып яшик. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Мин көненә җитмеш мең истигъфар кылам, Аллаһыдан кичерү сорыйм», — диде. Без дә, җәмәгать, хаталанган, ялгышкан булсак, Аллаһы Тәгаләдән кичерү, ярлыкау сорыйк. Кичерү сораганнан соң, чистартканнан соң, Аллаһыга зикерләребезне әйтик, Аллаһының сүзләре белән калебләребезне яхшылык белән, сафлык белән тутырыйк. Шушы саф калебләребезгә ныклык керсен һәм шул хәлдә калсын өчен, без Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып, гамәл-гыйбәдәтләребездә дәвамлы булып яшәсәк, калебләребез чиста, саф хәлдә булыр.

Кемдер: «Мин моны кайчан да булса эшли алам, бүген булмаса, иртәгә, 3–4 елдан яки пенсиягә чыккач, калебемне чистартырга вакытым булыр, хаталарымны, гөнаһларымны кылып яшим әле, соңрак тәүбәгә килермен», — дип вакытның узганын көтеп, үз-үзен тынычландырып йөрергә мөмкин. Ләкин, җәмәгать, беркем дә ахыргы сулышы кайчан икәнен белми. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә каршында төзек калебләр белән җавап бирергә насыйп әйләсен. Адәм баласы, мөселман кардәшем, әгәр дә шушы төзек булмаган калебең белән Раббың каршына килеп басуны һәм Аның каршына килүгә без әзер булырга тиешлегебезне белеп яшәргә тиешбез. «Булыр әле, вакыт җитәр әле», — дип үзеңне тынычландыру гына түгелме? Шушы калебең белән Аллаһы Тәгалә хозурына күчсәң, нәрсә дип җавап бирерсең? Моның турында да уйлану кирәктер. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Кеше ничек яшәгән, шул рәвешле Аллаһы Тәгаләгә күчә», — ди. Хөрмәтле җәмәгать, көн тудымы, кич яттыкмы — Аллаһыны

зикер итик. Шушы рәвешле калебләребезне чиста хәлдә тота алсак, без сөенербез. «Аллаһыга шөкер, мин мөселман, Син миңа биргән калебне зикер-тәсбих белән тутырдым, аны чистарттым, төзек хәлдә Сиңа тапшырам», — дип Аллаһы каршына килсәк, хәерлесе шул булмасмы? Хөрмәтле мөселманнар, шушы тәннәребезне саклаган кебек, калебләребезне дә сакласак иде. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә каршына Ул разый була торган хәлдә килеп бассак иде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм кебек Аллаһыга дога кылыйк: «Йә Раббым, Үзеңнең динеңдә мине ныгыт». Аллаһы Раббыбыз һәрбарчабыздан да разый булсын!

* * *

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә дәүләт җитәкчебезнең саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Инсаф хәзрәт Ибатуллин,*

*Казан шәһәренең «Динислам» мәчете имам-хатыйбы*

*24нче ноябрь вәгазе,*
*җөмәдәл-әүвәл аеның 10нчы көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Ата-ана хакы

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир рахмәә-нир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмииин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-Кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Чиксез рәхмәте белән безне бертуктаусыз тәрбияләп торучы, безгә һидәять бүләк итүче, барлык галәмнәр Раббысы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә ихлас олуглауларыбыз, мактауларыбыз булсын. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның газиз гаиләсенә, хөрмәтле сәхабәләренә сәламнәребез, салават-шәрифләребез ирешсә иде.

Бүген, иншәАллаһ, үтә дә әһәмиятле мәсьәләне күтәрербез, кардәшләрем. Күз алдыгызга китерегез: бервакыт олуг сәхабә Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһе Кәгъбәтуллаһ янында Йәмәннән килгән бер мөселманның, карт әнисен җилкәсенә утыртып, хаҗ кылуын күргән. Ә бит элекке заманнарда кешеләр хаҗга, бүгенге кебек, җиңел генә, очкычларда очып, кондиционерлар кабызып килмәгәннәр. Читен юллар, эссе чүлләр үтеп, авырлыклар белән килгәннәр. Әнисен өстенә утырткан бу хаҗи, Кәгъбә тирәли тәваф әйләнгәндә, шундый сүзләр кабатлаган: «Мин — әнием өчен хәрәкәт итү чарасы булган мескен бер дөя». Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһене күреп, әлеге кеше тукталган һәм аннан болай дип сораган: «Бу гамәлем белән мин әнием хакын үти алдыммы?»

Шушы урында тукталып, олуг сәхабәнең җавабына кадәр, әйдәгез, ата-ана хакы турында уйланыйк. Әбү Һөрәйра радыяллаһу ганһедән ки-леп ирешелгән бик күпләргә таныш хәдис бар. Бервакыт бер мөселман

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп сораган: «Йә Аллаһының илчесе, минем яхшы мөгамәләгә иң лаеклы кеше кем?» «Синең әниең», — дип җавап кайтарган Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм. «Ә аннан кем? — дигән кеше. «Синең әниең». «Ә аннан кем?» — дип сораган мөселман. «Синең әниең», — дип янәдән җавап биргән Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм. Кеше дүртенче тапкыр соравын кабатлагач кына, сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Синең әтиең», — дигән. Карагыз, кардәшләрем, барлык президентлардан, байлардан, иң якын туганнардан, дуслардан иң-иң өстен дәрәҗә — әниебездә. Аннан — әтиебездә. Моны һәрчак истә тоту бик мөһим. Әти-әниләребезне санламасак, дөньябызны да, Ахирәтебезне дә югалтабыз, Аллаһы Тәгалә үзе сакласын.

«Әл-Исра» сүрәсенең мәшһүр 23нче аятендә Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безгә ата-ана хакы турында бәян итә:

وَقَضَىٰ رَبُّكَ أَلَّا تَعْبُدُوا إِلَّا إِيَّاهُ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا ۚ إِمَّا يَبْلُغَنَّ عِندَكَ الْكِبَرَ أَحَدُهُمَا أَوْ كِلَاهُمَا فَلَا تَقُل لَّهُمَا أُفٍّ وَلَا تَنْهَرْهُمَا وَقُل لَّهُمَا قَوْلًا كَرِيمًا

> **«Раббың сезгә Үзеннән башкаларга табынмаска, ата-анага игелек** [кылырга] **әмер итте.** [И, кеше!] **Аларның икесеннән берсе яки икесе дә синең янында картлыкка ирешсә, аларга** [канәгатьсезлек белдереп]**: «Уф!» — дип тә әйтмә.** [Сүз-гамәлләре сиңа ошамаса да] **Аларга кычкырма, күркәм сүз әйт».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:23

Бу аятьне Раббыбыз Үзенең берлегеннән, Үзенең дәрәҗәсеннән, Үз хакыннан башлый! Аллаһыдан башка без беркемне дә, бернәрсәне дә хуҗа буларак күрергә тиеш түгелбез! Аллаһы хакы белән янәшә әти-әниләребезнең хакы килә, аларга игелек кылырга боерыла, димәк, бу мәсьәлә шундый ук дәрәҗәдә мөһим дигән сүз! Аятьтә ата-ананың олыгайган көннәре турында ассызыклана. Картайгач, кеше зәгыйфьләнә, сабыйлыкка кайта. Мәсәлән, үзе

ашый, йөри, үз йомышларын үти алмаска, онытучанлыктан бер үк тарихны көненә дистәләгән мәртәбә сөйләргә мөмкин. Бу гамәлләрне кечкенә нарасый эшләсә, без ачуланмыйбыз бит, шулаймы? Менә әти-әниләребезгә карата да, бигрәк тә картайган көннәрендә, үтә дә сабыр, игътибарлы булуны таләп итә Раббыбыз. Һәр баланың вазифасы бу. Моны үтәмәсәк, Аллаһы кушканга каршы килгән булабыз. «Уф!» сүзе барлык канәгатьсезлекне үз эченә ала. Без әти-әниләребездән нинди дә булса канәгатьсезлек күрсәтсәк, бу шул «Уф!» була инде. «Уф», — дию дә ярамагач, башка, тупасрак мөнәсәбәт, аңлашыла ки, Аллаһы тарафыннан катгый тыелган.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән:

أَلاَ أُنَبِّئُكُمْ بِأَكْبَرِ الْكَبَائِرِ؟ الإِشْرَاكُ بِاللّٰه و عُقُوقُ الْوَالِدَيْنِ.

«Зур гөнаһлардан иң зурысы — Аллаһыга ширек (тиңдәш кылу) һәм ата-ананы тыңламау». Ягъни әти-әниеңне тыңламау, аларның сүзләренә хилафлык күрсәтү — ширек кадәр җирәнгеч эш! Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм шул рәвешле кешеләргә бу мәсьәләнең бик әһәмиятле булуын, ата-ана хакына җитдилек һәм җаваплылык белән карарга кирәк икәнен белдергән.

Әти-әниеңне тыңламаудан да зуррак нәрсә — аларны ачулану, аларга кычкыру! Бүген, кызганыч, мондый хәл — еш күзәтелә торган гадәти күренеш. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бервакыт болай дип әйткән: «Кем үзенең әти-әнисен сүгә, шул кеше ләгънәт кылынган». Сәхабәләр заманында ата-анага ихтирам нык көчле булган. Шуңа күрә алар бу сүзләргә: «Ничек инде алай, кеше үз әти-әнисен сүгә аламы?» — дип бик аптыраганнар, шаккатканнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сүзен болай дәвам иткән: «Берәр кеше башка кешенең әти-әнисен сүгеп, тегесе, моны ишетеп, аның әти-әнисен сүксә, ул үз әти-әнисен сүгүгә сәбәпче була». Димәк, әлеге хәдистә әле үз әти-әнисенә тавыш күтәрү турында гына сүз бармый, башка кешенең әти-әнисен сүгеп, аның баласы синекен сүксә, бу

үз әти-әниеңне ачулану кебек килеп чыга икән. Ата-ана хакы никадәр нечкә мәсьәлә булуы моннан ачык күренә.

Кызганыч, ләкин без өлкәннәргә карата итагатьсезлек заманында яшибез. Үз илебездә генә дә меңләгән картлар йорты исәпләнә. Кайбер кешеләр, картлык көненә җиткән газиз әти-әниләрен тәрбияләүне авырсынып, шушы йортларда ташлап калдыра. Ата-ана хакы үтәмәүнең иң куркыныч дәрәҗәсе шул буладыр. Ә без әти-әниләребезне игътибарсыз калдырсак, хәлләрен белешмәсәк — бу ташлауның кечерәйтелгән мисалы түгелме?!

«Әл-Исра» сүрәсен дәвам итеп, 24нче аятендә Раббыбыз болай боера:

وَاخْفِضْ لَهُمَا جَنَاحَ الذُّلِّ مِنَ الرَّحْمَةِ وَقُل رَّبِّ ارْحَمْهُمَا كَمَا رَبَّيَانِي صَغِيرًا

**«Мәрхәмәтлектән алар алдында тыйнаклык канатын җәй һәм** [кяфер булсалар да, һидаятькә ирешүләрен Аллаһыдан сорап]**: «Ий, Раббым!** [Минем фани мәрхәмәтем нәрсә генә ул?] **Алар кечкенә чагымда мине** [зур бер шәфкать белән] **үстергәннәре кебек, Син дә аларга** [бакый рәхмәтең белән] **мәрхәмәт ит», — дип әйт».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:24

Бездән әти-әниләребезне борчымау, шөкерле, яхшы бала булырга тырышу таләп ителә. Һәм бу мөбарәк аятьне Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безгә дога өйрәтеп тәмамлый:

رَّبِّ ارْحَمْهُمَا كَمَا رَبَّيَانِي صَغِيراً

**«...Ий, Раббым!... Син дә аларга** [бакый рәхмәтең белән] **мәрхәмәт ит...»**

Ягъни, әти-әни өчен шул доганы кылу — Аллаһы Тәгаләнең боерыгы! Шушы изге доганы иң кадерле, иң газиз, иң дәрәҗәле кешеләребез өчен көн саен, намаз саен кылыйк, кардәшләрем.

Хәтта ата-анабыз вафат булганнан соң да, безнең өстә аларның хаклары кала. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу турыда төгәл

җавап биргән: «Балалар нишләргә тиеш соң? Әти-әни өчен һәрдаим дога һәм истигъфар кылып торырга, васыятьләрен үтәргә һәм аларның якыннары, кардәшләре белән аралашуны матур итеп дәвам итәргә, саклап торырга тиешләр. Бу — ата-ананың, үлгәч тә, бала өстендә кала торган хаклары».

Инде вәгазь башында телгә алынган Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһе тарихына кайтыйк. Йәмәннән хаҗга әнисен алып килгән, аны җилкәсенә утыртып тәваф кылдырган мөселманга олуг сәхабә ана хакын үтәү турында ни дип җавап биргән? «Юк, үтәмәдең. Бу гамәлең белән әниең сине карынында йөрткән вакытта кичергән бер тулгагын да каплый алмадың», — дигән ул. Әйе, әниләрнең хакы аеруча зур, кардәшләрем. Газиз әниләребез безгә эндәшкәндә, безне чакырганда, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәтта нәфел намазны да өзәргә кушкан бит.

Җәмәгать, ата-ана хакы турында сөйләшкәндә, Кыямәт көне турында искә төшереп китик, никадәр хәвефле булачак ул! Кешеләр исерек кебек йөрерләр, ләкин исерек түгел, куркудан шундый хәлдә булырлар. Һәркем үзен генә кайгыртыр, үз хөкеме өчен борчылыр. Бу дөньяда баласына соңгы кисәген биреп торган әти-әниләр шушы дәһшәтле көндә үз балаларыннан качып йөрерләр, чөнки изгелек-саваплары үзләренә җитәме-юкмы икәнен белмәсләр. Шушы аяусыз көндә кайбер ата-аналар: «Син безнең хакларыбызны үтәмәдең», — дип балаларының якасына ябышыр!

Гәрчә ата-ана хакын үтәү алай ук авыр эш булмаса да, бик күп балалар шундый хәлдә калырлар, Аллаһы сакласын. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Борыны белән җирне сөрсен шул кеше — кемнең әти-әнисе олыгайган көнгә җитте, ә ул (шул сәбәпле) Җәннәткә керә алмады!» Ягъни картайган ата-анаң хакын үтәү — Оҗмахка керү форсаты! Һәм бу шул кадәр җиңел мөмкинлек. Аны да башкара алмыйча, Җәннәттән колак каксаң, үзеңне генә гаепләргә кала! Ата-ана хакы бик биек урында торса да, аны башкару алай ук авыр түгел. Ихлас ярату, игътибар, сабырлык, итагать һәм бу Аллаһының әмере икәнен аңлау гына кирәк.

* * *

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә дәүләт җитәкчебезнең саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Фәрид хәзрәт Мөдәрисов,*

*Алабуга шәһәренең «Әҗмәл» мәчете имам-хатыйбы*

*1нче декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 17нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Авырлыклар, авырулар вакытында сабырлык

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмииин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-Кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Дөреслектә, авырлыклар — кешегә Аллаһы Тәгаләдән бирелгән нигъмәттер. Мөэмин-мөселман кешесе авырлыкларны шулай итеп кабул итә. Болар барысы да — Аллаһы Тәгаләнең олы рәхмәте һәм колларына карата бер нигъмәте. Башка кеше әлеге сүзләрне ишетеп: «Ничек миңа килгән кайгы-хәсрәт Аллаһының нигъмәте булсын?» — дип гаҗәпләнә. Ләкин мөселман авырлыкны Аллаһы Тәгаләнең колына биргән рәхмәте итеп кабул итә. Әгәр дә Коръәни Кәрим белән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Сөннәтенә мөрәҗәгать итсәк, әлеге мәсьәлә ачыктан-ачык күренә. Хак Раббыбыз Аллаһы Тәгалә, төрле сүрә — аятьләрдә төрле пәйгамбәрләрне һәм изге кешеләрне зикер итеп, алар вакытында булган, аларның өммәтләренә, үзләренә килгән кайгы-хәсрәтләр турында безгә хәбәр бирә. Мәсәлән Әюб галәйһиссәлам тарихы. Әюб галәйһиссәлам — олуг пәйгамбәрләрнең берсе. Аллаһы Тәгалә аны Коръәни Кәримдә бер генә тапкыр искә ала. Бу — зур галәмәт. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә күп икән, димәк аның дәрәҗәсе зур.

Аллаһы Тәгалә «әл-Әнбия» сүрәсенең 83нче аятендә әйтә:

وَأَيُّوبَ إِذْ نَادَىٰ رَبَّهُ أَنِّي مَسَّنِيَ الضُّرُّ وَأَنتَ أَرْحَمُ الرَّاحِمِينَ

**«**[Расүлем!] **Әюбне дә** [галәйһиссәлам] **искә ал]! Менә ул** [каты чир белән авырып, еллар буена сабыр иткәннән соң, намазга тора алырлык та көч таба алмагач] **Раббысына** [дога белән] **эндәште: «Һичшиксез, миңа бер зарар кагылды. Син исә мәрхәмәтлеләрнең иң мәрхәмәтлесе».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:83

Әюб галәйһиссәламгә зур кайгы килә: аның тәне чери, кортлар чыга башлый, янында чыдап булмаслык ис тарала. Моңа кадәр зур нигъмәтләрдә яшәсә дә, Аллаһы Тәгалә аңа шундый сынау, кайгы җибәрә. Риваятьләрдә китерелгәнчә, Әюб галәйһиссәлам 18 ел дәвамында авырый. Җаны тәнендә була, үлми, тәне үлектән дә начаррак була. Кешеләр түзә алмыйча, аны шәһәрдән чыгаралар, ягъни ул кешеләрдән читтә була. Янында фәкать бер генә кеше кала — хатыны. Әюб галәйһиссәламнең хатыны өчен дә бу — бик зур фетнә, авырлык, сынау, имтихан. Ул аны шушы еллар дәвамында бер дә ташламыйча карый, юа, үзе күтәреп йөртә. Шушы ис булуга карамастан, аны тәрбияләп, бер дә яныннан китмичә, тугры булып кала, бөтен яшьлеге аның, янында уза.

Әгәр дә хәзерге заманда без: «Бөтен гомерем шушы кайгы-хәсрәттә узды», — дип әйтсәк, шушы Әюб галәйһиссәламнең хатынының сабырлыгына, түзем булуына карыйк. Әюб галәйһиссәламнең сабырлыгы зур, хатынының сабырлыгы да ким түгел. Аллаһы Тәгалә бу мәсьәләне еллар узганнан соң хәл итә.

Аллаһы Тәгалә Әюб галәйһиссәламгә әйтә:

ارْكُضْ بِرِجْلِكَ ۖ هَٰذَا مُغْتَسَلٌ بَارِدٌ وَشَرَابٌ

**«Аягың белән** [җиргә] **тип!** [Ул әмеребезне үтәгәч, чишмә бәреп чыкты]**. Бу салкын су — коеныр һәм эчәр өчен»** [дидек]**».**

*«Сад», 38:42*

Әюб галәйһиссәлам юынып, яшәреп киткән була. Тәненнән чыккан бөтен кортлар — барысы да кыйммәтле мәрҗән, алмаз кебек ташларга

әверелә. Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә аны бай итә. Хатыны да янында кала. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә бөтен булган әйберләрен кайтара. Ягъни бу мәсьәләдә озак тукталып тормыйча, безнең өчен нинди мисал булуын карап китик: Аллаһы Тәгалә һәрбер очракта да тели икән — булдыра, тели икән — үзгәртә ала, авыруларга шифасын бирә, теләсә — бу дөньда ук әҗер-савабын бирә һәм Ахирәттә тагын да күбрәк. Бу дөньяда кеше көчле авырудан вафат булса, аның шәһит булып китүенә өметләнәбез.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм эч авыруыннан вафат булучының шәһит икәнен хәдистә болай дип әйткән:

«Иман китергән биш төр кеше җәннәтле булыр: 1) ваба чиреннән; 2) эч авыртуыннан вафат булучы; 3) суда батып; 4) җимерелү нәтиҗәсендә аста калып вафат булучы; 5) үзенең иле һәм дине өчен гомерен бирүче».[1]

Аллаһы Тәгалә безгә, адәм балаларына Әюб галәйһиссәлам мисалында сабырлык үрнәген күрсәтә, чөнки шайтан күпме генә тырышса да, котыртса да, 18 ел авыру вакытында күпме генә вәсвәсәләр булса да, Әюб галәйһиссәлам түзә һәм зур дәрәҗәгә ирешә. Ул — Аллаһы Тәгаләнең сөйгән пәйгамбәрләренең берсе. Ничәмә миллионлаган, миллиардлаган кеше арасыннан,  Аллаһы Раббыбыз Әюб галәйһиссәламне аерым искә ала. Әгәр дә безгә берәр кайгы-хәсрәт килсә, без үзебезгә үрнәк итеп пәйгамбәрләребезне алабыз, чөнки Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәндә әйтә:

لَّقَدْ كَانَ لَكُمْ فِي رَسُولِ اللَّهِ أُسْوَةٌ حَسَنَةٌ لِّمَن كَانَ يَرْجُو اللَّهَ وَالْيَوْمَ الْآخِرَ وَذَكَرَ اللَّهَ كَثِيرًا

> **«Сезнең өчен** [бигрәк тә] **Аллаһыга һәм Соңгы көнгә өмет баглаган һәм** [курку, теләү, муллык һәм тарлык кебек бөтен хәлләрендә] **Аллаһыны күп итеп искә алган кешеләр өчен Аллаһының расүлендә (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) күркәм үрнәк бар».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:21

[1] Әл-Бохари, Мөслим

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә:

إِنَّما الصَّبرُ عِند الصَّدمَةِ الأُولَى

«Чын сабырлык иң беренче мизгелдә күренә», — дигән.[1]

Кайгы-хәсрәт хәбәре килгәч, сабырлык, шул ук мизгелдә, хәбәрне ишетүгә, кеше үз-үзен ничек тотуыннан күренә.

Шул вакытта кеше Аллаһы Тәгаләнең Коръәни Кәримдә китергән шушы сүзләре белән мөрәҗәгать итсә:

الَّذِينَ إِذَا أَصَابَتْهُم مُّصِيبَةٌ قَالُوا إِنَّا لِلَّهِ وَإِنَّا إِلَيْهِ رَاجِعُونَ

**«Берәр бәлагә юлыкканнар: «Һичшиксез, без — Аллаһыныкылар һәм Аңа гына кайтачакбыз!» — дип әйтәләр».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:156

Аллаһы Тәгалә, һичшиксез, күпмедер вакыт узгач, аңа җиңеллек бирәчәк. Бөтен кайгы-хәсрәтен, шайтан вәсвәсәсен, нәрсә генә булуына карамастан, барысына да үзенең рәхмәтен бирәчәк һәм адәм баласы шушы тормышның авырлыгын үткәрәчәк. Аллаһы Раббыбыз барчабызга да шушындый күркәм сабырлыклар насыйп әйләсен!

***

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә дәүләт җитәкчебезнең саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Наил хәзрәт Әбелханов,*

*Лаеш районы мөхтәсибе*

[1] Әл-Бохари, Мөслим.

*8нче декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 24нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Нәрсә ул тәвәссүл һәм тәбәррук?

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмииин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-Кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Тәгаләгә бөтен мактауларыбыз, шөкраналарыбыз булса иде. Безгә бәхет-сәгадәткә илтә торган юлны күрсәтеп калдырган сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз ирешсә иде.

Изге җомга көне барчабызга мөбарәк һәм хәерле булсын! Бүгенге көндә кайбер дин кардәшләребез, белем җитмәү сәбәпле, дин мәсьәләләрен дөрес аңламыйлар, шәригать тарафыннан рөхсәт ителгән гамәлләрне тыялар. Шундый мәсьәләләрнең берсе — тәвәссүл яки истигасә.

Тәвәссүл — Аллаһыга якынлашу өчен, ниндидер сәбәп яки чаралар куллану дигән сүз. Яхшы гамәлләр генә түгел, пәйгамбәрләр дә, шулай ук тәкъва кешеләр дә Аллаһыга якынлашу юлының чаралары булырга мөмкин.

Тәвәссүл сүзенең синонимы — истигасә, ярдәм сорап ялвару. Коръәндә һәм Сөннәттә пәйгамбәрләр һәм тәкъва кешеләр арадашлыгы белән тәвәссүл кылу (үзләре булмаганда яки алар үлгәннән соң) тыелган булуны күрсәткән бернинди дәлил дә юк.

Тәвәссүлгә каршы килүчеләр моны: «Аллаһыдан башка берәүгә табыну», — дип раслый.

Тереләргә яки үлгәннәргә бары тик мөрәҗәгать кенә итү, яисә кемнедер бары тик олылау-зурлау, яисә Аллаһыдан башка берәүгә бары тик ярдәм сорап мөрәҗәгать итү, Аллаһы Тәгаләдән, башкалар тарафыннан ярдәм сорау

формуласы — болар Аллаһы Тәгаләдән башкага гыйбадәт кылу түгел, ягъни ширек түгел.

Пәйгамбәрләр һәм әүлиялар аша тәвәссүл һәм истигасә мөмкин булуга дәлилләрне карап узыйк.

«Дәләил ән-нубуввә»дә  имам әл-Бәйһәкый Гомәр радыяллаһу ганһедән хисапчысы (казначей) булган Мәлик әд-Дәрдән ышанычлы иснәд белән шуны риваять итә: «Гомәр идарәлек иткән вакытта, илгә ачлык килгәч, бер ир Пәйгамбәрнең каберенә килә һәм аңа дәшә: «Әй, Расүлуллаһ, өммәтеңә яңгыр явуын сора, әлбәттә, алар үлемгә якын», — ди. Шуннан соң Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмне төшендә күрә, һәм ул: «Гомәргә сәлам әйт һәм аңа тиздән яңгыр явуы турында хәбәр ит һәм шуны җиткер: җәмгыять файдасына тырыш булсын». Бу кеше, Гомәр янына килеп, бу турыда хәбәр иткәч, Гомәр елап җибәрә һәм әйтә: «Йә, Раббым, мин бар көчемне куеп, булдыра алганымны эшләрмен», — ди».

Мәгълүм булганча, бу кеше сәхабә Биләл ибне Харис әл-Музани булган. Ул, бәрәкәт алу максаты белән, Расүлуллаһның каберенә килә, һәм Гомәр дә, башка сәхабәләр дә моның өчен аны шелтәләмәгән. Бу Ибне Тәймиянең «мондый зиярат кылу — мәҗүсилек» дигән сүзләрен кире кага.

Имам Әхмәд яхшы иснәд белән «Муснәд» китабында әл-Харис бине Хассән әл-Бәкри Аллаһының илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ничек дәшүен риваять итә: «Гад кавеменең илчесе хәлендә калмас өчен, мин Аллаһы һәм Аның Расүле яклавына сыенам», — дигән ул.

Бу хәдис вәһһабиларның «Аллаһыдан башка кемнеңдер ярдәменә мөрәҗәгать итү — мөшриклек» дигән сүзләрен кире кагучы дәлил булып тора.

Ибне Габбастан радыяллаһу ганһе риваять ителгән, Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Чынлыкта, Аллаһының җирдә саклаучылардан кала фәрештәләре дә бар, алар агачлардан төшкән яфракларны яза. Әгәр кем дә булса ачык җирдә бәла-казага тарса, ул кычкырып: «Әй, Аллаһ

коллары, ярдәм итегез», — дип әйтсен». Әт-Табәрани тапшырган, ә хафиз әл-Хайсәми: «Аның тапшыручылары ышанычлы», — дигән.

Бу хәдиснең башка версияләрен хафиз әл-Бәйһәкый — «Шугаб әл-иман»да һәм «Әл-Әдәб»тә, әл-Бәззар — «Муснәд» китабында, имам ән-Нәвәви — «Әл-Әзкәр» китабында һәм Әбү Ягълә — «Муснәд»та китерәләр.

Имам әл-Бәззар «Муснәд» дип аталган китабында риваять кылган, Аллаһының илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Минем тормышым да сезнең өчен яхшы, үлемем дә сезнең өчен яхшы. Сез эшләр башкарасыз, һәм аларның хөкеме иңә. Минем үлемем сезнең өчен яхшы: кылган гамәлләрегез миңа күрсәтелә; әгәр мин яхшылык күрсәм, Аллаһыга шөкер кылам, әгәр начарлык күрсәм, сезнең өчен кичерү сорыйм». Аны тапшыручылар — дөрес хәдис тапшыручылар.

Әт-Табәрани «Әл-Мугъҗәм әл-кәбир» җыентыгында һәм «әл- Мугъҗәм әс-сәгыйр»дә Госман ибне Хунәефтән риваять иткәнчә, бер ир Госман бине Гаффәнгә үтенеч белән мөрәҗәгать иткән, әмма Госман аңа илтифат итмәгән, ирнең ихтыяҗы турында кайгыртмаган. Госман бине Хунәеф белән очрашкач, бу ир зарланган, һәм моңа каршы Госман аңа: «Тәһарәт ала торган урынга барып тәһарәт ал, аннары ике рәкәгать намаз укы, аннан соң әйт: «Әй, Аллаһ, мин Синнән сорыйм һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм, мәрхәмәт пәйгамбәре аша Сиңа мөрәҗәгать итәм; әй, Мөхәммәд, мин синең аша Раббыма ихтыяҗым турында мөрәҗәгать итәм, ихтыяҗымның үтәлүен насыйп ит», — дип сора. Аннан соң Госман янына бар, мин дә синең белән барырмын», — дигән.

Бу кеше киткән һәм, кушканнарны эшләп, Госман капкасы янына килгән. Баш хезмәтче чыгып, аның кулыннан ала һәм Госман бине Гаффән янына алып керә. Хәлифә аны келәмгә утырта һәм: «Сезгә нәрсә кирәк?» — дип сорый. Ир аңа үзенең үтенечен кабатлап исенә төшерә. Госман аны үти һәм: «Бу сәгатькә кадәр мин сезнең ихтыяҗны хәтерләмәдем», — ди.

Аннан чыккач, әлеге ир Госман бине Хунәеф белән очраша: «Аллаһы сиңа яхшы бүләк бирсен, син аның белән минем турыда сөйләшкәнче, ул минем ихтыяҗыма карамады, миңа игътибар итмәде», — ди.

Госман бине Хунәеф әйткән: «Аллаһы белән ант итеп әйтәм, мин аның белән сөйләшмәдем. Ләкин Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шундый гамәлен күрдем. Бер сукыр кеше аның янына килеп, күрү сәләтен югалту турында зарлангач, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: «Түз, әгәр теләсәң, мин синең өчен дога кылам», — диде. Сукыр кеше аңа: «Йә, Расүлүллаһ, минем өчен күрмәү бик авыр, минем җитәкләп йөртүчем юк», — диде. Шуннан соң Пәйгамбәр аңа болай эшләргә кушты: «Тәһарәт урынына бар, тәһарәт ал, аннары ике рәкәгать намаз укы, аннары бу сүзләрне әйт», — дип, шул сүзләрне өйрәтте. Сукыр бәндә шуларны үтәде. Аллаһы белән ант итәм, күп вакыт та үтмәде, без әле таралышырга да өлгермәдек, безнең янга, берни булмагандай, күз күрүе ачылган ир килеп керде».

Әт-Табәрани үзенең «Мугъҗәм»ендә: «Бу хәдис ышанычлы», — дип күрсәтә. Ул, гадәттә, «Әл-Мугъҗәм әл-кәбир» китабы зур күләмле булу сәбәпле (бу хәдистән кала), бернинди хәдиснең дә дөреслеген аерып күрсәтми. Ул шулай ук аны «әл- Мугъҗәм әс-сәгыйр»гә дә керткән һәм аңа сахих дәрәҗәсен биргән.

Әлеге хәдистә сукыр кешенең Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аша, ләкин аның үзенең катнашыннан башка, тәвәссүл ясавын күрсәтүче дәлил бар: Госман бине Хунәефнең: «Без әле таралышырга да өлгермәдек, безнең янга, берни булмагандай, күз күрүе ачылган ир килеп керде», — дигән сүзләре шуны исбатлый. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аша тәвәссүл ул исән вакытта һәм аның үлеменнән соң рөхсәт ителә, шуңа күрә Ибне Тәймиянең тәвәссүлнең тере кеше аша һәм ул янда булганда гына рөхсәт ителүе турындагы сүзләре дөрес түгел.

Тәвәссүл һәм истигасәнең рөхсәт ителгәнлеге турында галимнәрнең бертавыштан килешенгән фикерләре (иҗмәгъ) бар.

Мәсәлән, имам, мөҗтәһид, шәех әл-ислам Тәкыюддин әс-Субуки (683–756 еллар, һиҗри ел исәбе беләң) «Шифау-с-сикам» китабында болай дип яза: «Белегез, чыннан да, Аллаһы каршында Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аша арадашлык (тәвәссүл) башкару, ярдәм сорау (истигасә) һәм шәфәгать эзләү рөхсәт ителә һәм мактауга лаек. Ислам дине галимнәреннән без моның рөхсәт ителүен беләбез, һәм моны пәйгамбәрләр һәм рәсүлләр эшләве билгеле. Бу — тәкъва кешеләрнең, галимнәрнең һәм гади мөселманнарның юлы. Ислам белгечләренең берсе дә моны кире какмады һәм, Ибне Тәймия килгәнче, кире кагучы барлыгы турында ишетелмәде. Ибне Тәймия аңа кадәр башка гасырларда булмаган нәрсә алып килде һәм тәвәссүл, истигасә турында зәгыйфь кешеләрнең башларын бутардай сүзләр таратты».

Шәех Мөхәммәд бине Әдәм әл-Кәүсәри болай ди: «Әгәр кем дә булса, ул Аллаһы Тәгалә кебек үк кодрәтле дип уйлап һәм ышанып, пәйгамбәрдән, Аллаһы дустыннан (вәли) яки башка җан иясеннән ярдәм сораса, бу күпаллалык (ширек) була, һәм бу һич рөхсәт ителми. Шулай ук, әгәр кеше Аллаһы Тәгаләгә ышанса, ләкин шул ук вакытта Ул Үз көченең бер өлешен фәрештәгә, вәли яки пәйгамбәргә биргән, шуңа күрә ул бу өлкәдә мөстәкыйль һәм тулысынча эшли ала дип уйласа — бу да күпаллалык, һәм ул тыелган.

Бу югарыдагы ике мисал — безгә Коръәнне ачучы сүрәдә тыелган нәрсәләр: «Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз!»

Соңгы чорның бөек галиме, Сүрия шәехе Мөхәммәд әл-Хәмид яза: «Ярдәм сорап мөрәҗәгать иткәне, Аллаһы кебек, [нәрсәгәдер] тәэсир итә ала, файда яки зыян китерә ала дип ышанган кешегә килгәндә, ул — Ислам диненнән чыккан мөшрик». Шунлыктан, әгәр кеше аларның Аллаһы ихтыярыннан башка ниндидер файда яки зарар китерә алганына ышанмаса, ул вакытта югарыда аталган ысуллар белән пәйгамбәрләр, әүлиялар, тәкъва кешеләргә арадашчы сыйфатында ярдәм сорап мөрәҗәгать итүдә бернинди начарлык та юк».

Аллаһы Тәгалә барыбызга да сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең олуг галимнәребезнең рухи мирасын дөрес аңлап һәм изге гамәл-гыйбадәтләр кылып яшәргә насыйп итсә иде!

* * *

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә дәүләт җитәкчебезнең саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Нияз хәзрәт Сабиров,*
*«Апанай» мәчете имам-хатыйбы,*
*ТҖ МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы*

*15нче декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-ахыр аеның 2нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Рия — кече ширек

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмииин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-Кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Җирләрнең, күкләрнең Раббысына, безне юктан бар кылып, тәрбия кылып торучы, Бөек кодрәт иясе Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез ирешсә иде. Шушы дөньяга соңгы пәйгабәр булып җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез, хәбибебез, остазыбыз Мөхәммәд Мостафа Сөбеханәһу вә Тәгалә салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның әһле бәйтенә, сәхабәләренә, тәбигыйннарга, тәбге-тәбигыйннарга күңел түрләребездән чыккан салаватларыбыз, сәламнәребез, догаларыбыз ирешсә иде.

Аллаһы Раббыбыз, изге җомга көннәребезне хәерле, бәрәкәтле кылып, һәрбарчаларыбызның да кылган изгелекләребез, яхшылыкларыбыз, теләгән теләкләребез бәрабәренә бу дөньяның да, ахирәтнең дә бәхет-сәгадәтенә ирешүләребезне насыйп итсә иде.

Газиз дин кардәшләрем, хөрмәтле мөселманнар, хәзрәтләргә мәҗлесләрдә, социаль челтәрләрдә, мәчеттә көн дәвамында мөрәҗәгать итүчеләр бар. Күп кенә вакытта дин кардәшләребез рия гамәлләр мәсьәләсендә мөрәҗәгать итеп сорыйлар. «Рия гамәлләр нинди гамәлләр алар?» — дип сораучылар бар. Бүгенге вәгазебездә рия мәсьәләсен күтәрәсем килә. Рия ул икейөзлелек дип алсак та буладыр. Икейөзлелек — кешеләр алдында мактану яисә дәрәҗә алырга тырышу, кем алдындадыр яхшы булырга тырышу, дөнья максатында, дөньяда яшәгәндә кеше өчен: «Туга-

ным, дустым мине мактасын әле, бу изге кеше икән, яисә бу бик ярдәмчел, бик дини кеше икән, бу бик күп ураза тота, намаз укый икән, дип әйтсен әле», — дип гамәл кылу, эшләрне башкару. Бу рия гамәлгә килеп тоташа. Әгәр дә адәм баласының, гамәл-гыйбадәт, намаз, кылганда, ураза, садака һәм башка төрле изгелекләр мәсьәләләрендә күңелендә шик-шөбһә булса (ягъни Аллаһы ризалыгы өчен дип түгел, ә кеше күрсен өчен дигән ният белән шушы гамәлне башкара икән) аның бу гамәле рия булып санала. Рия гамәл — кеше күрсен өчен эшләнә торган гамәлләр. Нинди генә изгелегебезне алсак та, безнең күңелебездә булырга тиешле бердәнбер уй-фикер, бердәнбер ният — ул Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен, һәрбер эшебез, гамәлебез Аллаһы ризалыгы өчен булырга тиеш. Берәр төрле изгелек кылсак та, һәрвакыт, иң беренче, безнең ниятебез дөрес булырга тиеш. Намаз башланганда да, уразага кергәндә дә без һәрвакыт ниятнең ахырында «Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен» дип әйтәбез. Шуңа күрә, һәрбер гамәлебез дә Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен булсын. Әлбәттә, рия гамәлләр мәсьәләсенә килгәндә, рия гамәлләр алар безнең кылган эшебезне, риядан, кеше күргән өчен кылган эшебезнең савабы барлыгын күрсәтә. Җундүб бине Габдуллаһ бине Сафьян радыяллаһу ганһедән риваять ителә, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Кем изге гамәлләрне кешеләргә күрсәтер өчен, кешеләрнең ихтирамына ирешү өчен генә кыла, Аллаһы Тәгалә аны башкалар алдында ачып бирер, яшерен уйларын барысына да күрсәтер, Аллаһы Тәгалә аны хур кылыр, Кыямәт көнендә хурлык белән каплар», — дигән.[1] Әлбәттә, адәм баласы үзенең гамәлләрен кеше күрсен өчен генә башкара икән, димәк Аллаһы Тәгалә аның бөтен гөнаһларын фаш итәр, ягъни гөнаһларын күрсәтер, ачып бирер, — дип китерелә шушы хәдис-шәрифтә. Аллаһы Тәгалә шушындый бәндәләрдән булудан сакласа иде. Бервакытны пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Сезнең өчен иң курыккан әйберем — ул кече ширек эшләвегез», — дигән. Шушы сүзләрне

[1] Әл-Бохари, Мөслим.

ишеткәннән соң, яның янындагы кешеләр гаҗәпләнеп: «Расүлуллаһ, нәрсә соң ул кече ширек?» — дип сорыйлар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кече ширек — ул рия», — дип җавап бирә. Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә кешеләрне эшләгән эшләре белән хисап иткән вакытта, кешеләргә әйтер: «Дөньялыкта яшәгәндә гамәлләрегезне кем өчен эшләдегез, җәннәт гамәлен шулардан сорагыз, алар сезгә нәрсә дип җавап бирерләр икән?» — дип әйтер. Әгәр дә без үзебезнең һәрбер кылган гыйбадәтебез, намазыбыз, уразабыз, башка төрле гамәлләребез булсынмы, нәфел, сөннәт гыйбадәтләребез булсынмы — һәрберсен без кеше күрсен, кемдер мактасын, кемнедер бездән шаккатсын өчен эшлибез икән, Кыямәт көнендә безгә шушы бәндәләргә мөрәҗәгать итәргә кушылачак. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә мондый гамәлләрдән һәрбарчабызны да сакласын. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә әйтә: «Рия һәм хушуг гамәлләрдән сакланыгыз, ягъни рия да, хушуг та — кеше күрсен өчен эшләнелә торган гамәлләр. Безгә шушы гамәлләрдән саклануны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе боера.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән китерелгән хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: «Аллаһы Тәгалә Гаден җәннәтен яратты һәм шул Гаден җәннәтендә күз күрмәгән, колак ишетмәгән, кешеләрнең күңелләреннән кичмәгән нәрсәләрне бар кылды. Аннан соң Аллаһы Тәгалә: «Сөйләш», — дип әйтте. Җәннәт: «Әлбәттә, иман китергән кешеләр өч мәртәбә өстенлек таптылар, хакыйкатьтә, мин саран, икейөзле, рия кылучы кешеләргә харам булырмын», — диде. Ягъни, безнең белүебезчә, Гаден дигән җәннәт бар, җәннәт ишекләре бар, шушы җәннәт ишегеннән, җәмәгать, рия кылмаган, саран, икейөзле булмаган бәндәләр генә керерләр. Шуңа күрә, җәмәгать, икейөзлелектән һәм рия гамәлләрдән ерак булыйк. Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай ди:

قَدْ أَفْلَحَ الْمُؤْمِنُونَ ۞ الَّذِينَ هُمْ فِي صَلَاتِهِمْ خَاشِعُونَ

> **«Иман китерүчеләр хәзердән уңышка иреште** [һәм өметләре гамәлгә ашты]**. Кемнәр** [Аллаһының хозурында булган кебек] **намазларында** [карарга тиешле урынга карап, бөтен әгъзаларын да тыныч тотып һәм күңелләре белән Раббыларына юнәлеп] **түбәнчелеклеләр».**

«Әл-Мүэминүн / Мөэминнәр», 23:1-2

Гыйбадәтебезне башкарганда кемдер безнең турында матур сүзләр әйтсен өчен түгел, ә Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен башкарырга кирәк һәм, әлбәттә, Аллаһы Тәгаләгә тапшырып, Аның барлыгын, берлеген танып, гамәл кылырга тиешбез. Әгәр дә без намаз гыйбадәте кылганда, артыбыздан яки яныбыздан берәр кешенең килүен, карап торуын сизгәннән соң, намазыбызны тагын да яхшыртабыз икән: сәҗдәдә озаграк торабыз, кыямда озынрак сүрәләрне укыйбыз, «бу кеше мине мактасын әле, намазлы икән, тәкъва икән дип уйласын, сөйләсен әле», — дигән уй белән намазыбызны башкарырга тырышабыз икән, бу вакытта әлеге гамәлебез рия булып саналачак, ягъни бу гамәлебезнең әҗеренә ирешмибез. Шуңа күрә, әҗеренә ирешик дисәк, без бу рия гамәлдән ерак булырга тиешбез.

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تُبْطِلُوا صَدَقَاتِكُم بِالْمَنِّ وَالْأَذَىٰ كَالَّذِي يُنفِقُ مَالَهُ رِئَاءَ النَّاسِ وَلَا يُؤْمِنُ بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ ۖ فَمَثَلُهُ كَمَثَلِ صَفْوَانٍ عَلَيْهِ تُرَابٌ فَأَصَابَهُ وَابِلٌ فَتَرَكَهُ صَلْدًا ۖ لَّا يَقْدِرُونَ عَلَىٰ شَيْءٍ مِّمَّا كَسَبُوا ۗ وَاللَّهُ لَا يَهْدِي الْقَوْمَ الْكَافِرِينَ

> **«Ий, иман китерүчеләр! Аллаһыга һәм Соңгы көнгә ышанмаган, кешегә күрсәтер өчен генә малын сарыф иткәннәр кебек, битәрләү һәм кимсетүләрегез белән садакаларыгызны юкка чыгармагыз.** [Рия өчен икейөзлеләнгән кеше] **Аның өстендә бераз туфрак булган,**

**коеп яңгыр яугач,** [аны туфрактан арындырып] **ялан хәлдә калдырган кыя ташы кебек.** [Мондый кыя өстендәге туфрактан беркем дә файдалана алмаган кебек] **Алар казанган нәрсәләренә ирешә алмаслар. Аллаһы кяферләр кавемен** [игелеккә һәм дөреслеккә] **һидаять итми».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:264

Беләбез, бүгенге көндә бик күп хәйриячеләребез бар. Ә хәйрия гамәле — ул Аллаһы ризалыгы өчен эшләнергә тиешле гамәл. Нинди генә гамәл башкарсак та, садака мәсьәләсенә килгәндә дә, күп кенә вакытта ишеткәнебез бар, әби-бабаларыбыз да еш кына кабатлый: «Уң кулың биргәнне сул кулың күрмәсен», — диләр. Ягъни шулкадәр яшереп бир, бер кулың биргәнне икенчесе күрмәсен, тирә-яныңдагы кешеләр дә күрмәсен. Кеше күрсен өчен эшләмә дигән мәгънәдә китерелә. Садака таратабызмы, изге гамәл кылабызмы, без эш тәмамланганнан соң онытырга тиеш. Әгәр дә эш тәмамланганнан соң интернет челтәренә куябыз икән, кешеләргә сөйлибез икән, безнең бу эшләгән изгелегебез риядан китәргә дә мөмкин. Хөрмәтле дин кардәшләрем, саваплы гамәлгә ашыгу кирәк. Шуңа күрә кеше күрсен дип түгел, бөтен гамәлләребезне дә Аллаһы Тәгалә ризалыгы дип башкарсак иде. Татар халкында шундый мәкаль бар бит: «Изгелек эшлә дә, суга сал, халык күрмәсә, балык күрер», — диләр. Изгелек эшлә дә, оныт, кешегә сөйләп йөрмә, әҗеренә ирешерсең, иншә Аллаһ.

Әбү Мөхәриттән риваять ителә: «Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләре белән утырганда, алар яныннан куәтле, яшь гарәп егете үтеп китте. Әбү Бәкер белән Гомәр радыяллаһу ганһүмә: «Чү, бу егетнең яшьлеге һәм көче Аллаһы юлында булса, аның әҗере олуграк булыр иде», — диделәр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр дә ул егет картайган ата-анасына ярдәм кылып йөрсә, Аллаһы юлында булыр, әгәр дә яшь балалары өчен тырышса, ул да Аллаһы юлында булыр, әгәр дә кешеләргә бармас өчен үз-үзенә тырышса, ул да Аллаһы юлында булыр, әгәр

дә ул кеше рия һәм шөһрәт өчен кәсеп кылса — бу шайтан юлыдыр», — ди. Шушы хәдисендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһы юлы — ул фәкать намаз юлы, гыйбадәт юлы гына түгел, ә ата-анасына ярдәм итүне дә, баланңы тәрбияләү дә, үзең өчен тырышу да — ул Аллаһы юлы икәнен әйтә. Әлбәттә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять ителә: «Бер кеше икенче кешедән сорамас өчен, баласына ризык булсын өчен, күршесенә ярдәм итү өчен хәләл малны теләсә — Кыямәт көнендә бу кеше йөзе айның ундүртенче кичәсендәге кебек булган хәлдә килер; бер кеше күбәйтү һәм мактану өчен, рия гамәле кылу өчен хәләл дөньяны кәсеп итсә, Кыямәт көнендә ул кеше Аллаһы Тәгалә аңа ачулы булган хәлдә юлыгыр», — ди. Без шушыннан күрәбез, әгәр дә без гамәлләрне Аллаһы ризалыгы өчен кылабыз, изгелекләр эшлибез икән, ул бәндәнең йөзе тулган ай кебек нурлы һәм якты булыр ди, әгәр дә дәрәҗә, мактану өчен хәләл дөньяны кәсеп итеп яшәсә, Аллаһы Тәгалә аңа ачулы булыр ди. Гали кәррамәллаһу вәҗһәһүдән хәдис китерелә, Пәйгабәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: «Рия кылучының дүрт галәмәте бар:

1) ялгыз булса, һәрвакыт ялкауланыр;
2) кешеләр арасында булса, тырышыр;
3) мактасалар, гамәлен арттырыр;
4) хурласалар, гамәлен кылмас».

Хөрмәтле дин кардәшләрем, һәрбарчаларыбыз да, иманнарыбыз нык булып, Аллаһы Тәгалә юлында гамәл-гыйбадәт кылып яшәүләребез насыйп булсын. Шушы рия гамәлләрдән һәрбарчабыз да ерак булсак иде, гамәлләребезне Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә ризалыгы өчен генә дип яшәргә Раббыбыз көч-куәт, тырышлык насыйп итсен. Диннән ерак булган бәндәләргә Ислам юлына килергә Аллаһы Тәгалә һидәять, тәүфыйк насып итсен.

* * *

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә дәүләт җитәкчебезнең саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Ансар хәзрәт Мифтяхов,*
*Казан шәһәренең*
*«Әл-Мәрҗани» мәчете имамы*

*22нче декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-ахыр аеның 9нчы көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Гаилә таркатуда сихер куллану

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмииин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-Кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Барча мактау-данлау Аллаһы Тәгаләгә булсын! Без Аңа шөкрана кылабыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аның ярлыкавын үтенәбез! Үзебезнең начарлыгыбыздан, бозык гамәлләребездән Аллаһы Тәгаләдә сыену эзлибез. Аллаһы туры юлга күндерсә, берәү дә адаштыра алмас, Аллаһы адаштырганнарны берәү дә туры юлга кертә алмас. Аллаһыдан башка гыйбадәткә лаеклы илаһи зат юк, «Ул — Берүзе, Тиңдәшсез һәм Мөхәммәд — Аның колы һәм расүле», — дип шәһадәт бирәмен.

Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә кешелеккә биргән зур нигъмәтләренең берсе — гаиләле булу. Гаилә кору белән Адәм баласының дөньядагы тормышы ямьлерәк була, ул күңеленә тынычлык таба. Аллаһы Тәгалә «Рум» сүрәсенең 21нче аятендә әйтә:

وَمِنْ آيَاتِهِ أَنْ خَلَقَ لَكُم مِّنْ أَنفُسِكُمْ أَزْوَاجًا لِّتَسْكُنُوا إِلَيْهَا وَجَعَلَ بَيْنَكُم مَّوَدَّةً وَرَحْمَةً ۚ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِّقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ

**«Бергә яшәвегез өчен үзләрегездән сезнең өчен хатыннар яралтуы һәм арагызда сөю** [нәтиҗәсендә хасил булган бердәмлек] **белән бер шәфкать** [чарасы булган бала] **бирүе дә — Аның билгеләреннән. Һичшиксез, монда уйлаганнар өчен** [аңлатылып бетерә алмаслык дәрәҗәдә зур] **билгеләр бар».**

«Әр-Рум / Румлылар», 30:21

Тик кызганыч бүгенге көндә гаилә корып ямьле, тыныч тормышта яшәргә тиешле күпме кешеләр гаиләдә күңел тынычлыгы табалмыйлар, аерылалар. Аерылышу, гаилә таркалу очраклары артканнан арта бара. Статистика мәгълүматлары буенча моннан 70 ел элек 100 гаиләнең 4се генә таркалган, 30 ел элек 100 гаиләнең 42се. Бүген исә Русиядә һәр теркәлгән 100 гаиләнең 68е аерылышу белән тәмамлана.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм әйткәнчә: «Ир белән хатынның аерылышуы — ул Иблисне шатландыра торган күренешләрдән. Җәбир радыяллаһу ганһе китергән хәдистә Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: «Иблис үзенең тәхетен су өстенә урнаштырып куйды да, үзенең гаскәрен төрле якка җибәрә башлады. Шул гаскәрендәге шайтаннарның Иблискә иң якыны — араларыннан иң зур фетнә чыгаручысы. Аларның берәрсе Иблис янына килеп: «Мин шундый-шундый әшәкелекләр эшләдем», — дип әйтә. Ләкин Иблис аңа: «Син бернәрсә дә булдыра алмагансың», — ди. Аннан соң икенче шайтан килеп: «Мин гел бер кеше янында булдым, хатыныннан аны аермыйча, аның яныннан китмәдем», — ди. Бу шайтанны Иблис үзенә якынайта һәм: «Менә син булдыргансың», — дип аны мактый».[1]

Шушы хәдистә әйтелгәнчә, кайвакытта гаиләнең таркалуына шайтан үз өлешен керткән булырга мөмкин. Шайтан ир белән хатынга вәсвәсә кылып, аларны бер-берсенә каршы котыртып, аерылу дәрәҗәсенә җиткерергә мөмкин. Икенче яктан, шайтаннар сихер эшендә катнашып та гаилә таркалуга китерәләр.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә сихер турында әйтә:

وَلَٰكِنَّ الشَّيَاطِينَ كَفَرُوا يُعَلِّمُونَ النَّاسَ السِّحْرَ وَمَا أُنزِلَ عَلَى الْمَلَكَيْنِ

**«Алар** [кешеләр] **ир белән хатын арасын аера торган** [сихер кебек] **нәрсәләрне шул икәүдән өйрәнгәннәр иде».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:102

---

1 Мөслим

Сихернең төрләре турында әйткәндә дин галимнәре аерылу сихерен дә искә алалар. Бу сихернең максаты ир белән хатынны аеру, гаиләне таркату, шулай ук бер-берсен якын күрүче кешеләрне дошманлаштыру өчен дә кулланылырга мөмкин диләр. Ир белән хатын үзләре шуны сизмәсәләр дә, кайчак аерылышуның сәбәбе булып сихер торуы бар.

Ничек итеп кеше үзенә карата сихер кулланылганны белә ала соң? Дин галимнәре сихергә дучар булуның кайбер билгеләрен әйтеп узалар:

— кисәк рәвештә ирнең хатынга яки хатынның иренә нәфрәт хисе уяну;

— юк кына сәбәптән дә җәнҗал, ызгыш-талаш чыга башлау;

— иргә хатыны яки хатынга ире ямьсез, тәрбиясез, начар холыклы булып күренү;

— сихерләнгән кеше тормыш иптәшенең бөтен эшләрен күралмый, сөйми башлый;

— сихерләнүче иптәше булган урыннарны сөйми, иптәше янәшәсендә булу аңа авырлык китерә;

— өйгә кергәч күңелдә авырлык хисе туу;

— кәефнең кинәт үзгәреп торуы;

— гыйбадәт эшләреннән, Аллаһыны искә алудан читләшү;

— холыкның начар якка үзгәрүе, тиз нәфрәтләнү, кызып китү;

— элек чирләмәгән кешенең еш авырый башлавы;

— чынлыкта булмаган әйберләр күзгә күренү;

— күңел төшенкелеге, йокы начарлану;

— азан ишеткәндә, Коръән укылганда тынычсызлану, тыңлыйсы килмәү.

Санап үтелгән билгеләр кешегә карата сихер кулланылганны белгертергә мөмкин. Ничек итеп сихердән дәваланып һәм сакланып була? Динебез безгә сихердән, бозымнан, шайтаннарның зарарыннан саклый торган юлларны өйрәтә.

1. Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

وَنُنَزِّلُ مِنَ الْقُرْآنِ مَا هُوَ شِفَاءٌ وَرَحْمَةٌ لِّلْمُؤْمِنِينَ ۙ وَلَا يَزِيدُ الظَّالِمِينَ إِلَّا خَسَارًا

**«Без мөэминнәр өчен шифа һәм рәхмәт булган Коръәнне иңдерәбез. Әмма ул** [Коръәни Кәримне инкяр итүдә үҗәтлек күрсәткән] **залимнәргә зарардан башка берни дә арттырмый».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:82

Аллаһы Раббыбыз Коръән аркылы һәртөрле тән авыруларыннан да, калеб авыруларыннан да, сихердән, бозымнан да шифа бирә. Бигрәк тә «әл-Бәкара» сүрәсе сихердән, шайтаннардан саклаучы сүрә булып тора. Әбү Һөрайра китергән хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә:

«„Әл-Бәкара“ сүрәсе укыла торган йорттан шайтаннар качалар».[1]

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең хәдисләрендә әйткәнчә, «Әл-Бәкара» сүрәсендәге «Аятел-Көрси»не уку адәм баласын Аллаһы Тәгаләнең саклавы астына кертә, шайтаннардан саклый.

Шулай ук «Әл-Фәләк» белән «Ән-Нәс» сүрәләре дә сихер-бозымга каршы иң файдалы сүрәләр. Әбү Сәгыйд әл-Ходри радыяллаһу ганһе сөйләвенчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм башта күз тиюләрдән, шайтаннардан Аллаһыга сыенып дога кыла торган булган, «әл-Фәләк» белән «ән-Нәс» сүрәләре иңгәч исә, шуларны гына укый башлаган[2]. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәсе Габдуллаһ бине Хөбәеб радыяллаһу ганһегә дә киңәш итеп әйтә: «„Әл-Ихлас“, „Әл-Фәләк“, „Ән-Нәс“не иртә-кич өчәр тапкыр укысаң, бу сине бөтен начарлыктан саклар» .[3]

2. Сихер ясалган әйбер табылса, бу әйберне юк итү бу сихердән арынуның иң ышанычлы юлларыннан. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне бервакыт бик каты сихерләгәннәр иде. Аллаһы Тәгалә аңа сихернең бер коеда яшерелгәнлеген белгертеп, шул сихер юк ителгәч кенә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм савыккан. Ләкин сихерне табу җиңел түгел. Ул төйнәлгән җепләр рәвешендә дә, кечкенә төргәк рәвешендә

---

[1] Мөслим.

[2] Ән-Нәсәи, 5494; Ибне Мәҗе, 3511.

[3] Тирмизи, 3575; Әбү Дауд, 5082; ән-Нәсәи, 5428.

дә, аңлашылмый торган сихер сүзләре язылган кәгазь рәвешендә дә булырга мөмкин. Шундый әйберләр кешенең өендәге күренми торган урыннарда: идән астында, ярыкларда, хәтта мендәр эчләрендә булырга мөмкин. Дин галимнәре әйтүенчә кайчакта сихерне ризык аша кешенең эченә кертәләр. Бу очракта аны косып чыгару белән кеше шул сихердән дәвалана. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә өебезне дә, ризыгыбызны да шайтаннан саклау юлын өйрәтте. Ул да булса «бисмилләһ» әйтү. Җәбир радыяллаһу ганһе китергән хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өйгә кергәндә һәм ашар алдыннан «бисмилләһ» әйтү безнең өебезне һәм ризыгыбызны шайтаннан саклавын хәбәр итә. Әгәр дә кеше өенә кергәндә «бисмилләһ» дип Аллаһыны искә алмаса, аның белән бергә бу йортка шайтаннар да үтеп керә, ашар алдыннан «бисмилләһ» әйтмәсә, аның белән бергә шайтаннар да бу ризыкка катнашалар.[1]

3. Аллаһыны зикер итү, искә алу. Аллаһыны зикер итүче кеше һәрвакыт Аллаһы Тәгалә белән элемтәдә һәм Аның саклавы астында була. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм зикер итүне ныгытма белән чагыштыра. Аллаһыны искә алучы кеше ныгытма эчендә сыман: аңа шайтаннар бернинди зарар-зыян сала алмый.

4. Аллаһыга сыгыну. Ярдәм сораучы кешегә Аллаһы Тәгалә ярдәм бирә, саклавын сораучыны саклый. Аллаһы Тәгаләгә шайтаннардан саклавын сорау догасы ул һәрберебез белә торган «Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим» сүзләре. Шушы сүзләр белән шайтаннарның зарарыннан Аллаһыга сыгынабыз. Шулай ук Аллаһының саклавына китерә торган догаларны да уку кирәк. Госман бине Гәффән радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән шушы хәдисне китерә: «Иртә-кич өчәр мәртәбә:

بِسْمِ اللهِ الَّذِي لَا يَضُرُّ مَعَ اسْمِهِ شَيْءٌ فِي الْأَرْضِ وَلَا فِي السَّمَاءِ وَهُوَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ

1 Мөслим.

«Аллаһының исеме белән, Аның исеме белән җирдә дә, күктә дә — бернәрсә дә бернинди дә зыян китерә алмый, Ул — Ишетүче, Белүче», — дип әйтүчегә бернәрсә дә зыян китерә алмас».[1]

5. Хөрмә (финик) ашау. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: «Һәр иртә гәҗвә төрендәге җиде хөрмә ашаучыга ул көндә агу да, сихер дә зыян китермәс».[2] Дин галимнәре, бу хәдистә гәҗвә хөрмәсе турында гына әйтелсә дә, андый хөрмә тапмаган кеше нинди хөрмәсе булса, шуны иртәләрен җидешәрне ашап бару сихергә каршы файда китерәчәк, дип аңлаталар.

Бу сихердән, шайтаннардан саклый торган кайбер ысуллар булды. Аллаһы Тәгалә һәммәбезне дә сихер-бозымнардан сакласын. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтләрен үтәп, Аллаһыны гел истә тотып, Аның белән һәрвакыт элемтәдә булып, һәрдаим Аллаһының саклавы астында булырга насыйп итсен!

* * *

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә дәүләт җитәкчебезнең саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Марат хәзрәт Сәйфетдинов*

*Сауш авылының «Хәлил» мәчете имам-хатыйбы*

---

[1] Тирмизи, 3388.

[2] Әл-Бохари, 5445; Мөслим, 2047.

*29нчы декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-ахыр аеның 16нчы көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Вакытның кадере: үткәннәргә хисап, киләчәккә планнар кору

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмииин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-Кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Адәм баласы бу дөньяда һәрвакыт хәрәкәттә: каядыр ашыга, омтыла, үз алдына куйган максатларына ирешергә тырыша. Күп вакытта кеше Аллаһы биргән нигъмәтләрнең кадерен белеп бетерми, аны дөрес кулланмый, шуңа күрә тормышында төрле киртәләр барлыкка килә: йә чокырга төшеп аягын сындыра, йә башын имгәтә яки төрле бәла-казаларга очрый.

Хөрмәтле мөселманнар! Раббыбыз Аллаһы «Шура» сүрәсенең 30нчы аятендә болай дип әйтә:

وَمَا أَصَابَكُم مِّن مُّصِيبَةٍ فَبِمَا كَسَبَتْ أَيْدِيكُمْ وَيَعْفُو عَن كَثِيرٍ

**«Сезгә килгән һәр бәла — колларыгыз казанган** [начар] **нәрсәләр сәбәпле. Ул бик күбен гафу итә** [һәм аларга җәза бирми, шулай булмаса, җир йөзендә һичбер җан иясен калдырмаган булыр иде]**».**

«Әш-Шура / Киңәш», 42:30

Без бу дөньяда яшәгәндә, бер елдан икенчесенә күчкәндә, яңа планнар төзегәндә, киләчәк турында уйланганда сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге хәдисен истә тотарга тиешбез. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Сез биш нәрсә килгәнче биш нәрсәнең кадерен белегез, дөрес итеп кулланыгыз: картлык килгәнче — яшьлекнең; авыру килгәнче — сәламәтлекнең; фәкыйрьлек

килгәнче — байлыкның; мәшәкатьләр, авырлыклар килгәнче — буш вакытның; үлем килгәнче — гомернең» (әл-Хәким, Мустәдрак).

Төшенер өчен күп вакыт һәм китаплар кирәк булган хакыйкатьләрне Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм кечкенә генә хәдисендә аңлатып биргән. Шул нигъмәтләрне тулырак итеп карап үтик.

Картлык килгәнче яшьлекнең кадерен белегез. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм юкка гына яшьлекне аерып күрсәтмәгән, аны дөрес үткәрергә чакырган. Ул чорда кеше күп көчкә һәм энергиягә ия. Булган егәрлеген дөрес итеп кулланган вакытта гына зур уңышларга ирешергә һәм Кыямәт көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәт күләгәсенә лаек булырга мөмкин. Хәдисләрдә әйтелгәнчә, Кыямәт көнне кояш бик нык кыздырачак һәм кайбер кешеләрнең тирләре аларның колакларына кадәр җитәчәк, хәтта кайберәүләр үзләренең тирләренә батачак. Раббыбыз Аллаһының рәхмәт күләгәсе турында түбәндәге хәдис-шәрифтә әйтелгән: «Кыямәт көнне җиде төрле кеше генә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәт күләгәсенә лаек булыр. Гадел (намуслы) имам; яшьтән үк Аллаһыга гыйбадәт кылып үскән кеше; күңеле мәчет белән бәйле булган кеше; Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен бер-берсен сөйгән, шуның өчен генә күрешкән һәм аерылган ике кеше; дәрәҗәле, матур хатын зина кылырга чакырганда: «Мин Аллаһыдан куркам», — дип бу эштән тыелган кеше; сул кулы уң кулының садака бирүен белмәү дәрәҗәсендә яшереп садака бирүче; беркем күрмәгәндә Аллаһыны зикер итеп, күзеннән яшьләре аккан кеше» (әл-Бохари, Мөслим).

Бу хәдистә көн-төн гыйбадәт кылучы яшьләр күздә тотылмый, ә яшьлек чорында нәфес колына әйләнмичә, Аллаһының колы булып кала алган егетләр һәм кызлар турында әйтелә. Бүгенге көндә күңелне аздыра торган нәрсәләр бик күп, шайтан эшсез утырмый. Ул һәрвакыт аздырырга, бигрәк тә яшьләрне харам эшләргә кызыктырырга тырыша. Һәлакәт чокырына төшмәс өчен, яшьлек чорында адәм баласы төп игьтибарын гыйлем алуга юнәлтергә тиеш. Файдалы белемнәр кешене начарлыктан, гөнаһтан азат итеп, изгелекләргә, игелекле гамәлләргә юл күрсәтә. Әбү Дәрда радыяллаһу

ганһе болай дигән: «Гыйлем иясе, яки гыйлем алучы, яисә гыйлемне тыңлаучы бул, ләкин дүртенчесе булма, һәлак булырсың». Бүгенге көндә күп кенә яшьләр гыйлемне интернет челтәреннән ала. Белгәнебезчә, интернет төрле мәгълүмат белән тулган, анда хакыйкатькә туры килми торган белемнәр дә шактый күп, шуңа күрә саф белем алыр өчен, беренче чиратта, тирән гыйлемгә ия булган, тәҗрибәле остазлар кирәк. Элек-электән белемне остазлардан алганнар, дини китапларны алар белән укыганнар. Гыйлем ияләре үз белемнәре белән генә түгел, ә күркәм холыклары, гүзәл сыйфатлары белән шәкертләре өчен үрнәк, өлге булган. Яңа ел каникулларында күп кенә мәчетләрдә дини дәресләр, файдалы чаралар үткәрелә. Балаларыбызны мәчет-мәдрәсәләргә китерик, аларны рухи яктан баетырга тырышыйк!

Яшьләр өчен бер тәкъвалык үрнәген китерәсем килә. Гомәр бин Хаттаб радыяллаһу ганһе заманында бер егет яшәгән, аның күңеле һәрвакыт мәчет белән бәйле булган. Ул һәр намазын мәчеттә җәмәгать белән укырга тырышкан, Гомәр бине Хаттабның вәгазьләрен тыңларга бик яраткан. Аның тәкъвалыгы бөтен эшләрендә, сүзләрендә чагылган. Күпмедер вакыттан соң хәлиф Гомәр бу егетне мәчеттә берничә көн дәвамында очратмаган. Мәчеттәге җәмәгать арасында аның нурлы йөзе күренмәгән. Гомәр бу егетне эзли башлаган, ләкин тапмаган. Мөэминнәрдән бу хакта кызыксынып сораган: «Теге егет белән нәрсә булды икән, берничә көн дәвамында мин аны мәчеттә күрмим», — дигән. Аңа: «Йә, әмирүл-мөэминин, без аның үле гәүдәсен бер әшәке урында таптык, сине борчымас өчен бу турыда хәбәр бирмәдек, җеназа намазын укып, аны җирләдек», — дип әйткәннәр. Гомәрнең күзләреннән яшьләр чыккан һәм аның ничек үлгәнен белергә теләгән.

Бу егет мәчеткә барганда һәрвакыт бер азгын хатынның йорты яныннан үтә торган булган, теге хатын төрле юллар белән яшь егетне үзенә буйсындырырга теләгән, ләкин егет бу эштә сабырлык, түземлек күрсәткән. Шайтанга, нәфескә иярмәгән, гөнаһтан ерак булган. Беребез дә хаталардан, гөнаһтан азат түгел. Бу егет тә беркөнне, үз нәфесенә буйсынып, теге хатынга якынайган.

Бу мизгелдә ул бер аятьне искә төшергән һәм аны күп тапкыр кабатлаган:

إِنَّ الَّذِينَ اتَّقَواْ إِذَا مَسَّهُمْ طَائِفٌ مِّنَ الشَّيْطَانِ تَذَكَّرُواْ فَإِذَا هُم مُّبْصِرُونَ

«[Аллаһы Тәгаләнең тыюларын бозудан курыккан] **Тәкъва кешеләр, үзләренә шайтаннан бер вәсвәсә кагыла калса,** [Аллаһының әмерләрен һәм тыюларын] **искә төшерәләр һәм шул сәбәпле алар** [турыны, кәкрене һәм шайтанның тозакларын] **аңлы рәвештә күрәләр** [һәм аңа иярмичә, явызлыгыннан котылалар]**».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:201

Егет бу аятьне кабатлаганда тирән мәгънәсен аңларга тырышкан, ул аның күңел түренә үтеп кергән, әйтерсең лә бу аять хәзер аның өчен иңгән. Егет бу гамәле өчен бик үкенгән һәм аның күңеле тирән рухый халәт кичергән. Аның җаны Аллаһының рәхмәтенә омтылган.

Гомәр бу егетнең үлеме сәбәбен белгәч, аның кабере янына килеп әйткән: «Әй, егет, сиңа Аллаһы Тәгалә ике җәннәт насыйп итсен, чөнки Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дигән:

وَلِمَنْ خَافَ مَقَامَ رَبِّهِ جَنَّتَانِ

**«Раббысының дәрәҗәсеннән курыккан кешегә ике җәннәт бар».**

«Әр-Рахмән / Мәрхәмәтле», 55:46

Кинәт шунда тавыш ишетелгән: «Йә, әмирүл мөэминин, Аллаһы миңа күбрәк нигъмәт бирде».

Авыру килгәнче, сәламәтлекнең кадерен белегез. Шуны истә тотарга кирәк, сәламәтлегебез — Аллаһының безгә карата булган юмартлыгы. Бүгенге көндә күп кенә авырып яткан кешеләр: «Эх, сәламәт булсам, шуны эшләр идем, моны башкарыр идем», — дип үкенә. Иртәгә нәрсә булачагын беркем дә белми, шуңа күрә сәламәтлегебез булганда изге гамәлләребезне иртәгесе көнгә калдырмаска кирәк. Казан шәһәрендәге «Ярдәм» мәчетен мисал итеп

китерәм. Ул сукырлар өчен тернәкләндерү, ярдәм итү үзәге булып тора. Анда төрле өлкәләрдән, шәһәрләрдән килгән гарип кардәшләребез өчен дин гыйлеме һәм тәрбия алырга бөтен шартлар тудырылган. Күзләре күрмәгән кызлар һәм егетләр, апалар һәм абыйлар тырышып динебезне өйрәнә, Коръән сүрәләрен ятлый. Араларында Коръәннең яртысын белүчеләр дә бар.

Хөрмәтле мөселманнар! Маңгай күзләре күрмәсә дә, ул кардәшләрнең күңел күзләре яхшы күрә, алардан үрнәк алырга кирәк! Сәламәтлекләре зәгыйфь булуга карамастан, алар Аллаһының хак динен өйрәнә, Аның чиксез рәхмәтенә, мәңгелек сәгадәткә омтыла. Кайберләребезнең маңгай күзләре күрсә дә, күңел күзләре йомылган шул…

Фәкыйрьлек килгәнче, байлыкның кадерен белегез. Әгәр без матди байлыкка яки ниндидер мөмкинлеккә ия икән, «ахирәт банкы» ндагы хисабыбызны тулыландырып өлгерергә кирәк, иртәгә андый мөмкинлек булмаска мөмкин. Ул банкта инфляция һәм кризис беркайчан да булмаячак. Бүген кайберләребез зур дәрәҗәгә ия, иртәгә ул дәрәҗәгә башкалар ия булырга мөмкин. Кемдер бүген бай, иртәгә фәкыйрь булып калырга мөмкин, шуңа күрә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әйткән сүзләре турында уйланыйк һәм тормышка ашырырга онытмыйк.

Мәшәкатьләр, авырлыклар килгәнче, буш вакытның кадерен белегез. Буш вакыт булганда, аны үзебезгә һәм җәмгыятебезгә файда китерерлек итеп үткәрергә тырышырга кирәк. Ни кызганыч, күпләребез буш вакытны дөрес кулланмый. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Аллаһы Тәгаләнең ике нигъмәте бар, күп кешеләр аларның кадерен белеп бетерми: буш вакыт һәм сәламәтлек», — дигән.[1]

Барысын да сүзгә-сүз бәяләргә ярамый, Ислам бертуктаусыз гыйбадәт кылырга һәм хезмәт итәргә өндәми. Моны аңлар өчен бер хәдис белән танышып үтик.

Беркөнне Хәнзәлә дигән сәхабә өенә кайткач, гаилә тормышына чума, вакытын балалары, туганнары белән шаяруда, гафләттә уздыра. Бер мизгелдә

[1] Әс-Суютый, «Җәмигъ әс-сәгыйрь».

ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында булган вакытларындагы югары рухый халәтне искә төшерә һәм: «Хәнзәлә монафикъ булды!» — ди. Аннары урамга чыгып, «Хәнзәлә монафикъ булды!» дигән сүзләрне бертуктаусыз кабатлый-кабатлый мәчеткә таба юнәлә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына йөгереп килгәч, янә: «Хәнзәлә монафикъ булды!» — дип әйтә. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм, гаҗәпләнеп: «Моны ничек аңларга?» — дип сорый. Хәнзәлә: «Без синең янында булганда һәм син безгә җәннәт белән җәһәннәм турында сөйләгәндә аларны (җәннәт белән җәһәннәмне) күргән кебек булабыз. Синнән аерылгач, дөнья эшләренә чумып, күп нәрсәләрне онытабыз», — дип җавап бирә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай ди: «Йә, Хәнзәлә, әгәр сез минем янымда булгандагы халәтне һәрвакыт сакласагыз, фәрештәләр сезне һәр урында сәламләр һәм кулларыгызны кысар иде. Ләкин, Хәнзәлә, белеп тор, мондый халәт вакыт-вакыт була». Бу сүзләрне ул өч тапкыр кабатлый.[1]

Чыннан да, кеше кайчакта үзенә бертөрле рухый күтәренкелек тоя, ләкин көндәлек мәшәкатьләр белән ошбу халәт югалып тора. Бу табигый хәл һәм Аллаһы Раббыбызны онытуның билгесе түгел. Мәсьәләнең асылы шунда ки, кайбер кешеләр тәүлекнең күп өлешен үзләре өчен генә багышлый, Аллаһы Тәгалә каршында булган бурычларын оныта.

Әлеге хәдистән күренгәнчә, әгәр башкарылган гамәлләр шәригать кысаларыннан чыкмаса, Исламда ялга һәм күңел ачуга тыю юк.

Үлем килгәнче, гомернең кадерен белегез. Мөхтәрәм мөселманнар! Түбәндәге аятьләргә игътибар итик. Аллаһы Тәгалә «Монафикълар» сүрәсенең 9–11нче аятьләрендә болай дип әйткән:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تُلْهِكُمْ أَمْوَالُكُمْ وَلَا أَوْلَادُكُمْ عَن ذِكْرِ اللَّهِ ۚ وَمَن يَفْعَلْ
ذَٰلِكَ فَأُولَٰئِكَ هُمُ الْخَاسِرُونَ ۝ وَأَنفِقُوا مِن مَّا رَزَقْنَاكُم مِّن قَبْلِ أَن يَأْتِيَ

[1] Мөслим.

أَحَدَكُمُ الْمَوْتُ فَيَقُولَ رَبِّ لَوْلَا أَخَّرْتَنِي إِلَىٰ أَجَلٍ قَرِيبٍ فَأَصَّدَّقَ وَأَكُن مِّنَ
الصَّالِحِينَ ۞ وَلَن يُؤَخِّرَ اللَّهُ نَفْسًا إِذَا جَاءَ أَجَلُهَا ۚ وَاللَّهُ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ

**«Ий, иман китерүчеләр! Малларыгыз** [белән булашуыгыз] **да, балаларыгыз да** [намаз, җиһад һәм Коръән уку кебек] **Аллаһыны зикер итүдән** [һәм гыйбадәт кылудан] **сезне тайпылдырмасын. Кем дә кем моны эшләсә,** [кыйммәтле һәм мәңгелек булган бернәрсәне гади һәм фани дөнья бәрабәренә сатканы өчен] **зарар күрүчеләр булырлар.**

**Сезнең берәрегезгә үлем** [галәмәтләре] **килгәнче Безнең сезгә ризык итеп биргән нәрсәләрнең бер өлешен** [Ахирәткә бер әзерлек буларак, мохтаҗларга] **сарыф итегез, соңыннан** [авырлык күргәч]**: «Ий, Раббым! Мине** [үлememне] **якын бервакытка кадәр кичектерсәң, күп итеп садака бирер идем һәм** [Сиңа карата булган вазифаларымны тиешенчә үтәп] **изге кешеләрдән булыр идем», — дияр.**

«Әл-Мүнәфикун / Монафикълар», 63:9–11

Аллаһы әҗәле җиткән җанга кичектерү бирми. Аллаһы сезнең ни кылганнарыгыздан хәбәрдар».

Кешегә бирелгән гомернең вакыты беткәннән соң, хәтта бер мизгелгә дә аны беркем озынайта алмас. Мәңгелек капкаларына илтүче тормыш юлы һәрберебез өчен билгеләнгән һәм чикләнгән. Һәр мизгелебез, һәр сулышыбыз чикләнгән, һәм моны Аллаһы Тәгаләдән башка беркем дә белми. Шуңа күрә безгә бирелгән санаулы вакытны файдалы итеп үткәрү өчен өлгерергә тырышу лазем. Бер риваять белән таныштырып үтәм.

Элекке заманда яшәгән бер вәли (изге кеше) үз өендә кабергә охшаган чокыр казып куйган. Аллаһы Тәгаләне онытып, күңеленең каралганын тойган вакытта ул шул чокырга төшкән. Шунда ятып, күзләрен йомып, үзен үлгән кеше итеп күз алдына китергән. Шуннан соң үлем хәлендә булган вакытта әйтелә торган сүзләрдән торган аятьне укыган:

حَتَّىٰٓ إِذَا جَآءَ أَحَدَهُمُ ٱلْمَوْتُ قَالَ رَبِّ ٱرْجِعُونِ ۝ لَعَلِّىٓ أَعْمَلُ صَٰلِحًا
فِيمَا تَرَكْتُ ۚ كَلَّآ ۚ إِنَّهَا كَلِمَةٌ هُوَ قَآئِلُهَا ۖ وَمِن وَرَآئِهِم بَرْزَخٌ إِلَىٰ يَوْمِ يُبْعَثُونَ

«[Кяферләр ширек кылуларын дәвам итәчәкләр]. **Аларның берәрсенә үлем килгәч,** [кылган гамәлләренә үкенеп] **әйтер: «Ий, Раббым! Мине** [тормышка] **кире кайтар! Бәлки, мин калдырып киткәнемдә** [намаз, ураза, хаҗ, зәкят кебек кылырга тиешле булган] **изге гамәл кылырмын». Юк!** [Аның бу үтенече берничек тә кабул ителмәячәк]. **Һичшиксез, ул** [тормышка кайтарылу үтенече турында әйтелгән буш] **бер сүз ки, аны ул** [үзенә] **әйтә. Аларның алларында терелтеләчәк көнгә кадәр** [дәвам итәчәк] **бер киртә бар** [ул — кабер киртәсе, һәм кабер галәме аларның кабат дөнья тормышына кайтуларына бер комачау булып калачак. Ахирәттәге тормышлары исә дөньядагыдан бик нык аерылачак]**».**

«Әл-Мүэминүн / Мөэминнәр», 23:99–100

Бу аятьне укыганнан соң ул, күзләрен ачып, үз-үзенә: «Менә син хәзер дөнья тормышында. Сиңа тагын бер мөмкинлек бирелде. Хәрәкәттә бул, игелекле гамәлләр кыл. Бәлки, бу синең соңгы мөмкинлегеңдер», — дип әйтә торган булган.

Хәдис-шәрифтә әйтелгән: «Үлемне искә төшерегез, аны искә төшерү дөньядагы ләззәтләрне оныттыра» (Тирмизи).

Ләкин кайберәүләр үлемне искә төшерергә курка, бүгенге көн белән яшәп, иртәгесе турында уйланмый. Фани дөнья өчен генә яшиләр, мәңгелек тормыш турында фикер йөртмиләр. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дөреслектә, кешенең күңеле, тимер күгәргән кебек, тутык белән каплана», — дигән. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән сораганнар: «Күңелне нәрсә пакьли алыр соң?» Ул үз җавабында: «Коръәнне уку һәм үлемне искә төшерү», — дигән.

Хөрмәтле мөселманнар! Бу дөнья тормышы бер мизгел генә, хәтта Аллаһы Тәгалә каршында бөек дәрәҗәләргә ия булган пәйгамбәрләр дә

дөнья тормышының шулай икәнлеген бик яхшы тойган. Билгеле булганча, Нух галәйһиссәлам үз вакытында иң озын гомерлесе булган. Ул мең ел яшәгән. Аның янына үлем фәрештәсе килгәч, аннан сораган: «Әй, Аллаһының расүлләре арасында иң озын гомерле булган пәйгамбәр, бу дөньяны ничек күрдең?» Нух галәйһиссәлам болай дип җавап биргән: «Мин бу дөньяны ике ишекле өйгә охшаттым. Бер ишектән керәсең, икенчесеннән чыгасың».

Үлем сәгате Аллаһыдан башка беркемгә дә билгеле түгел, шуңа күрә ул вакытка әзер булырга кирәк. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Зирәк һәм акыллы кеше үз-үзен тикшерә һәм үлемгә әзерләнә», — дигән (әс-Суютый, «Җәмигъ әс-сәгыйрь»). Әгәр бу хәдистә әйтелгәнчә яшәсәк, без, ин шәә Аллаһ, Коръәндә искә алынган әҗергә ирешербез:

رَّضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ وَرَضُواْ عَنْهُ

**«Аллаһ алардан разый, алар да Аннан разыйлар»**

«Әл-Маидә / Табын», 5:119

Раббыбыз Аллаһы Тәгалә барчабызга Аның безгә бүләк итеп биргән нигъмәтләренең кадерен белергә, дөрес итеп кулланырга насыйп итсә иде.

* * *

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә дәүләт җитәкчебезнең саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Нияз хәзрәт Сабиров,*

*«Апанай» мәчетенең имам-хатыйбы, ТҖ МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы*

*5нче гыйнвар вәгазе,*

*җөмәдәл-ахыр аеның 23нче көне, һиҗри исәп буенча 1445 ел*

# Аллаһы Тәгаләнең Әр-Раззак исеме

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмииин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил-Кәрим. Вә галәә әәлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Газиз дин кардәшләрем, безгә Үзенең чиксез нигъмәтләрен бүләк итүче Бөек Раббыбыз Аллаһы Тәгаләгә туктаусыз хәмедләребез, шөкерләребез, сәналәребез булса иде. Аның Илчесе, безгә рәхмәт итеп җибәрелгән пәйгамбәребез һәм бөек остазыбыз Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Аллаһы Тәгаләнең сәламнәре һәм бәрәкәтләре булса иде. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Кадерле дин кардәшләр, җомга саен без сезнең белән Аллаһы Тәгаләнең чиксез нигъмәтләре дип башлап җибәрәбез. Шул сәбәпле, бүгенге җомгабызда Аллаһы Тәгаләнең, чыннан да, чиксез нигъмәтләрен исебезгә төшереп китәрбез. Аллаһы Тәгаләнең Әр-Раззак исеме бар, ягъни Аллаһы Тәгалә — Ул Ризыкландыручы. Әлеге төшенчәгә бик күп нәрсә керә. Гомумән алсак, бөтен нигъмәтләр.

Аллаһы Тәгалә Үзенең нигъмәтләре турында Коръәндә хәбәр биргәндә әйтә:

وَإِن تَعُدُّوا نِعْمَةَ اللَّهِ لَا تُحْصُوهَا ۗ إِنَّ اللَّهَ لَغَفُورٌ رَّحِيمٌ

> **«Аллаһының** [сезгә биргән бөтен] **нигъмәтләрен саный башласагыз, аларны санап бетерә алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы —** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче, Рәхимле».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:18

Ул чыннан да шулаймы, ни өчен? Санап китәргә мөмкин, әмма без аларның барысын да искә төшереп бетерә алабызмы, юкмы — монысы беренче мәсьәлә, һәрберсенә игътибар итә алабызмы, юкмы — монысы икенче мәсьәлә. Һәм дә инде тагын бер мәсьәлә — Аллаһы Тәгаләнең сыйфатлары абсолют, Аллаһы Тәгаләнең сыйфатлары чиксез, кодрәте дә чиксез, белеме дә чиксез, Аллаһы Тәгаләнең ирадәсе дә чиксез, шул сәбәпле, Аның нигъмәтләре дә чиксез. Без ул нигъмәтләрне санап, белеп бетерерлек түгел. Кайбер әйберләрнең хикмәтләрен без сезнең белән аңлап та бетермибез. Берәрсенең тормышында кайгы-хәсрәт килә, ул аны начарлык дип уйлый, әмма дә ләкин күпмедер еллар узгач, ул аны Аллаһы Тәгаләнең нигъмәте икәнлеген аңларга мөмкин. Шуның өчен Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләрен хисаплап бетерерлек түгел. Без фәкать аларның кайбер төрләрен генә бүген искә алырбыз.

Аллаһы Тәгаләнең мөэмин-мөселман кешегә карата булган иң олы нигъмәте — иман нигъмәте. Ул нигъмәттән олырак нигъмәт булырга мөмкин түгел. Ул нигъмәт турында Аллаһы Тәгалә Коръәндә:

بَشِّرِ الَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا الصَّالِحَاتِ أَنَّ لَهُمْ جَنَّاتٍ تَجْرِي مِن تَحْتِهَا الأَنْهَارُ

> «**Иман китерүчеләрне һәм** [намаз, ураза, хаҗ, зәкят кебек Китап белән сөннәткә муафыйк] **изге гамәлләр кылучыларны, аларга** [сарайлары һәм агачлары] **асларыннан елгалар аккан җәннәтләр белән сөендер».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:25

Димәк, Аллаһы Тәгаләнең иманлы кешеләр өчен әзерләгән бүләге бар. Ә киресе ничек? Аллаһы Тәгалә әйтә:

«Әмма дә ләкин кяфер булганнар, иман китермәгәннәр хайваннар шикелле бу дөньяда рәхәтләнәләр, хайваннар ашаган шикелле ашыйлар, һәм

аларның урыннары җәһәннәм уты, җәһәннәм газабы».

وَلَقَدْ ذَرَأْنَا لِجَهَنَّمَ كَثِيرًا مِّنَ الْجِنِّ وَالْإِنسِ ۖ لَهُمْ قُلُوبٌ لَّا يَفْقَهُونَ بِهَا وَلَهُمْ أَعْيُنٌ لَّا يُبْصِرُونَ بِهَا وَلَهُمْ آذَانٌ لَّا يَسْمَعُونَ بِهَا ۚ أُولَٰئِكَ كَالْأَنْعَامِ بَلْ هُمْ أَضَلُّ ۚ أُولَٰئِكَ هُمُ الْغَافِلُونَ

> «**Без җеннәрдән һәм кешеләрдән күбесен** [көферлектә калуны сайлаганнарын белгәнебезгә күрә, аларны] **җәһәннәм өчен яралттык. Аларның йөрәкләре бар,** [әмма] **алар** [шул йөрәкләре] **белән** [хакыйкатьне] **аңламаслар. Аларның күзләре бар,** [ләкин] **алар белән күрмәсләр. Аларның колаклары бар,** [тик] **алар белән ишетмәсләр. Алар** [төшенү җитмәү, гыйбрәт алмау һәм фикерләп тыңламау ягыннан] **хайваннар кебек. Хәтта алар ныграк адашкан. Алар —** [Аллаһыны оныткан] **гафил кешеләр».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:179

Нәтиҗә бөтенләй башка. Иманлыларга мәңгелек бүләк, имансызларга мәңгелек газап. Шул сәбәпле, иман — ул Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән иң олы бүләге. Шуны да әйтеп китәргә кирәк, ахирәттә генә түгел, бу дөньяда да иманлы кеше иманын аңлы рәвештә кабул итә икән, ул бу дөньяда аңлы килеш яши. Иманлы кеше үзенең нәфесен акылына буйсындырып, күп зарарлы нәрсәдән тыела һәм күп файдалы нәрсәләрне үзләштерергә мөмкин. Иман ул кешене төрле бозыклыклардан, зинадан, исерткечтән, кеше малын таладан да, кешене үтерүдән дә саклый торган бер корал. Шулай ук хакыйкый иман адәм баласын яхшы гамәлләргә этәргеч булган корал дип әйтергә була, чөнки иман безне гыйбадәткә этәрә, бер-беребез белән уңай мөнәсәбәттә булырга этәрә. Димәк, безгә бүләк ителгән иман — ул Аллаһы Тәгаләнең иң зур нигъмәте һәм безнең өчен ул зур байлык.

Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләренең тагын бер төре адәм баласының тәне белән бәйле. Безнең күбебез ул аятьне белә һәм укый. Аллаһы Тәгалә әйтә:

لَقَدْ خَلَقْنَا الْإِنسَانَ فِي أَحْسَنِ تَقْوِيمٍ

**«Без кешене иң күркәм сурәттә яралттык».**

«Әт-Тин / Инҗир», 95:4

Чыннан да, адәм баласының тәнен тикшерә башласак, Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләрен исәпләп бетерерлек түгел. Аллаһы Тәгаләнең безнең тәнебезгә һәм, гомумән, адәм баласына биргән, тәне белән бәйле булган иң олы нигъмәте — акыл. Игътибар итсәгез, Аллаһы Тәгалә баш миен кешенең тәнендә иң югары урынга куйган. Акыл баш мие белән бәйле. Акыл — ул адәм баласын хайваннан аера. Шәригать галимнәре кеше турында: «Кеше акыл иясе булган хайван», — дип язалар. Чыннан да, бездә хайван сыйфатлары бар: ризыкны эшкәртә торган система бертөрле, мускуллар, сөякләр төзелеше охшаган. Әмма дә ләкин аера торган бер корал бар, ул да булса — акыл. Акылы белән адәм баласы куйган бик күп максатларына ирешергә мөмкин. Акыл белән без атомны ярып, бүген атом электростанцияләре төзеп, үзебезнең өйләребезне яктыртабыз, җылытабыз; акыл көче белән без үзебезгә нефть энергиясен буйсындырып, машиналарга утырып йөрибез; акыл белән без үзебезгә электр һәм башка энергияне буйсындырып, интернет шикелле әйбер белән файдаланып, үзебезгә файдалы мәгълүмат таба алабыз. Мәгълүмат кына түгел, дөньяның бер-берсеннән ерак һәм төрле почмакларында булган ике туганны тоташтырырга мөмкин. Барысы да акыл нәтиҗәсендә. Акыл иманның ярдәмчесе булып, адәм баласын бозыклыктан тыеп, яхшылыкны күрсәтә торган бер корал.

Акылдан башка Аллаһы Тәгалә безнең тәнебезгә биргән нигъмәтләр күп. Ул да булса — күрү нигъмәте һәм ишетү нигъмәте. Күрү нәтиҗәсендә бу дөньядагы 80% мәгълүматны кабул итәбез. Ишетү һәм башка тойгылар аркылы — калганын. Әгәр дә күрә һәм ишетә алмасак, дөньябыз нинди күңелсез булыр иде. Әгәр дә тәмне тоя алмасак, тагын да күңелсез булыр иде. Әгәр дә җылыны, салкынны тоя алмасак… Болары да Аллаһы Тәгаләнең нигъмәте.

Тәнебездә булган тагын бер нигъмәт, ул да булса, — Аллаһы Тәгалә безнең тәнебезгә көч-куәт биргән. Һәм шул көч-куәт белән файдаланып, без үзебезнең дөньябызны алып барабыз. Ашыйсыбыз да, эчәсебез дә килә, машинада да утырып йөрисебез килә. Монысы инде тәнгә көч биреп, Аллаһы Тәгалә безгә боларга ирешер өчен мөмкинчелек бирә. Монысы да Аллаһы Тәгаләнең олы нигъмәте.

Эчке әгъзаларыбызга килгәндә, һәрбер әгъза Аллаһы Тәгаләнең бер олы бүләге һәм нигъмәте. Бавыр белән бөерне алсак, безнең тәнне чистарталар, үпкәне алсак, тәнебезне һава белән, йөрәкне алсак, тәнебезне кан белән тәэмин итәләр. Безнең тәнебездә дә, эчебездә дә Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләре бик күп, хисапсыз.

Аллаһы Тәгалә безгә биргән нигъмәтләрнең өченче төре, ул да булса без яши торган дөнья белән бәйле. Алар шулай ук хисапсыз. Аллаһы Тәгалә безне һәрберебезне хайваннардан аерып, акыл бүләк итеп һәм башка төрле нигъмәтләр биреп, һәрберебезне өстен итте, һәрберебезгә шәхсән хөрмәт күрсәтте. Аллаһы Тәгалә ул хөрмәтләрнең, нигъмәтләрнең мисалларын китерә:

وَلَقَدْ كَرَّمْنَا بَنِي آدَمَ وَحَمَلْنَاهُمْ فِي الْبَرِّ وَالْبَحْرِ وَرَزَقْنَاهُم مِّنَ الطَّيِّبَاتِ وَفَضَّلْنَاهُمْ عَلَىٰ كَثِيرٍ مِّمَّنْ خَلَقْنَا تَفْضِيلًا

**«Без Адәм улларын шәрәфле кылдык. Аларны корыда һәм диңгездә йөрттек. Аларга ризыклар бирдек һәм Без бар иткән мәхлукларның күбесеннән аларны өстен кылдык».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:70

Бу Аллаһы Тәгаләнең бүләге. Аллаһы Тәгалә безгә гыйлем биреп, адәм баласының иң беренче, олы ачышы, ул да булса — тәгәрмәч. Безне җир буенча йөртер өчен бу Аллаһы Тәгаләнең зур нигъмәте. Аны ачмасак, ничек йөрер идек, җәяү йөрисең инде, башкача мөмкинчелек юк. Җәяү яки атка атланып,

ләкин атка күп әйбер төяп булмый. Хәтта күчмә тормыш белән яшәсәң дә, арбаң булмаса авыр. Машина тәгәрмәчсез йөри алмый, анысы да билгеле.

Шулай ук икенчесе — Аллаһы Тәгалә әйтә: «Без аларны су өстеннән йөртәбез». Монысы да Аллаһы Тәгаләнең нигъмәте. Әгәр дә су әйберләрне үз өстендә тота торган булмаса, без шулай ук дөньяның бер тарафыннан икенче тарафына йөри алмас идек һәм үзебез өчен файдалы әйберләрне ташый да алмас идек. Монысы да Аллаһы Тәгаләнең нигъмәте.

Әле бу аятьтә зикер ителмәгән тагын бер нигъмәт бар. Бүгенге көндә Аллаһы Тәгалә безне һавадан йөртә. Әлбәттә, ул Коръәннең башка бер аятендә бар. Аллаһы Тәгалә әйтә: «Әй, сез җеннәр һәм кешеләр, әгәр дә сез күк һәм җир чикләрен узырга теләсәгез, узыгыз. Әмма дә ләкин сезгә моның өчен солтан (энергия, көч) кирәк». Димәк, Аллаһы Тәгалә безне һавадан да йөртә. Һава законнарын үзебезгә буйсындырып, без һавадан үзебез өчен файдалана алабыз.

Шулай ук Аллаһы Тәгалә әйтә:

انظُرْ كَيْفَ فَضَّلْنَا بَعْضَهُمْ عَلَىٰ بَعْضٍ

> «[Расүлем!] **Безнең** [тоткан урын, мал һәм хакимият кебек мәсьәләләрдә] **аларның берәүләрен икенчеләреннән ничек өстен кылганыбызны кара...»**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:21

Кешенең ризыгын һәм хайванның ризыгын чагыштырып карагыз. Кеше бәрәңгесен ашый, хайван сабагын ашый. Бананның эчен ашыйбыз, кабыгын хайванга бирәбез. Хайван салкын сарайда яши, ә без, кешеләр, мич белән җылытылган өйләрдә яшибез. Монысы да Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән бер олы нигъмәте. Шулай ук гаурәтебезне каплар өчен бирелгән кием дә ризыкка керә, машиналарыбыз, өйләребез — барысы да Аллаһы Тәгаләнең нигъмәте.

Чыннан да, беренче аятьтә әйтелгәнчә:

وَإِن تَعُدُّوا نِعْمَةَ اللَّهِ لَا تُحْصُوهَا ۗ إِنَّ اللَّهَ لَغَفُورٌ رَّحِيمٌ

**«Аллаһының** [сезгә биргән бөтен] **нигъмәтләрен саный башласагыз, аларны санап бетерә алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы —** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче, Рәхимле».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:18

Шуның өчен өстебездә булган төп бурыч — Аллаһы Тәгаләгә шөкер итү.

Вәгазебезне йомгаклап, статистика белән бәйле мәгълүматларны карап китик. Бер мәкаләдә әйтелгән: «Әгәр дә сез иртә белән сау-сәламәт хәлегездә уянсагыз, сезнең хәлегез миллионлаган кешеләргә караганда яхшырак». Никадәр кеше бүген хастаханәләрдә ята, кадерле дин кардәшләрем. Ә без сезнең белән җомгада җыелдык. Димәк, Аллаһы Тәгалә безгә саулык-сәламәтлек биреп, безне монда китергән. «Әгәр дә сез ач хәлдә, мәзлум хәлдә төрмәдә булмасагыз, сез бәхетле кеше, чөнки биш йөз миллион кеше бу рәхәтлектән мәхрүм». Димәк, бүгенге көндә биш йөз миллион кеше (ярты миллиард) шул авырлыкларга дучар. Ачлык, төрмә яки тагын берәр бәла. «Әгәр дә сез бернинди хәвеф-хәтәрсез, курыкмыйча үзегезнең динегез буенча яшисез икән, сез өч миллиард кешегә караганда бәхетлерәк». Димәк, кешелекнең яртысы бу яктан караганда авыр хәлдә яши икән: динсез яки диннәрен тотканнары өчен куркыныч яный. Без исә җомгаларыбызга җыелабыз, беркем тыймый. «Әгәр дә сезнең йортыгыз, киемегез булса, суыткычыгызда ризыгыгыз булса, сез 75 % кешегә караганда байрак». Бу — Аллаһы Тәгаләнең нигъмәте. Бүгенге көндә җиде миллиард кеше бар, шуннан биш миллиард кеше бүгенге көндә матди яктан безгә караганда күпкә авыррак җирләрдә яши. Шушы вәгазьнең ахырында килгәне буенча: «Әгәр дә сез бу вәгазьне үзегез укый алсагыз, сез дөньяда яшәгән ике миллиард кешегә караганда бәхетлерәк», чөнки дөньяда ике миллиард кеше укый-яза белми. Монысы да Аллаһы Тәгаләнең нигъмәте.

Шуның өчен, кадерле дин кардәшләрем, Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләрен хисаплап бетерерлек түгел. Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә аларны истә тотып, шөкер итүчеләрдән булсак иде. Һәм шөкер итү сәбәпле Аллаһы Тәгалә безгә биргән нигъмәтләрен арттырса иде.

* * *

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», — дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә дәүләт җитәкчебезнең саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Габдулла хәзрәт Әдһәмов,*

*Казан Ислам университетының өлкән укытучысы*

# «Нәрсә? Кайда? Кайчан?»

# ИЮЛЬ–СЕНТЯБРЬ

## 2023 елда Татарстаннан 1800 мөселман хаҗ кылды

2023 елда «ДУМ РТ Хаҗ» компаниясе белән 1800 кеше хаҗ кылу бәхетенә иреште. Барлык хаҗилар да хаҗ гамәлләрен тиешле рәвештә үтәп чыкты. Сәфәрдә аларны шәригатьне һәм гарәп телен белүче тәҗрибәле җитәкчеләр һәм табиблар озатып йөрде. Алар хаҗ кылу кагыйдәләрен аңлатты һәм хаҗиларның иминлеге өчен җавап бирде. Барлык хаҗилар да, сәфәргә чыкканчы ук, Татарстан мәчетләрендә махсус курсларда белем өстәде.

Хаҗилар өчен быел 4 төрле программа эшләнде. Алар бер-берсеннән әл-Харам мәчетеннән ераклык һәм кунакханәнең дәрәҗәсе, сәфәр озынлыгы, маршрут (очкыч яки катнаш — очкыч+автобус), туклану (2 тапкыр яки швед өстәле), программага корбанның кертелүе һәм башка хезмәтләрнең булуы белән аерылып торды.

2023 елда бөтен дөньядан 1,8 миллион кеше хаҗ кылды. Коронавирус пандемиясе белән бәйле рәвештә кертелгән барлык чикләүләр быел бетерелде.

## Актаныш мөхтәсибәтендә яңа мәчет ачылды

Зөлхиҗҗә аеның 13 нче көнендә (1 июльдә) Актаныш районы Югары Яхшый авылында «Дәүҗия» мәчете ачылды. Яңа мәчеткә нигез ташы 2022 елның 4нче июнендә салына. Төзелеш беренче көннән Тимербулат Әхмәдуллин иганәлегендә алып барыла һәм мәчеткә аның әнисенә багышлап, «Дәүҗия» исеме бирелә. Төзү эшләрен исә үз бригадасы белән Җәүдәт Заһитов башкара.

Кирпечтән салынган яңа мәчетнең беренче катында 45 кеше сыйдырышлы ир-атлар залы, икенче катта 18 кешегә исәпләнгән хатын-кызлар залы урнашкан. Ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен уңайлы тәһарәтханә бар,

электр, газ, су кертелгән, идәннәр җылытылган. Мәчеттә — ифтарлар һәм зур булмаган мәҗлесләр уздыру өчен ашханә; 25 кешелек янкорма да бар. Ишегалды төзекләндерелгән, агач-куаклар утыртылган, брусчатка җәелгән.

Хәзерге вакытта Актаныш мөхтәсибәтендә, Югары Яхшый авылындагысын да исәпкә алып, 55 мәчет эшли.

## Татарстанда Корбан бәйрәме нәтиҗәләренә йомгак ясадылар

Диния нәзарәте узып киткән Корбан бәйрәменә нәтиҗәләр чыгарды. 2023 елда республикабызда, Россия ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе биргән мәгълүматлар буенча, корбан чалыр өчен 58, шул исәптән, Казанда 18 махсус мәйданчык оештырылды. Татарстанда шушы мәйданчыкларда, Казанны да кертеп, барлыгы 13 806 баш мал чалынды. Казанның үзендә 5812 баш хайван корбанлык булды.

Татарстан районнары һәм шәһәрләре арасында алдынгы булып Яр Чаллы мөхтәсибәте тора: биредә 1495 сарык корбанга чалынды. Аннан соң Лаеш (1360), Яшел Үзән (1009), Лениногорск (920) мөхтәсибәтләре килә. Казанда иң күп мал чалган урыннар булып «Казан нуры» (2553 сарык), «Рамазан» (423 сарык) һәм «Ризван» (400 сарык) мәчетләре тора.

Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды, социаль акция кысаларында халыкның мохтаҗ катламнарына тарату өчен, 255 сарык һәм 3 сыер чалды. Шулай итеп, быел Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды 4 тоннадан артык корбан итен мохтаҗларга таратты һәм социаль проектларга җибәрде. Корбан бәйрәме көннәрендә 500 мохтаҗга: аз керемле һәм күп балалы гаиләләргә, инвалидларга, ятимнәргә, ялгыз гомер итүче өлкән яшьтәгеләргә — 1,5 тонна корбан ите өләшенде; 300 кг ит Татарстанның 4 социаль учреждениесенә — Анжела Вавилова исемендәге Казан хосписына, Татарстандагы инвалид балалар ата-аналарының «Забота» төбәк иҗтимагый оешмасына, «Мамы Казани»

хәйрия фондына, диабет үзәгенә тапшырылды. Итнең калган өлешен «Зәкят» фонды суыткычларга саклауга куйды һәм ел дәвамында йорт-җирсез, аз керемле, өлкән яшьтәге ялгыз кешеләргә, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм башка мохтаҗ кешеләр өчен хәйрия ашлары әзерләүдә кулланырга ниятли.

## Арча шәһәрендә «Дини йола» үзәге төзелеше башланды

Зөлхиҗҗә аеның 23нче көнендә (11 июльдә) мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Арча мөхтәсибәтенә эшлекле сәфәр кылды. Биредә ул район имамнары җыелышында һәм «Дини йола» үзәге төзеләчәк бинага беренче таш салу тантанасында катнашты. «Дини йола» үзәге Арча шәһәре Үзәк мәчете янында төзелә. Үзәк, беренче чиратта, балаларны, яшь буынны дини кануннар нигезендә тәрбияләү мөмкинлекләрен үстерергә ярдәм итәчәк. Биредә мөселман балалар бакчасын ачу көтелә. «Дини йола» үзәге шулай ук, шәригать кануннарына туры китереп, мәрхүмнәрне соңгы юлга озатуны башкарачак. Гомуми мәйданы 800 квадрат метр булган бинаны 2024 елда кулланылышка тапшыру көтелә.

Арча мөхтәсибәте республикабызда 92 мәчетле иң зур мөхтәсибәт. Район күләмендә мәчет каршындагы курсларда белем алучыларның гомуми саны — 1300 кеше. Аларга 88 имам һәм 140 укытучы Ислам нигезләре буенча белем бирә. Узган ел ачылган Г. Тукай исемендәге рухи-мәгърифәт үзәгенә 150 шәкерт кабул ителде. Биредә шулай ук Коръән ятлау бүлеге эшләп килә.

## Чүпрәле мөхтәсибәтендә яңа мәчет ачылды

Зөлхиҗҗә аеның 28нче көнендә (16 июльдә) Чүпрәле районы Яңа Чәке авылында тантаналы рәвештә яңа мәчет үз ишекләрен ачты. Яңа Чәке авылында мәчет булдыру фикере — Илдар Шәрәфетдиновныкы. Ул мәрхүм әтиәнисенең йортын мәчет бинасы итү фикерен шушы авылны җитәкләгән

Рафаил Алимовка белдерә. 2022 елда мәхәллә тарафыннан бертавыштан мәчет булдырырга карар кылына һәм бу изге ният бер ел эчендә бөтен халык көче белән тормышка ашырыла. Мәчет нигезнең хуҗабикәсе, динебезне хөрмәтләп яшәгән Гөлсәйран исеме белән атала. Имам итеп Илдар Шәрәфетдинов сайлана.

Мәчет 40 кеше өчен исәпләнгән, газ, ут, су кергән, әйләнә-тирәсе коймалар белән тотылган. Мәчеттә дәрес алу өчен барлык мөмкинлекләр тудырылган, Нәзарәтнең «Хозур» нәшрият йортыннан дини әдәбият кайтартылган. 2023 елның көзеннән мәчет каршындагы курсларны башлап җибәрү көтелә.

Яңа Чәке авылында мәчет ачылганнан соң, Чүпрәле мөхтәсибәтендә халыкка 27 мәчет хезмәт күрсәтә башлады.

## Казанның мохтаҗ гаиләләре азык-төлек белән тәэмин ителде

Зөлхиҗҗә аеның 30нчы көнендә (18 июльдә) Татарстан мөфтиятенең «Зәкят» хәйрия фонды 60 мохтаҗ гаиләгә азык-төлек җыелмалары таратты. Хәйрия фондыннан әлеге ярдәмне ялгызы балалар үстерүче аналар, күп балалы гаиләләр, ялгыз пенсионерлар, авыру мохтаҗлар, инвалид бала тәрбияләүчеләр алды. Һәр азык-төлек җыелмасына он, ярмалар, көнбагыш мае, шикәр, тушенка, макарон һәм чәй кебек иң кирәкле ризыклар кертелгән. Фонд азык-төлек җыелмаларын дин кардәшләребез биргән садакалар, битараф булмаган кешеләрнең матди ярдәме белән әзерләде.

## Татарстан мөфтие «Ибн Фадлан» фильмын төшерү төркеме белән очрашты

Мөхәррам аеның 2нче көнендә (20 июльдә) Нәзарәт бинасында мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм аның мәгълүмати сәясәт буенча урынбасары, «Хозур» нәшрият йорты җитәкчесе Ришат хәзрәт Хәмидуллин «Ибн Фад-

лан» документаль-нәфис фильмын төшерү төркеме белән очрашты. Хәзрәт белән әңгәмә корырга генераль продюсер, сценарист, режиссёр-куючы Айназ Мөхәммәтҗанов, сценарист һәм режиссёр-куючы Рәмис Нәҗмиев, башкаручы продюсер Влада Крылова, оператор-куючы Алексей Матросов, төп рольне – Әхмәд бине Фадланны уйнаган Зөлфәт Закиров, продюсер ярдәмчесе, Алмыш ханның хәләл җефете ролендәге Айгөл Әхмәтова килде.

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин кинематографның дин, мәдәният, тарихи аң һәм җәмгыятьне рухи яктан тәрбияләү эшендә мөһим булуын ассызыклады. Башка тарихи фильмнарны да төшерүдә катнашкан хәзрәт, «Ибн Фадлан» фильмын төшерүчеләрне яңа проектларга рухландырып, үз идеяләре белән уртаклашты. Айназ Мөхәммәтҗанов җитәкчелегендәге иҗат төркеменә ихлас тырышлык куеп эшләүләре өчен рәхмәт белдерде. Ришат хәзрәт Хәмидуллин фильмны төшерү һәм прокатка чыгаруга гомуми нәтиҗәләр ясады, «Хозур» нәшрият йортының «Ибн Фадлан»ны YouTube-ка куюы хакында хәбәр итте.

## Саба мөхтәсибәтендә мөселман Сабан туе үткәрелде

Мөхәррам аеның 5нче көнендә (23 июльдә) Саба мөхтәсибәте Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысаларында республикакүләм мөселман Сабан туен оештырды. Ул халкыбыз хәтерендә сакланган тарихи җирлектә — борынгы Өтернәс шәһәрлеге янында (хәзерге Иләбәр авылы) үткәрелде.

Мөселман Сабан туе Коръән уку һәм Казан ханлыгын яклап шәһит киткән бабаларыбыз рухына дога кылу белән ачылды. Аннан хәзрәтләр татар-мөселман үзенчәлекләрен һәм гореф-гадәтләрне саклау, яшүсмерләр күңеленә рухи кыйммәтләрне сеңдерүнең әһәмияте, тәрбияле, әдәп-әхлаклы булу, өлкәннәрне хөрмәтләү һәм башка күркәм сыйфатлар хакында нәсыйхәтләрен җиткерде. Мөселман Сабан туена ир-атларга түбәтәйдән, хатын-кызларга яулыктан килү шарты куелды, хәләл ашамлыклар һәм товарлар

белән сәүдә итү оештырылды. Әлеге Сабантуйның үзенә генә хас үзенчәлеге – бәйрәмгә килгән халыкның бергәләшеп мәйдан уртасында өйлә намазы укуы булды.

## Чаллы Җәмигъ мәчетенең төп гөмбәзенә ярымай куелды

Мөхәррам аеның 7нче көнендә (25 июльдә) Чаллы шәһәрендә истәлекле вакыйга — Җәмигъ мәчетенең төп гөмбәзенә ярымай урнаштыру тантанасы узды. Тантана Чаллы шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе Фәрит Сәлаховның һәм имам-мөхтәсиб Әлфәс хәзрәт Гайфуллинның сәламләү һәм котлау сүзләре белән башланып китте. Соңрак, Коръән укып дога кылганнан соң, тәкъбир әйтеп, Җәмигъ мәчетнең төп гөмбәзенә ярымай урнаштырылды. Өйлә намазы мәчетнең 3нче катында укылды.

## Балтач районында Чишмә бәйрәме үтте

Мөхәррам аеның 11нче көнендә (29 июльдә) Балтач районы Бөрбаш Сәрдегәне авылында Чишмә бәйрәме үткәрелде. Быел дүртенче тапкыр оештырылган бәйрәмдә дин әһелләре, авыл халкы, кунаклар катнашты. Әлеге чара табигатьнең матур урынында — Нурзидә чишмәсе янәшәсендә оештырылды. Авыл халкын тәбрикләп, чишмәләрне һәм сулыкларны кадерләп торуның әһәмияте, аның иң матур үрнәге биредә булуы хакында чыгышлар ясалды. Сәламләү чыгышларыннан соң мәйданда Сабантуй уеннары: чүлмәк вату, күз бәйләп әйбер кисү, чиләк белән су ташу, капчык киеп йөгерү, таяк тарту, әтәч куып тоту, капчык сугышы, авыш колгага менү, кул көрәше һәм көрәш булды.

Әлеге чишмәнең тарихы Балтач районы өчен бик истәлекле. 2013 елда Бөрбаш Сәрдегәне авылыннан Габделнур Хөсәенов, төрле тарафтагы 7 чишмәне казып чыгарып һәм аларны берләштереп, 2017 елда яңарту эшләрен тәмамлый. Габделнур әфәнде чишмәгә әнисе хөрмәтенә Нурзидә исемен бирә. Нурзидә апа — халкыбыз өчен ихтирамлы, игътибарлы, ярдәмчел уллар-кызлар үстерүче акъәби.

## Алабуга мөхтәсибәтендә яңа мәчет ачылды

Мөхәррам аеның 14нче көнендә (1 августта) Алабуга районы Гари авылында тантаналы рәвештә яңа мәчет ачылды. Гари авылында мөселман мәхәлләсе 2020 елда оеша һәм мәчет салу өчен җир бүлеп бирелеп, 2021 елда беренче нигез ташы салына. Мәчет ике ел эчендә шушы авыл җирлегендә яшәгән мөселман кардәшләрнең финанс ярдәме белән күтәрелә. Иң саллы өлешне шәхси эшмәкәр Кадыйров Нурислам Мидхәт улы кертә.

Мәчет авыл үзәгендә мәдәният йорты янәшәсендә сафка басты. Авыл уртасыннан төбәк дәрәҗәсендә әһәмияткә ия булган трасса уза, ягъни мәчет мосафирлар өчен дә уңайлы. Рәсми документлар буенча, иман йорты 48 кешегә исәпләнгән. Әмма мәчет берьюлы, хатын-кызларны да исәпләп, 70–80гә якын кешене сыйдыра ала. Бер катлы мәчеттә ир-атлар өчен зур намаз залы, балконда 15ләп хатын-кыз өчен зал, ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен тәһарәтханәләр, имам бүлмәсе, кухня һәм котельная бар.

Мәчет югары сыйфатлы кирпечтән төзелгән, барлык инженер-техник коммуникацияләр (ут, салкын һәм җылы су, канализация, җылыту системалары һ.б.) уздырылган, газ кертелгән.

Рифкать хәзрәт Гарифуллин имамлык иткән иман йорты Алабуга мөхтәсибәтендә 12нче мәчет булып ачылды.

## Нәзарәттә абыстайлар җыены үтте

Мөхәррам аеның 15нче көнендә (2 августта) Татарстан мөфтиятендә «Абыстайлар җыены» дип исемләнгән беренче форум үтте. Әлеге форумга Татарстанның 35 районыннан мөслимәләр берлекләре җитәкчеләре һәм Казанның барлык мәчетләреннән абыстайлар җыелды.

Татарстан мөхтәсибәтләрендә Мөслимәләр берлекләре 2005 елдан эшләп килә. Шул вакыттан бирле халыкка дини гыйлем бирү, гаилә кыйммәтләрен, татар-мөселман гореф-гадәтләрен саклау, балалар һәм яшь буынны тәрбияләү өлкәсендә эш тәҗрибәсе формалашты. Җыелышта абыстайлар шушы һәм башка юнәлешләр буенча эшчәнлекне җәелдерү хакында киңәште. Форумга нәтиҗә буларак, резолюция кабул ителде. Анда, аерым алганда, «Хәерле гаилә» үзәкләрен булдыру, республикадагы татар-мөселман хатын-кызлары өчен милли кием җитештерүне дәвам итү, милли бәйрәмнәрдә, сабантуйда исерткечләр сатуны тыю буенча җитәкчеләргә мөрәҗәгатьләр юллау тәкъдимнәре бар.

## «Зәкят» фондында балалар өчен рухи-сәламәтләндерү курслары эшләде

Казанда 1–11нче август көннәрендә Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фондында икенче тапкыр күп балалы һәм мохтаҗ гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар өчен рухи-сәламәтләндерү курслары эшләде. Анда 9–15 яшьлек 13 бала шөгыльләнде. Әлеге курслар балаларга, ял итү белән беррәттән, рухи һәм физик торышны да яхшыртырга мөмкинлек бирде.

Ике атналык программага Ислам фәннәрен өйрәнү, рухи-әхлакый үсеш, патриотик тәрбия, каратэ, көн саен зарядка ясау, төрле мастер-класслар, сәяхәтләр кертелгән иде. Алар Апанай мәчете һәм мәдрәсәсе комплексына, Казан Кремленең Музей-мемориалына, «КидСпейс» һәм «Maza Park» күңел ачу үзәкләренә экскурсиягә бардылар, Кабан күлендә катамаранда йөзәргә чыктылар.

## Әгерҗе мөхтәсибәтендә Саклау җыены үтте

Мөхәррам аеның 22нче көнендә (9 августта) Әгерҗе районы Саклау авылында мөселманнар җыены үтте. Әлеге җыен елдагыча дәүләт саклавындагы, тарих-архитектура истәлеге саналган, районда хәзергәчә сакланып калган бердәнбер таш мәчет — Саклау мәчете янында үткәрелде.

Еллык җыенда танылган хәзрәтләрдән вәгазьләр тыңланды, мөнәҗәтләр башкарылды, Саклау авылының тарихи мәчетендә өйлә намазы укылды һәм дога кылынды, Коръән ашы оештырылды. Әлеге чарага «Саклау җыены»на Әгерҗе мөхтәсибәте имамнары һәм абыстайлары, җәмәгать эшлеклеләре, тирә-як районнардан имам-мөхтәсибләр, Киров өлкәсеннән һәм Ижау шәһәреннән мөселманнар килде.

Җыенны үткәрүнең төп максаты бабаларыбыздан әманәт итеп тапшырылган динебезгә һәм борынгы мәчетләребезгә сакчыл караш тәрбияләү, Ислам динен куәтләү өчен мөселманнарга очрашу, күрешү мөмкинлеге булдыру иде. Саклау авылы җыенының тарихы 2006 елга барып тоташа. Беренче җыен, Әгерҗе районында инкыйлабка кадәр төзелгән таш мәчеткә сакчыл караш тәрбияләү йөзеннән, ул вакытта имам-мөхтәсиб булган Мөхәммәтазат хәзрәт Гатин тарафыннан оештырыла.

## Лаеш мөхтәсибәтендә бушлай су алу урыны һәм балалар мәйданчыгы ачылды

Мөхәррам аеның 25нче көнендә (12 августта) Лаеш районы Нурминкә авылы мәчете ишегалдында «Чишмә» дип аталган бушлай су алу урыны ачылды. Әлеге проектны Лаеш якташлык җәмгыяте эшмәкәрләр белән бергәлектә тормышка ашырды.

«Чишмә» проекты, суны чистартучы кыйммәтле фильтрлар куеп, скважина бораулау, су алу урыннарын төзекләндерү һәм матурлаудан гыйбарәт. Бу — Лаеш районындагы сигезенче чишмә: калган чыганаклар

Усад, Сокуры һәм Габиш, Имәнкискә, Столбище һәм башка авылларда урнашкан.

Бу көнне шулай ук Лаеш районының Сокуры авылында «Юлчы» мәчете янында балалар мәйданчыгы ачылды. Аннан бөтен авыл халкы, кунаклар файдалана алачак. Биредә кечкенә балалар, мәктәп укучылары һәм яшүсмерләр шөгыльләнә ала: баскетбол-волейбол һәм футбол мәйданчыклары, тренажер комплекслары бар. Балалар мәйданчыгын ачу тантанасыннан соң кунаклар Каеп авылына барды, биредә янгыннан зыян күргән гаиләгә хәйриячеләр ярдәме белән салынган өй кулланылышка тапшырылды.

## Коръәннең Морад Рәмзи язган мәшһүр тәрҗемәсе иске имлядән — кириллицага һәм хәзерге татар әдәби теленә күчерелде

Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында Нәзарәттә мәшһүр дин галиме шәех Мулла Морад Рәмзинең «Коръән газыйму-ш-шанның төркичә тәрҗемәсе» хезмәтен иске имлядән кирилл язуына күчерделәр һәм хәзерге татар әдәби теленә яраклаштырдылар. Күләме 700 биттән артып киткән иске имлядәге кульязма галим тарафыннан 1927–30 елларда Кытайдагы Чугучак шәһәрендә яшәгән вакытында эшләнгән. Нәзарәтнең шәригать мәсьәләләре буенча бүлеге белгечләре Нурислам хәзрәт Вәлиулла һәм Идрис хәзрәт Киёмов кулдан иске имля белән язылган текстны кириллицага җыеп күчерде, аннан соң бу текстны хәзерге татар теленә яраклаштырды. Хәзерге вакытта Коръәннең 30 нчы парәсе, ягъни аның ахыргы $^{1}/_{30}$ өлеше әзер.

Басма ике өлештән: иске имлядән кирилл язуына күчерелгән оригиналь тексттан һәм хәзерге татар теленә тәрҗемә ителгән тексттан тора. Хәзерге укучы өчен беренче өлешне аңлау кыен булганга күрә, кайбер сүзләрнең мәгънәләре, кайсы телдән алынганын һәм кайсы сүзлектән аның мәгънәсе китерелгәнен күрсәтеп, искәрмәләрдә китерелә. Басмада шулай ук китапның

үзе, аның әһәмияте турында мәгълүмат бирелгән, шулай ук шәех Морад Рәмзи тарафыннан кулланылган методология, Коръән аятьләрен аңлату тәртибе һәм үзенчәлекләре бәян ителгән. Моннан тыш, укучылар шәех белән якыннанрак таныша алсын өчен, биредә галимнең биографиясе китерелә, аның остазлары, укучылары, гаиләсе һәм башка галимнәрнең аның турында әйтелгән фикерләре басылган.

## Яңа татар-мөселман исемнәре сүзлеге дөнья күрде

Татарстан Республикасында игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысаларында «Хозур» нәшрият йортында «Исемнәр китабы» дөнья күрде. Ул — 2020–2023 елларда Диния нәзарәтенең Казыйлар шурасы тарафыннан әзерләнгән хезмәт. Бу китап — иң зур сүзлекләрнең берсе, анда 8500ләп исем: 5500 ир-ат исеме, 3000ләп хатын-кыз исеме кертелде. Татар халкында кушылган күркәм исемнәр, аларның русча язылышы, татар, гарәп, фарсы яки төрки телләрдә сакланган мәгънәсе бирелде. Китаптан хәзер кулланылыштан төшеп калган, мәгънә белдерми торган, Ислам диненә муафыйк булмаган, начар мәгънә белдергән яки тупас мәгънәле исемнәр төшереп калдырылды. Сүзлекне әзерләгәндә, нигез итеп, күренекле тел белгече Гомәр Саттаровның «Татар исемнәре ни сөйли?» китабы алынды.

## Татарстанда XVI Бөтенроссия мөселман яшьләре форумы узды: иң яхшы проектлар сайлап алынды

Татарстанда 16–23нче август көннәрендә XVI Бөтенроссия мөселман яшьләре форумы узды. Җыен Болгар шәһәрчегендә мөселманнар арасында хәйрия эшчәнлегенә багышлап, Диния нәзарәте, Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифенә ярдәм күрсәтү фонды белән берлектә оештырылды. Форумда Индонезия, Мисыр, Англия, Кыргызстан, Үзбәкстан, Таҗикстан, Кырым,

Башкортостан, Кабарда-Балкар (Нальчик), Чувашстан һәм Татарстан республикалары, Пермь крае, Мәскәү, Әстерхан, Владикавказ, Свердловск өлкәләре, Ижау, Йошкар-Ола, Самара һәм Ханты-Манси шәһәрләреннән 18–30 яшьлек 130 мөселман катнашты.

Форумның төп максаты — яшьләрнең башлангычларына үсәргә мөмкинлек бирүче мохит тудыру, мөселман яшьләренә тормышта үз-үзен табарга ярдәм итү, рухи дөньяны баету. Мөселман яшьләре белем алу, иҗади һәм гамәли чаралар аша үз социаль проектларын тормышка ашырырга өйрәнде. Нәтиҗәдә 100 проекттан 52се сайлап алынды. Аннан соң иң яхшы идея-проектлар дип 17 эш билгеләнде. Алар үзенең заманчалыгы, көн тәртибендә торган мәсьәләгә җавап бирүе белән аерылып торды: социаль челтәрләр аша яңа гына дин нигезләрен үти башлаучылар белән эш алып бару, хәләл туристик маршрутлар, хәләл һәм харам ризыкларның телеграм-боты, балалар өчен палаткалы лагерьлар оештыру, иске татар язуы буенча онлайн дәресләр уздыру, балалар һәм яшүсмерләр өчен рухи-күңел ачу чаралары үткәрү һ.б. Һәм алар арасыннан да гамәлгә кертү өчен 3 проектка 100 мең сум, 80 мең сум һәм 60 мең сум күләмендә грантлар тапшырылды. Төп җиңүче булып 9–14 яшьлек кызларга җенси тәрбия бирүгә багышланган «Тепло про тело» проекты танылды. Җиңүчеләр Ислам кыйммәтләре нигезендә пубертат (җенси яктан җитлегү) чорындагы яшүсмер өчен комикслар җыентыгы ясарга, аны офлайн һәм онлайн мәйданчыкларда таратырга ниятли. Икенче урынны «Лисан: тел ачкычы» (иске татар телендә укырга өйрәтү) проекты яулады. Авторлар иске имля буенча дәресләр алып бару өчен күнегүләр дәреслеген төзү белән шөгыльләнә. Өченче урынны этно-туризмны үстерүгә багышланган «БлогEtnotur» проекты яулады. Моннан тыш, РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе грантына балалар өчен палаткалы лагерь (20 мең сум), «Лисан: тел ачкычы» (30 мең сум), «Путеводитель мусульманки» (50 мең сум) проектлары лаек булды». Амаль» финанс йорты типография хезмәтләре белән «Тепло про тело» проектына булышырга,

«INDEEN» проекты партнеры булырга вәгъдә бирде. «Ханский дом» төзелеш компаниясеннән 50 мең сум күләмендә акчалата бүләккә «ПроНаставник» проекты лаек булды.

## Балык бистәсе мөхтәсибәтендә төзекләндерүдән соң 122 еллык тарихи мәчет ачылды

Сафәр аеның 3нче көнендә (19 августта) Балык Бистәсе районы Мәмле Казаклар Чаллысы авылында төзекләндерүдән соң «Әхмәтвәли» мәчете үз ишекләрен ачты. «Әхмәтвәли» мәчете 2022–2023 еллар эчендә «Кулон» ябык акционерлык җәмгыяте генераль директоры Альберт Фәхретдинов тырышлыгы һәм матди ярдәме белән төзекләндерелде. 120 кешегә исәпләнгән мәчет җылылык системасына тоташтырылды, тәһарәтханә һәм кухня ясалды. Идәне тулысы белән алыштырылды һәм җылытылды, плиткалар җәелде, яңа тәрәзәләр һәм ишекләр куелды, яңа келәмнәр сатып алынды, стеналар, штукатурланып, яңа обойлар ябыштырылды. Яңа минбәр урнаштырылды. Мәчет тышкы яктан сайдинг белән тышланды, манарасы һәм түбәсе яңартылды, ишегалдына туфрак кертеп газон чәчелде, коймалар тотылды.

Бүгенге көндә Балык Бистәсе мөхтәсибәтендә 46 мәчет эшли.

## Азнакай шәһәрендә яңа мәчет ачылды

Сафәр аеның 7нче көнендә (23 августта) Азнакай шәһәренең Яңа юл микрорайонында яңа мәчет үз ишекләрен ачты. Йөз ун кеше сыйдырышлы мәчетнең нигезе — блоклардан, төп бинасы агач бурадан төзелгән. Ир-атлар өчен намаз уку урыны — беренче катта, хатын-кызлар өчен намаз уку урыны — балконда. Яңа мәчетнең подвал өлешендә 60 кеше сыйдырышлы ашханә һәм барлык уңайлыклары булган кухня бар. Шулай ук ишегалдын төзекләндерү, балалар өчен уен мәйданчыгы булдыру ниятләнә.

Яңа мәчет мөхтәсибәттә 52 нче булып теркәлде. Мәчеткә имам итеп Урыссуның «Фәнис» мәдрәсәсен тәмамлаган Физикать хәзрәт Шакиров билгеләнде.

## Республика клиник хастаханәсендә икенче намаз уку бүлмәсе ачылды

Сафәр аеның 9нчы көнендә (25 августта) Республика клиник хастаханәсендә намаз бүлмәсен рәсми рәвештә ачу тантанасы үтте. Намаз уку бүлмәсе РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе тырышлыгы белән Республика клиник хастаханәсе авырулары үтенече буенча оештырылды. Бүлмә Республика клиник хастаханәсе поликлиникасының В корпусында 3нче катта уң якта урын алды. Намаз бүлмәсенең мәйданы — 15 кв.метр, анда 7–8 кеше гыйбадәт кыла ала. Тәһарәтханәсе бар, михраб куелган, келәм җәелгән. Намаз укырга керүчеләргә намазлыклар, Коръәннәр бар. Авыруларга уңайлы булсын өчен, намаз бүлмәсеннән арырак комган куелган бәдрәф эшли. Намаз бүлмәсенә кергән урында диварда бүлмәдән файдалану тәртипләре аңлатылган махсус такта эленгән.

Поликлиникага көненә 600дән, ә хастаханәгә 1000нән артык кеше мөрәҗәгать итә. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: бу — Республика клиник хастаханәсендә ачылган намаз бүлмәсенең икенчесе.

## Яңа Чишмә мөхтәсибәтендә Мәгърифәт үзәге ачылды

Сафәр аеның 10 нчы көнендә (26 августта), яңа уку елы алдыннан Яңа Чишмә районы Әдәмсә авылы мәчете янәшәсендә Мәгърифәт үзәге ачылды. Илле кеше сыйдырышлы бер катлы укыту-тәрбия үзәге Габдрахман хәзрәт Зөбәйровның тырышлыгы һәм авыл халкының матди-финанс ярдәме белән сафка басты. Йөз квадрат метр мәйданлы бинада, уку сыйныфларыннан

тыш, кухня, тәһарәт алу бүлмәләре бар. Биредә Рамазан аенда авыз ачу мәҗлесләре, төрле дини чаралар, никахлар үткәрү мөмкинлеге бар.

Хәзерге вакытта Яңа Чишмә мөхтәсибәтендә 5 Мәгърифәт үзәге эшли.

## Актаныш мөхтәсибәтендә яңа мәчет ачылды

Сафәр аеның 10нчы көнендә Актаныш районы Табанлыкүл авылында яңа мәчет үз ишекләрен ачты. Аны төзетүне тумышы белән шушы авылдан булган хәйрияче Рузилә Шәймәрдәнова оештырып йөргән.

Кирпечтән төзелгән бер катлы мәчет 40 кешегә исәпләнгән, гомуми мәйданы 60 квадрат метр. Барлык уңайлыклар тудырылган тәһарәтханәсе бар, газ, ут, су кертелгән.

Бүгенге көндә Актаныш мөхтәсибәтендә 57 мәчет эшли.

## Хөкүмәт йортында Татарстанның Ислам финанслары буенча экспериментта катнашуы турында брифинг узды

Сафәр аеның 13нче көнендә (29 августта) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында «Татарстан Республикасының партнерлык финанславы буенча экспериментны гамәлгә ашыруда катнашуы турында» брифинг узды. Журналистлар белән очрашуда Татарстан мөфтие, шәригать фәннәре докторы Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Республикасы премьер-министры урынбасары — ТР икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов, РФ Дәүләт Думасының икътисади сәясәт комитеты рәисе Максим Топилин, VIII чакырылыш РФ Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов, РФ Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсенең Татарстан Республикасы буенча Милли банк бүлеге идарәчесе Марат Шәрифуллин катнашты.

Брифинг Россиядә 2023 елның 1 сентябреннән 2025 елның 1нче сентябренә кадәр Дагыстан, Чечня, Башкортстан һәм Татарстан

җирлекләрендә Ислам банкингын кертү буенча эксперимент үткәрү турындагы канунның үз көченә керүе алдыннан узды. Камил хәзрәт Сәмигуллин журналистларга Татарстан мөфтиятенең Ислам финанслары өлкәсендәге тәҗрибәсе һәм Татарстанның бу өлкәдә гамәли казанышлары турында сөйләде. «Безнең портфолиода «Амаль» финас йорты, Ак барс банкы, Ак Барс Капитал, Мир бизнес банк, Иджара Лизинг һәм Нур Финанс кебек финанс оешмалары белән уртак продуктлар бар», — дип санап чыкты хәзрәт һәм аеруча хәләл финанс продуктларының шәригать контроле мәсьәләсенә игътибарны юнәлтте:

— Аңлашыла ки, закон үз көченә керү белән базарда хәләл банк продуктлары турындагы тәкъдимнәр белән тагын да күбрәк оешмалар барлыкка киләчәк, — диде Камил хәзрәт. — Һәм монда ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең позициясе шундый ки, финанс продуктының хәләллеге турында Ислам хокукы һәм икътисадының компетентлы белгечләре тарафыннан әзерләнгән һәм хупланган очракта һәм алга таба аны гамәлгә ашыруның шәригать контроле шартлары булганда гына сөйләргә мөмкин. Ислам финансларында хәләл стандартларга туры килү өчен уңай абруйга һәм тиешенчә компетенцияләргә ия ышанычлы дини оешмалар җаваплы булырга тиеш. Бездә сертификацияләүче һәм контрольдә тотучы шундый орган булып Голәмәләр шурасы тора. Бездә хәләллекне, финанс продуктларының рөхсәт ителүен раслаганда, шәригать экспертлары һәр продуктның алга таба сатылуын күзәтәләр. Ягъни бу — Ислам продуктын бер тапкыр сертификацияләү һәм эшләү генә түгел, ә даими аудит һәм мөфтият ягыннан күзәтчелек итү дә. Без мөселман җәмәгатьчелеге алдында дини яктан зур җаваплылык тотабыз.

## Татарстан мөфтиятендә 140тан артык укучыга букчалар һәм мәктәп кирәк-яраклары тапшырылды

Сафәр аеның 15нче көнендә (31 августта), Белем көне алдыннан, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин аз керемле һәм күп балалы, авыру,

тулы булмаган гаиләләрдә тәрбияләнүче, төрле милләттәге һәм диндәге мәктәп укучылары белән очрашты.

Мөфти 140тан артык балага букчалар һәм мәктәп кирәк-яраклары тапшырды. Аларның дүрттән бере беренче сыйныфка баручылар иде. Барлык уку кирәк-яраклары тутырылган портфельләрне беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлап керүче 25 бала алды. 2–4нче сыйныф укучылары (28 кыз, 17 малай) өчен әзерләнгән пакетларда уку кирәк-ярakларына иҗади дәресләр өчен шөгыльләнү өчен пластилин, акварель, төсле кәгазьләр, альбомнар һ.б. өстәлгән. 5–11нче сыйныфларда белем алачак 72 укучы өчен җыелмалар калын дәфтәрләр белән баетылган.

Очрашу Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтендә «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит!» республика акциясе кысаларында узды. Әлеге акция 2016 елдан бирле алып барыла. Камил хәзрәт мөфтиятнең яшь кунакларын сәламләде, аларны якынлашып килүче Белем көне белән котлады, белемнең мөһимлеге һәм кыйммәте турында вәгазь сөйләде.

## «Зәкят» фонды бер сәгать эчендә мохтаҗларга 1,5 тонна гошер таратты

Диния Нәзарәте Татарстанда 23нче сентябрьне гошер көне дип игълан итте. Бу уңайдан сафәр аеның 20нче көнендә (5 сентябрь) ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды Казандагы аз керемле гаиләләргә, ялгыз яшәүче өлкәннәргә 1,5 тонна гошер садакасын таратты. Алексеевск мөхтәсибәтенең Урта Тигәнәле мәхәлләсеннән китерелгән азык-төлек ярдәмен барлыгы  35 гаилә алды.

Татарстанда традицион рәвештә гошер садакасын җыю һәм халыкның мохтаҗ катламнарын азык-төлек белән тәэмин итү кампаниясе вакытында 2017 елда — 160 тонна; 2018 елда — 600 тонна; 2019 елда — 1109,5; 2020 елда — 1000 тоннага якын; 2021 елда — 577,33 тонна; 2022 елда — 1377,34 тонна гошер садакалары җыеп таратылды.

## Казанда XII Якупов укулары узды

Сафәр аеның 22нче көнендә (7 нче сентябрьдә) «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә «XII Якупов укулары» узды. Җыен Татарстан мөфтияте, Россия Ислам институты һәм Казан Ислам университеты, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе тарафыннан оештырылды. Конференция танылган татар мәгърифәтчесе, галим һәм дин эшлеклесе, Ислам яңарышы чорында «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең беренче директоры Вәлиулла хәзрәт Якуповның (1963–2012) бай рухи-дини һәм интеллектуаль мирасын саклау һәм өйрәнү максатыннан үткәрелә.

Якупов укулары кысаларында «Таян Аллаһка!» бәйгесендә җиңүчеләр тәбрикләнде һәм Вәлиулла Якуповка багышланган документаль фильм күрсәтелде. «Таян Аллаһка!» бөтенроссия әдәби бәйгесенә 2010 елда Вәлиулла Якупов тарафыннан нигез салынган иде.

# Нәсыйхәт

# Әхлак һәм әхлакый вазифаларыбыз

## Әхлак нәрсә ул?

Әхлак — тумыштан яки уку-өйрәнү вә гаилә тәрбиясе белән казанылган рухи хәлләр (хәят) димәктер.

Сүзләрендә, эшләрендә, һәртөрле хәл вә хәрәкәтләрендә дөрес эш иткән кешегә әхлаклы кеше диләр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер мөбарәк хәдисендә болай дигән: «Холкы яхшы булган мөселман — иман ягыннан иң камил мөселмандыр».

Дин һәм диндә кабул ителгән яхшы әхлак кагыйдәләре кеше белән Аллаһы Тәгалә, шулай ук кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләрен билгеле бер тәртипкә сала. Һәр кеше башка кешеләр белән аралашып яши. Кайда гына булмасын, бердән артык кеше булган җирдә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салучы кануннар, кагыйдәләр, гореф-гадәтләр барлыкка килә. Ислам әхлагы исә — ул дингә таянган һәм үзенең асыл мәгънәсен Ислам диненнән алган гүзәл бер әхлактыр.

Кеше бу дөньяга пакь һәм гөнаһсыз булып туа. Әгәр ата-анасы яхшы тәрбия бирсә, ул югары әхлаклы булып үсә, нинди генә вәзгыятьтә булса да, кеше булып кала белә. Мондый тәрбия бирелми икән, ул вакытта адәм баласыннан яхшылык көтмә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Әхлагыгызны камилләштерегез». Шул сүзләренә нигезләнеп, әхлакны яхшырту мөмкинлеге турында авыз тутырып сөйләшә алабыз. Алган тәрбиясенә һәм тирә-юньдәге кешеләр ясаган йогынтыга карап, кеше яхшы яки яман әхлаклы була ала.

Берәр чирдән арыну өчен без тәнебезне төрле дарулар ярдәмендә дәвалыйбыз. Нәкъ шуның кебек, күңелебезне дә әшәке сыйфатлардан чистартырга, аны камилләштерергә, гамәл-хәрәкәтебезне контроль астында тотарга, рөхсәт ителгән белән тыелганны яхшылап белергә тиешбез.

Әхлаксыз кешеләр белән аралашсак, тора-бара аларның бозык гадәтләрен дә ирексездән үзләштерергә мөмкинбез. Бу хакта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзе бар: «Тәкъва яки гөнаһкяр кеше белән дуслашу мускус сатучы һәм тимерче белән дуслашкан кебек була. Беренчесеннән мускус сатып алып, аның хуш исен иснәсәң, икенчесенә баргада йә киемеңне көйдерерсең, йә булмаса аның тәмсез исен иснәрсең».

Билгеле булганча, массакүләм мәгълүматландыру чаралары җәмгыятьне тәрбияләүдә бик зур роль уйный. Әгәр балалар көннәр буе телевизор яисә компьютер алдында утырып үткәрсә, ата-аналары гел эш белән мәшгуль булса, сабыйларның әхлакый тәрбиясе дә шуның кадәр генә булыр. Шуның өчен дә тәрбиягә бик зур әһәмият бирергә, күркәм әхлак иясе кешеләр белән аралашырга кирәк. Әгәр инде бозык әхлаклы кеше белән аралашасың икән, аралашу вакытын аны дөрес юлга бастыру өчен файдаланырга тиешсең. Иманлы кеше тискәре, негатив мәгълүматтан ераграк торсын, җәмгыятьне эчтән черетә торган нәрсәләрдән читләшсен. Бу — иң дөрес, иң хәерле юл.

Ислам дине буенча һәр кешенең шундый әхлакый вазифалары бар:

1. Аллаһы Тәгаләгә вә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата булган вазифалар.
2. Үзебезгә карата булган вазифалар.
3. Гаиләбезгә карата булган вазифалар.
4. Ватан вә милләтебезгә карата булган вазифалар.
5. Кешелеккә карата булган вазифалар.

## Аллаһы Тәгаләгә вә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата булган вазифаларыбыз

Аллаһы Тәгаләгә карата булган вазифаларыбыз:

1. Аллаһының барлыгына һәм берлегенә ышану.
2. Аллаһы кушкан эшләрне эшләү.
3. Аллаһы тыйган эшләрдән тыелу.

4. Аллаһы биргән санаусыз нигъмәтләргә шөкер итү.

5. Аллаһыны һәрнәрсәдән өстен күреп, Аллаһы Тәгаләне сөю хисен күңелгә урнаштыру.

6. Аллаһыны сөюне Аллаһыдан куркудан өстен итү.

7. Аллаһыга чын күңелдән гыйбадәт кылу.

8. Аллаһыга карата һәрвакыт тәрбияле, әдәпле булу, Аның исемен хөрмәт белән телгә алу.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата булган вазифаларыбыз:

Кешелекне караңгы бер дөньядан коткарып, якты бер дөнья тәкъдим иткән һәм безгә дөнья вә ахирәт бәхетенә илтүче юлны күрсәткән кеше — Пәйгамбәребез Мөхәммәдтер.

Безнең Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата булган төрле вазифаларыбыз бар:

1. Мөхәммәднең пәйгамбәрлегенә ышану.

2. Пәйгамбәр аңлаткан дини мәсьәләләрнең дөреслеген һәм боларның Аллаһыдан килгәнлеген кабул итү.

3. Пәйгамбәребезнең ялгыз бер милләткә генә түгел, бөтен кешелеккә пәйгамбәр буларак җибәрелгәнен кабул итү, аның әмер вә киңәш-нәсыйхәтләрен өйрәнү, тыйганнарыннан тыелу.

4. Аның әхлагы белән яшәү.

5. Аның тормышын үзебезгә үрнәк итеп, аның сөннәте буенча яшәү.

6. Аллаһы вә Пәйгамбәрне үзебездән дә артык ярату һәм хөрмәт итү.

7. Пәйгамбәребез Мөхәммәд исемен искә алганнан соң түбәндәге сүзләр өстәп әйтергә кирәк: галәйһис-сәләм, яки «аңа Аллаһының сәламе булсын», салләллаһү галәйһи вә сәлләм, яки «аңа Аллаһының бәрәкәте вә сәламе булсын».

# Үзебезгә карата булган вазифаларыбыз

Аллаһы Тәгалә бар кылган мәхлуклар арасында иң өстен зат — кешедер. Кешенең тәне һәм бу тәннең эчендә күзгә күренмәгән рухы бар. Ислам дине кешенең тәнен дә һәртөрле хасталардан һәм зарарлы нәрсәләрдән саклый, рухын да үстерә. Яхшы кеше булыр өчен фәкать тән сәламәтлеге генә җитмидер, рух сәламәтлеге дә кирәк.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай боерган: «Аллаһ сезнең тышкы кыяфәтегезгә карамас, Ул сезнең калебләрегезгә һәм кылган гамәлегезгә карар». Димәк ки, эчке арулык, ягъни рух арулыгы Ислам динендә зур әһәмияткә ия. Шуның өчен дә рухи яктан үстерү кешенең үзенә карата булган иң мөһим вазифаларыннан берсе булып санала. Начар вә пычрак уйлардан саклану, башкалар турында ямьсез фикер йөртүдән тыелу кешенең үзенә карата булган иң төп вазифалары булып исәпләнә.

Ислам дине буенча кешегә ике төрле хасталык (авыру) хас. Аның берсе — матди, икенчесе — мәгънәви хасталык. Тәнебезгә хас булган матди хасталыклар күзгә күренеп беленә. Гәүдәбезне һәртөрле матди хасталыклардан саклау — шулай ук үзебезгә карата булган вазифаларыбызның берсе. Мәгънәви хасталыклар күзгә күренмәс. Гайбәт, ялганчылык, яла ягу, хәйләкәрлек, алдау, бүтәннәрне мыскыл итү, көнчелек, тәкәбберлек, саранлык вә ялкаулык рухи хасталыклардан санала.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Ике көнен бертигез үткәргән кеше зарардадыр». Чын мөселман — һәр көн алга таба баручы вә өзлексез үзен камилләштерү өстендә эшләүче кешедер. Гыйлемлеккә омтылган, тормышын тырышлык белән алып барган, башкаларның тәҗрибәсен өйрәнгән кеше үзенә, милләтенә вә диненә дә файда китерә ала. Аның әйләнә-тирәдәгеләр арасында дәрәҗәсе бар, андый кешенең сүзенә һәркем колак сала. Үзен яхшы тәрбия кылган кеше үзенә карата булган әхлак вазифаларын үтәгән булып санала.

## Гаиләбезгә карата булган вазифаларыбыз

Баланы карау, үстерү, саклау, тәрбияләү вазифасы гаиләгә, ягъни ата-анага тапшырылган. Гаилә — Аллаһы Тәгалә әмере белән корылган илаһи бер мәктәптер. Бу мәктәпнең укытучылары — ата белән анадыр. Адәм баласы бу мәктәптә үзенә, милләтенә, гаиләсенә вә диненә карата булган вазифаларын үтәргә өйрәнер. Гаиләдән алган тәрбия кешенең динле, әхлаклы вә һәрьяктан яхшы кеше булуында, аның көндәлек тормышында зур урын алып тора.

Коръәндә Аллаһы ир-атларны:

**«Күңелегезгә хуш килгән хатын-кызларга өйләнегез...» — диеп өйләнергә өнди.**

«Ниса / Хатыннар», 4:3

Гаилә — милләтнең иң кечкенә кисәге. Гаилә нык булса, милләт тә нык, көчле булыр, шуның өчен Ислам дине гаиләгә бик зур әһәмият бирә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дигән: «Өйләнү кемнең хәленнән килсә — өйләнсен».

Билгеле бер яшькә җиткәннән соң, өйләнеп балалар үстерү, гаиләсе вә нәселе, дине вә милләте өчен җаваплылык алу — хәленнән килгән һәр мөселманга фарыздыр. Өйләнү — саваплы бер эштер. Өйләнмәгән кеше бу саваптан өлешсез калыр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дигән: «Дин буенча, Аллаһы ризалыгы өчен дип өйләнгән кеше диненең яртысын үтәгән булыр. Икенче яртысы өчен дә Аллаһыга сыенсын, Аллаһыга таянсын».

Никах һәм никахсыз тору арасында зур аерма бардыр. Никах — Аллаһы кушкан саваплы бер эш булган хәлдә, ике кешенең никахсыз бергә торуы — Аллаһы тарафыннан катгый рәвештә тыелган вә харам кылынган бер эштер. Никах ул — дингә вә милләткә хезмәттер. Никахсыз бергә яшәү — нәфескә вә шайтанга хезмәттер. Никах газиз динебезне вә милләтебезне саклар, никах-

сыз тору дини вә милли барлыкны бетерер һәм боларның югалуына сәбәп булыр. Шуның өчен Аллаһы никахны фарыз, зинаны харам кылган.

Никах — һәр милләтнең нигезедер. Никахлашып өйләнешү бетсә, милләт тә бетәр. Бу — бер илаһи канундыр.

Өйләнергә теләгән кеше — динен, милләтен вә нәселен дәвам иттерер өчен үз өстенә җаваплылык алырга теләгән фидакяр кешедер. Өйләнергә ниятләүче мөселман — үз нәфесеннән бигрәк милләтен вә динен өстен күрергә тиеш. Шуңа күрә өйләнгән кешеләр гаилә коруның дини вә милли бер мәсьәлә булганын да онытмас, өйләнгәннән соң бер-берләре белән яхшы торыр, кечкенә мәсьәләләрне зурайтып, төрле күңелсез хәлләр китереп чыгармас, кайгы вә шатлыкларын уртаклашып, бер-берләренә таяныч булыр, бер җан, бер тән булып яшәр.

Әлбәттә, кешенең тормышында төрле хәлләр булырга мөмкин. Якты көннәр булган кебек, яңгырлы, болытлы вә караңгы көннәр дә була. Мөэмин-мөселманнар мондый вакытларда да сабыр итеп, гаилә тормышын дәвам иттерергә тырышыр.

Гаилә — ул һәр җәмгыятьнең яисә милләтнең кечкенә бер кисәгедер. Гаиләнең нигезе ата-ана белән төзелер. Гаилә эчендә яшәүче кешеләрнең бер-берләренә карата булган вазифалары да бар. Боларны өч өлешкә аерып карарга мөмкин:

1. ата-ананың балаларына карата булган вазифалары;
2. балаларның ата-аналарына карата булган вазифалары;
3. туганнар һәм кардәшләрнең бер-берләренә карата булган вазифалары.

## Ата-ананың балаларына карата булган вазифалары

Ата-ананың вазифасы бала тудыру белән генә чикләнми. Туган баланы һәрьяктан сәламәт итеп үстерү, яхшы тәрбияләү, дине вә милләте өчен файдалы кылу — ата-ананың иң зур вазифаларыннан исәпләнә. Пәйгамбәребез

салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә түбәндәгечә боерган: «Балаларыгызны яхшы багыгыз, аларны яхшы тәрбия кылыгыз».

Ата-ананың баласына карата булган вазифалары нигездә түбәндәгеләр:

1. бала тугач, дини гадәтләр буенча матур вә мәгънәле исем кушу;

2. баласын фәкать хәләл ризыклар белән тукландыру;

3. ир баланы сөннәткә утырту;

4. бала мәктәп яшенә җиткәч, аны мәктәпкә бирү, укыта башлау;

5. җиде яшеннән әкрен генә дини белемнәрне өйрәтү һәм кыска сүрәләрне ятлаттыру, ун яшеннән намаз укырга кушу. Бу яшьтән соң балага динебезнең нигезләрен һәм Коръән укырга өйрәтүдә ата-ананың иң мөһим вазифаларыннан санала;

6. балалар арасында аерма ясамау;

Исламияткә кадәр булган чорда гарәпләр кыз балаларын яратмаган, хәтта аларны тереләй җиргә күмә торган булган. Ислам дине мондый эшләрне катгый рәвештә тыйды. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай ди: «Аллаһыдан куркыгыз вә балаларыгызга мөнәсәбәттә гаделсезлек кылмагыз».

7. баланың яхшы дус табуына игътибар итү (начар иптәшләре баланы юлдан яздырырга мөмкин);

8. яше җиткәч, баланы Ислам шәригатенә муафыйк рәвештә никахландыру.

## Балаларның ата-аналарына карата булган вазифалары

Безнең дөньяга килүебезгә ата-аналарыбыз сәбәп булган. Алар безне тәрбияләп үстергәннәр, тормышларының иң кыйммәтле вакытларын безгә багышлаганнар, авырлыкларга карамый, безне яхшы кеше итәргә тырышканнар. Шуның өчен дә аларның безгә чиксез хаклары бар. Ата-ана хакын түләп бетерергә мөмкин түгел. Алар бездән канәгать вә разый булсалар, без бала вазифаларыбызны үтәгән булып исәпләнербез.

Балалар ата-аналарына бервакытта да ачуланып карамас, тупас сүзләр әйтеп, кычкырып, аларны рәнҗетмәс. Коръәндә Аллаһы Тәгалә бу хакта болай ди: «...ата-анага «уф» дип тә әйтмә...»

1. Балалар ата-аналарына һәртөрле хөрмәт күрсәтеп, аларга итагатьле булырлар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дигән: «Ата-анага итагать — Аллаһыга итагатьтер. Аларга каршы тору — Аллаһыга каршы торудыр».

2. Балалар ата-аналары чакыруга йөгереп килерләр, аларның йомышларын җиренә җиткереп үтәрләр, йомшак вә татлы тел белән җавап кайтарырлар.

3. Мохтаҗ хәлдәге ата-анага балалары һәрвакыт ярдәм итәрләр.

4. Кая булса да китәргә кирәк булганда, рөхсәт сорарлар, ата-аналарына хәбәр бирерләр.

5. Ата-ана өйгә кергәндә, балалар аларны аягүрә каршы алыр.

6. Вафат булган ата-аналарын балалар онытмас, һәрвакыт аларны догалар белән искә төшерер, каберләрен зиярәт итәр. Балаларның ата-аналарына карата булган вазифалары турында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләрендә болай диелә: «Аллаһ яраткан иң сөекле гамәлләр — вакытында укылган намаз вә ата-анага яхшылык кылудыр», «Җәннәт — әниләрнең аяк астында».

## Туганнар һәм кардәшләрнең бер-берләренә карата булган вазифалары

Ата-анадан кала безгә якын булган кешеләр — туганнарыбыздыр. Үзебезне яраткан кебек без аларны да шулай ук яратырга тиешбез. Ата-ананың вафатыннан соң иң олы ул — ата, иң олы кыз — ана урынындадыр. Яшьрәк туганнар абый-апаларына хөрмәт кылыр. Алар да яшьрәк туганнарына ата-ана шәфкате күрсәтер; туганнар ата-анадан калган мал вә акчаны тигезлек белән бүлешер, мирас мәсьәләсендә бер-берләрен рәнҗетмәсләр. Туганнар

арасында иң күп үпкәләшүләр бу мәсьәләгә караганга күрә, моңа аеруча дикъкать итәргә кирәк.

Ислам дине буенча туганнар арасында шундый вазифалар каралган:

1. туганнар һәм кардәшләр бер-берләре белән яхшы яшәр, кайгы вә шатлыкларын уртак итәр;

2. бер-берсеннән якын яшәгән туганнар үзара йөрешер; аралары ерак булса, хатлар вә телефон ярдәмендә элемтәдә торыр. Туганнар арасындагы мондый мөнәсәбәтләргә Ислам динендә «силә-и рәхим» диелә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дигән: «Ризыгы мул, гомере озын булуын теләгән кеше туганнарының хәлен белсен, аларны зиярәт кылсын»;

3. бай кешеләр ярлы туган һәм кардәшләренә ярдәм итәр. Динебез буенча зәкят вә садака ярлыларга бирелер. Ләкин кардәшләр арасында ярлылар булса, аларга бирү саваплырактыр;

4. туган һәм кардәшләр бер-берсенә карата хата эшләсәләр, гафу үтенер, үпкә тотмас, чөнки динебез буенча өч көннән артык сөйләшмичә тору ярамый.

## Ватан вә милләтебезгә карата булган вазифаларыбыз

Һәр кешенең ватанына вә милләтенә карата булган вазифалары бар:

1. Ватандашлар арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салу өчен ул дәүләтнең хөкүмәте билгеле кануннар кабул итә. Безнең вазифаларыбызның берсе — бу кануннарны хөрмәт итүдер, чөнки кешеләр кануннарны таныса, һәрвакыт рәхәт һәм тыныч яшәр.

2. Ватандашлар керемнәренең бер өлешен хөкүмәткә салым рәвешендә түләр. Бу акча белән хөкүмәт ватандашлар өчен кирәкле булган эшләрне башкарыр. Мәсәлән, хастаханәләр, мәктәпләр, юллар, фабрикалар корырлар. Хөкүмәт сораган салымны төгәл иттереп түләү — мөһим бер ватандашлык вазифасыдыр.

3. Ватанны саклау акча белән генә чикләнми. Әлеге көндә милләтләр үз байлыкларын һәм ватаннарын саклар өчен йөз меңнәрчә гаскәр тота. Кешеләрнең ватаннарына мал вә җан бурычлары бар. Мал бурычы салым белән, җан бурычы хәрби хезмәт белән түләнер. Вакыты җиткәч, хәрби хезмәтебезне үтәү — ватан алдындагы бер мөһим бурычтыр.

4. Дәүләтнең идарәчеләрен ватандашлар, ягъни шул дәүләттә яшәүче халык сайлар. Сайлау вакытында яхшы кешеләрне хөкүмәткә яисә парламентка сайлау һәм дә, сайлауларда катнашып тавыш бирү — шулай ук ватанга вә милләткә карата булган вазифаларыбыздандыр.

## Бөтен кешелеккә карата булган вазифаларыбыз

Ислам дине буенча бөтен кешелек бер ата-ананың — атабыз Адәм галәйһиссәлам вә анабыз Хаува балалары. Дөньяда тәннәре төрле төстә, төрле диндә вә төрле иҗтимагый караштa булган кешеләр яши. Ислам динендә булган кешенең мөселман кардәшләренә һәм шулай ук мөселман булмаган кешеләргә карата булган төрле вазифалары бар:

1. Башка кешеләрнең тормышы да безнеке кебек үк хөрмәтле, кыйммәтле һәм кадерледер, һәр кешенең бу дөньяда яшәргә хакы бар. Динебез буенча, бер кешене дә хаксызлык белән үтерергә ярамый, чөнки Ислам динендә иң зур гөнаһлардан берсе — кеше үтерүдер.

2. Аллаһы Тәгалә бөтен кешеләрне дә ирекле итеп яраткан. Кешеләр тоткынлыкта яшәр өчен яратылмаган. Исламияткә кадәр булган заманнарда колларны базарларда мал кебек сатканнар. Исламият бу хәлләргә чик куйды.

3. Кешеләрнең уй-фикерләре вә ышанулары һәрвакыт үзгәрешсез дәвам итми, һәр кеше үзенчә уйлый, фикер йөртә, һәр кешенең үзенә күрә шәхси фәлсәфәсе бар. Бөтен нәрсәне дә безнең кебек уйламаучы һәм ышанмаучы кешеләрнең фикерләренә дә хөрмәт белән карарга кирәк, аларның дөрес булган фикерләре белән килешеп, дөрес булмаган фикерләренә нигезле җавап биреп, һәр кеше өчен дә уртак булган хакыйкатьне аңлатырга

кирәк. Карашлар туры килмәгән очракларда фикерләр арасында көрәш башлана, гадәттә мондый фикер көрәше адәм баласының дөнья хакындагы уй-фикерләвен киңәйтә генә. Без һәрберебез дә башкаларның намус вә шәрәфләренә (абруй-дәрәҗәләренә) хөрмәт белән карарга тиешлебез. Билгеле булганча, кеше — иң өстен, иң шәрәфле барлыктыр. Кешене хаксызга рәнҗетү, яла ягу, гайбәт сөйләү, сүз йөртү, мыскыл итү кебек хәлләр Исламда харам кылынгандыр.

4. Кешенең хәләл хезмәте белән табылган малы да җаны кебек кыйммәтледер. Шуның өчен башкаларның малына вә акчасына зарар китерү дә гөнаһ санала. Димәк, һәр кешенең җанына, малына, намусына, уй-фикерләренә һәм ышануларына хөрмәт белән карау — безнең кешеләргә вә кешелеккә карата булган әхлакый вазифаларыбыздыр.

*«Ислам дине нигезләре» китабыннан*